КЫЙММӘТЛЕ АЧКЫЧ

Торак базарына авыр көннәр килде

> 6

КАРА ТАМГА

Дошманга каршы көрәшкән хатын-кызларның тормышы сугыштан соң да җиңел булмый

> 16

ГАЗИНУР ФАРУКШИН:

«Сәхнә агрономсыз калган басу кебек»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 88 (28861) | Җомга | 24 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4 604609 000131

ЕРАК БАРАСЫ ДА ЮК

АВЫЛ ТУРИЗМЫНА НӘРСӘ ҖИТМИ?

Үзебезнекен сайлар чак. Чит илгә йөрүне гадәт итә башлаган халык, мәгълүм вакыйгалар аркасында, ял итүнең башка юлларын эзләргә мәҗбүр. Шуларның берсе – авыл туризмы. Бу юнәлештә шөгыльләнүчеләр дә юк түгел. Тик, ни кызганыч, үзебездәге мөмкинлекләр турында халык та, җирле җитәкчелек тә белми, туристлык оешмалары да хәбәрдар түгел диярлек. Чөнки күбесе кәгазьдән артмый, гамәлгә барып җитми дигән фикер калдыра. Авыл туризмы Татарстанда ни дәрәҗәдә үскән? Аның киләчәге өметле булсын өчен нәрсә җитми? Без шул сорауларга җавап эзләдек.

> 17

Ишетми калмагыз

Саха Республикасында (Якутия) Татарстан көннәре уза. Аның кысасында Якутия халкын һәм кунакларын Татарстан мәдәнияте, традицияләре, гореф-гадәтләре белән таныштыру каралган. Татарстаннан делегациягә язучылар, артистлар, сәнгать эшлеклеләре, республиканың танылган шәхесләре керде. Мәгълүм булганча, былтыр Татарстанда Якутия көннәре 7–11 июньдә узган иде.

Программа кысасында кино-спектакльләр күрсәтү, эшлекле очрашулар, күргәзмәләр, иҗат коллективларының чыгышлары көтелә.

Бүген исә Якутиядә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Саха Республикасы башлыгы Айсен Николаев белән якут язучысы Платон Ойунский һәйкәленә чәчәкләр салачак һәм төбәк башкаласында «Казан» скверы төзелешенә старт бирәчәк. Республика җитәкчеләренең «Татарстан – Якутия» эшлекле форумында катнашуы көтелә. Сүз ике яклы сәүдә-икътисади элемтәләрне үстерү юллары турында барачак.

«Ысыах» якут бәйрәме кысасында Сабан туе да уздырачаклар.

Россия футбол берлеге башкарма комитеты утырышында киләсе сезонда беренче лигада чыгыш ясаячак командалар исемлеген расладылар. Араларында Татарстаннан берьюлы өч команда бар: «Рубин», «Нефтехимик» һәм «КАМАЗ». Билгеле булганча, Казан командасы, премьер-лигада 15 нче урынны алып, иң көчлеләр арасыннан төшеп калды. «Нефтехимик» белән «КАМАЗ» узган сезонда да беренче лигада чыгыш ясады. Сүз уңаеннан, бүген «Рубин» белән «КАМАЗ» Казанда иптәшләрчә очрашу уздыра.

Быел Татарстанда полиция хезмәткәрләре 215 килограммнан артык наркотикны кулга төшергән. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту идарәсе башлыгы урынбасары Павел Фоминых әйтүенчә, 700дән артык кеше наркотикларга бәйле җинаять җаваплылыгына тартылган. Шуларның 300ләбе – яше 30га җитмәгән кешеләр. 11енә әле 16–17 генә яшь. Күпчелегенең эше яки башка даими керем чыганагы юк.

Ял көннәрендә Татарстанда, төньяктан үтеп кергән салкынча һава чигенеп, +26 градуска кадәр җылытачак. Гидрометеоүзәктән хәбәр ителгәнчә, шимбә – 25 июньдә көндез +20 градуска кадәр, төнлә +10...+15 градус җылы булачак. Башлангыч фаразларга караганда, киләсе атна башында термометрның терекөмеш баганасы +19...+24 градуска кадәр күтәреләчәк, 28 июньдә бераз салкынча: +17...+22 градус. Урыны белән яңгыр, яшен. Сүз уңаеннан, КФУ метеорология кафедрасы мөдире Юрий Переведенцев Росгидромет мәгълүматларына таянып әйткәнчә, июль аенда республикада һава температурасы нормадан түбәнрәк булачак. Әмма фараз инде яз башында ук ясалган, шуңа күрә мәгълүматлар үзгәрергә мөмкин.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Түбән Камада яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераны Рокыя Сәхәбетдинова балалар йортына 90 мең сумлык ике телевизор бүләк иткән. Ленинград блокадасының бөтен ачысын татыган ветеран үзе дә эти-әнисен бик иртә югалта. «Без яшәгән балалар йорты бик кечкенә иде. 100 кешегә исәпләнгән йортка 200 баланы урнаштырдылар. Нишләтәсең, сугыш...» – дип искә ала ул. Авыр хезмәтнең, ачлыкның нәрсә икәнен кечкенәдән үк яхшы белә Рокыя әби. «Балалар без күргәнне күрмәсә ярар иде», – ди ул. Ятим сабыйларга ничек тә булышырга теләп ул һәм, Түбән Камадагы балалар йортына ярдәм кирәген ишеткәч, шундук ике телевизор сатып ала. «Балаларга бу бүләкне кем тапшырганын сөйләгәч, шаккаттылар. Хәзер инде Рокыя әбиләрен кунакка көтәләр. Бергәләп чәй эчеп, тапшырулар карап, вакыт үткәрергә телиләр», – ди балалар йорты директоры Юлия Кривенцова.
(ntr-24.ru)

Баулы

Якутиядән атка атланып сәяхәткә чыккан илгизәрләр Татарстан җиренә аяк басты. Аларны Уба авылыннан ерак түгел урнашкан стела янында каршы алдылар. Сәяхәтчеләрне каршы алырга Лениногорскидагы «Алмакай» утарының татар атларын алып килгәннәр иде. Оймякон – Мәскәү маршруты буенча сәфәр кылучыларны үзебезнең чәкчәк һәм кымыз белән сыйладылар. Сүз уңаеннан, әлеге экспедиция Якутиянең Россия Федерациясе составына керүенә 390 ел тулуга багышланган.
(Баулы-информ)

Балтач

Яшьләр күнен Балтачта ел да бер мөгез чыгарып – үзгәлек кертеп үткәрәләр. Быелгысында Россия күләмендә рекордлы бәлеш пешерергә уйлаганнар. Аның авырлыгы 60 кило булачак. Диаметры бер метрлы борай бәлеше махсус мичтә пешерелер дип көтелә. Мондый зур бәлеш 2018 елда Башкортстанда пешерелгән булган. Ул чакта алар 20 килолы бәлеш пешергәннәр. Без аларны уздырырга булдык, ди оештыручылар. Бу көнне шулай ук «Коляскалар парады», чыгарылыш сыйныф укучылары бәйрәме – бүләкләүләр, эстрада артистлары чыгышы да көтелә. Бәйрәм 26 июньгә тәгаенләнгән.
(vatantat.ru)

Мамадыш

Сабан туйлары дәвам итә. 2 июльдә Мамадыш районының Югары Кыерлы авылында да милли бәйрәмне елдагыча зурлап уздырырга ниятлиләр. Сабан туена танылган җырчылар чакырылган. Елдагыча бирегә иң көчле көрәшчеләрне көтәләр. Бил алышу ике авырлыкта узачак: 85 килога кадәр һәм аннан авырраклар. Үз категориясендә беренче урынны алган егетләргә – 35000, икенчеләргә – 25000, өченчеләргә исә 15000 сум акча вәгъдә итәләр. Баш батырга тәкә белән бергә квадроцикл да әләгәчәк. Узган ел Югары Кыерлы Сабан туенда иң көчле егет булып Раил Нургалиев танылды һәм ул мини-тракторга ия булды.

ҮЗЕ САКЛЫЙ, ҮЗЕ ТАРАТА

Фармацевтика ипи кибете кебек – көн саен кирәк. Рөстәм Миңнехановның Казанда «Протек» оешмасының яңа фармацевтика комплексын ачу тантанасында әйткән сүзләре бу. Әлеге үзәк, республикадан тыш, тагын 6 төбәкне дарулар һәм медицина кирәк-яраклары белән тәэмин итәчәк.

15 мең квадрат метр мәйданда урнашкан әлеге логистик үзәктә дарулар, биологик актив кушылмалар, төрле медицина кирәк-яраклары сакланачак. Бирегә берьюлы 11 мең төргәге товар саклана ала. Шуларның 60 процентын дарулар тәшкил итә. Киләсе елга биредәге ассортиментны 20 меңгә кадәр җиткерергә җыеналар. Әлеге үзәктә тәүлегенә 250 мең берәмлек товар эшкәртеләчәк.

Рөстәм Миңнеханов инвесторларга республикада шундый зур һәм социаль яктан мөһим булган проектны чынга ашырулары, ышанычлары өчен рәхмәт белдерде. «2019 елда без фикер алышкан проектның, барлык кыенлыкларга да карамастан, уңышлы тәмамлануына бик шатмын. Фармацевтика ипи кибете кебек – көн саен кирәк», – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов яңа логистика үзәгенең иң заманча югары технологияле җайланмалар белән җиһазландырылуын да искәртте. «Халыкны кирәкле медикаментлар белән тәэмин итү буенча бурычларны хәл итүче катлаулы махсус инженерлык конструкциясе бу. Безнең бурыч – кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту. Иң мөһиме – сәламәтлек. Кирәк булган барлык әйберләр белән тәэмин ителсәк, сәламәтлек булачак. Республика өчен бу проект – бик мөһим адым», – диде Президент.

«Протек» компанияләр төркеме Россиядә дарулар белән тәэмин итүче иң эре оешма санала. Билгеле булганча, Казанда оешманың яңа үзәген төзү турындагы сөйләшүләр 2019 елда ук башланган иде. Аның төзелешенә 1,9 миллиард сум акча сарыф ителгән. Яңа үзәк, Татарстаннан тыш, Чуашстан, Мари Иле, Удмуртия, Коми Республикаларына, Киров өлкәсе белән Пермь краена да медицина кирәк-яраклары таратачак. Саннарга күчерсәк, ул алда телгә алынган төбәкләрдәге 6 меңгә якын оешмага, шул исәптән 400ләп сәламәтлек саклау оешмасына, 5 меңнән артык даруханәгә хезмәт күрсәтәчәк.

«Протек» акционерлык җәмгыятенең Директорлар советы рәисе Вадим Якунин сүзләре белән әйтсәк, иң заманча төбәк фармацевтика үзәге бу. Яңа үзәкнең ачылышы тантанасында республика җитәкчелегенә проектны хуплавы өчен рәхмәт сүзләре дә җиткерде ул. «Протек» акционерлык җәмгыяте президенты Вадим Музеев башкалада эшләячәк үзәкнең тагын бер әһәмиятле ягын искәртте. «Логистика үзәген ачу республика һәм күрше төбәкләрдә яшәүчеләр өчен даруханә ассортиментының киңрәк булу мөмкинлеген арттырачак», – диде ул.

Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов, әлеге логистика үзәге халыкны яңа эш урыннары белән дә тәэмин итәчәк, дигән фикердә. Хәзерге вакытта биредә 120дән артык эш урыны булдырылган. 2023 елга тагын 50 кешене эшле итәчәкләр. «Республика өчен бик зур казаныш бу. Оешма вәкилләре күрше төбәкләрне түгел, нәкъ менә Татарстанны сайлаган бит. Бу – моның өчен иң яхшы урын. Логистика үзәге ачуны бик дөрес карар дип саныйм», – диде депутат.

Питрәч районының Әлбәдән авылында Брест ныгытмасы оборонасында катнашкан Советлар Союзы Герое Петр Гавриловка бюст ачтылар. Тантанада Президент Рөстәм Миңнеханов катнашты. «Майор Гаврилов батырлыгы ул – ныклык, батырлык һәм каһарманлык символы. Балаларыбыз аның кебек геройлар үрнәгендә тәрбияләнергә тиеш. Аның Ватанга мәхәббәте, батырлыгы – яшьләр өчен лаеклы үрнәк», – диде Рөстәм Миңнеханов. Беларусь Республикасының мактаулы консулы Константин Анисимов әйтүенчә, Бресттагы дүрт музейда да Петр Гаврилов истәлегенә багышланган аерым экспозицияләр бар.

tatarstan.ru

Киләчәк проектлары

Президент Рөстәм Миңнеханов янәдән «Татнефтехиминвест-холдинг» Директорлар советы рәисе итеп сайланды. Хөкүмәт йортында узган утырышта яңа проектлар тәкъдим иттеләр.

Россия Фәннәр академиясенең Зелинский исемендәге Органик химия институты директоры урынбасары Александр Терентьев әйтүенчә, алар тәкъдим иткән органик пероксидларны синтезлау технологиясе малярия, паразитар авырулар, шулай ук яман шешкә каршы көрәшергә мөмкинлек бирәчәк. Моннан тыш, пероксидлар ярдәмендә фунгицидлар ясап чыгару нияте дә бар. Бу препаратларны бәрәңге, борчак һәм бөртекле культураларда сынап караганнар инде. Пероксидларны башка юнәлешләрдә дә кулланалар. «Мәскәүдә безне заказ белән күмеп куйдылар. Сез – инновацияләрдә бик алга киткән төбәк. Әмма безгә хезмәттәшлек өчен арадашчы кирәк», – ди Александр Терентьев. Рөстәм Миңнеханов Институтка Татарстандагы югары уку йортлары, фәнни-тикшеренү лабораторияләре белән хезмәттәшлекне җайга салырга тәкъдим итте.

Казанда 2025 елга онкология һәм нейродегенератив авыруларның сирәк төрләрен дәвалау өчен дару җитештерүне җайга салу планлаштырыла. Препаратлар Казан федераль университеты галимнәре эшләнмәләре нигезендә булдырылган, дип сөйләде «Изварино Фарма» (Мәскәү) компаниясе генераль директоры Орест Ибраһимов. «Нанофарма Девелопмент» әгъзаларны күчереп утыртканда кулланыла торган препаратлар җитештерә башлаган инде. Бу эш «РОСНАНО» катнашында «Идея» технопарклы тарафыннан 2015 елда оештырылган.

«Тема бик мөһим, сез шактый алга киткәнсез. Кеше тормышы бәһасез. Чит ил дарулары мондый югары бәяләр гадел түгел! Шуңа күрә бергәләп шөгыльләнергә, «Татхимфармпрепаратлары» белән көчләрне берләштерергә кирәк. Тормыш безне үзебездәге җитештерүне үстерергә мәҗбүр итте», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Санкт-Петербургтагы «ЕТС» компаниясенең стратегия һәм үсеш буенча директоры Сергей Андреев кече тоннажлы химия тармагындагы хәлләр турында сөйләде. Аның фикеренчә, санкцияләр, Көнбатыш ширкәтләренең Россия базарыннан китүе бездәге җитештерүчеләргә зур мөмкинлек ачты. «ЕТС» бүгенге шартларда эшчәнлек алып бару өчен ярдәм күрсәтергә әзер. «Бездә СИБУР катнашында инженерлык мәктәбен булдыру мөмкинлеге бар. Кытай, Һиндстан белән хезмәттәшлек итәргә кирәк. Әмма нәрсәне мөмкин, шуны үзебездә җитештерергә кирәк. Моны тиз генә эшләп булмый. Әлбәттә, сезнең белән хезмәттәшлек итәчәкбез», – диде Президент.

Сентябрь башында Казанда узачак Татарстан Нефть, газ, химия форумына 200дән артык предприятие чакырылган. «Бик яхшы әзерләнергә кирәк. Форум илдә иң яхшысы булырга тиеш. СИБУРның хәзер бик җитди тәкъдим ителүен исәпкә алып, әйдәгез, Урта Азия илләре, Төркия, Кытай партнерларын чакырыйк, бәлки, Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы илләрен дә чакырыргадыр», – диде Рөстәм Миңнеханов.

ЧИТ КЕШЕ ТҮГЕЛ

Актаныш белән моннан ары Ленар Зарипов җитәкчелек итәчәк. Җирле депутатлар элеккеге башлык Энгель Фәттаховның отставкага китү теләгенә каршы килмәде. Ул үзе исә районда калырга җыена.

tatarstan.ru

Билгеле булганча, моннан ике атна элек килеп чыккан шаушулы вакыйгадан соң Энгель Фәттахов үз вазыйфасыннан китәсен әйтте. Район советының мөһим карар кабул ителгән чираттан тыш утырышында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты. Парламент спикеры әйтүенчә, Энгель Фәттаховның хезмәт юлы тулысынча диярлек район белән бәйле. Хакимият башлыгының тырышлыгы, республика җитәкчелегенең ярдәме белән районда торак, социаль объектлар, юллар төзү һәм капиталь ремонтлау, «Безнең ишегалды» кебек проектлар уңышлы хәл ителде. Актаныш узган ел йомгаклары буенча районнарның социаль-икътисади үсеш рейтингында 12 нче урынга чыкты. Район авыл хуҗалыгында да зур уңышларга иреште.

– Һичшиксез, Актаныш районында яшәүчеләрнең уртак хезмәте җимешләре бу. Шулай да Энгель Нәвапович эшне оештырудагы, республика хакимият органнарының халык белән тыгыз элемтәсен урнаштырудагы өлеше бәяләп бетергесез зур, – диде Дәүләт Советы Рәисе. – Күп эшләнде, әмма тормыш дәвам итә. Энгель Нәваповичның абруе һәм тәҗрибәсе, һичшиксез, республикабызның киләчәге өчен кирәк тә, файдалы да булачак.

Районга 1998 елда җитәкчелек итә башлаган Энгель Фәттахов үзе белән бергә эшләүчеләрнең һәркайсына рәхмәт белдерде һәм ерак китәргә җыенмаганын әйтте.

– Актаныш – авыл хуҗалыгы районы. Без – игенчеләр, һәм иң зур казанышыбыз – мул уңыш җыю. Район төрле елларда республикада алдынгы сафларда барды, без һәрвакыт 200 мең тонна ашлык үстерүгә омтылдык һәм моңа ирештек тә, – диде ул. – Мин 20 ел, урынбасар вазыйфасын алсаң, 25 ел эшләдем. Актаныш урамнарында иркенләп йөрим. Кем генә мөрәҗәгать итсә дә, берсенә дә битараф булмадым. Үти алмасам да, битараф калмадым. Мине эшләткән өчен республика җитәкчелегенә бик зур рәхмәт. Киләчәктә дә шушы районда калып, шушы коллектив белән хезмәтемне алып барасым килә.

Район уставы нигезендә, яңа башлык вазыйфасына Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов исеменнән моңа кадәр район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары итеп билгеләнгән Ленар Зарипов кандидатурасы тәкъдим ителде. Ул – чыгышы белән Актанышның Кужәкә авылыннан. Әтисе озак еллар буе авыл хуҗалыгы тармагында җитәкче вазыйфаларында хезмәт куйган, ТАССР Югары Советы депутаты итеп сайланган. Ленар Зарипов, электромонтердан башлап, «Сетевая компания»нең «Чаллы электр челтәрләре» филиалы директорына кадәр хезмәт юлын үткән. Район Советы депутатлары Президент тәкъдим иткән кандидатураны бертавыштан хуплады.

Утырышта шулай ук район башкарма комитеты җитәкчесе Рөстәм Ильясовның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылды. Район уставы буенча, хәзерге вакытта әлеге вазыйфаны биләүгә конкурс игълан ителгән. Аңа йомгак ясалганчы, башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын Ленар Зарипов башкарачак.

Әлеге карар кабул ителгәннән соң яңа җитәкче үзенә күрсәтелгән ышаныч өчен Татарстан Президенты исеменә рәхмәт сүзләре җиткерде.

– Бу вакыйга – республика масштабында. Энгель Нәваповичны озатканда, аның турында мактау сүзләре ишетү рәхәт булды. Аның катлаулы чорда министр булып эшләве турында яхшы сүзләр әйтелде. Кем генә килсә дә, бу район яхшы икътисади, мәдәни, социаль рельсларга салынган. Президент тәкъдим иткән Ленар Зарипов кандидатурасын депутатларның хупламына шатмын. Аның җитәкчелегендә районның тагын да зуррак уңышларга ирешәчәгенә ышанам, – диде Фәрит Мөхәммәтшин утырыштан соң. – Актаныште – чиста татар районында тел, халыкның гореф-гадәтләре һәм традицияләре бик әйбәт саклана. Моннан тыш, авылда яшәүчеләргә ярдәм итеп, ил икътисадын үстереп кенә калмыйча, республикадагы барлык халыкларның мәдәниятен дә саклыйбыз. Авылда тел һәм гореф-гадәтләр әйбәтрәк саклана.

Тел димәктән, Фәрит Мөхәммәтшин Актаныштагы утырышта бары татарча гына чыгыш ясады.

Рәсми хәбәрләр

Елга буйлап сәяхәт итүчеләрне ишәйтү күздә тотыла. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның Дәүләт Думасының Туризм буенча комитеты әгъзалары белән очрашуында шул хакта сөйләштеләр. Комитет рәисе Сангаҗи Тарбаев җитәкчелегендәге парламент делегациясе Татарстанга Идел һәм аның кушылдыклары янында урнашкан төбәкләрдә туризмны үстерү, шулай ук елгада пассажирлар йөртүне оештыру мәсьәләләрен өйрәнү өчен килгән. Төбәк хакимиятләре органнарының бу юнәлештәге эш тәҗрибәсе Татарстан һәм Чуашстан үрнәгендә карап тикшерeләчәк.

– Казан – туристларның иң яраткан шәһәрләреннән берсе, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Узган елда республикада 3,3 миллионнан артыграк кеше булып китте.

Әлбәттә, коронавирус пандемиясе туризмга тискәре йогынты ясаган. Әмма хәзер хәлләр яхшыра, эчке туризм үсә. Дәүләт Советы Рәисе әйтүенчә, республикада туризмны үстерүгә зур игътибар бирелә. Бездә бик күп мәдәни мирас объектлары, Болгар һәм Свияжск, борынгы шәһәрләр, музей-тыюлыклар бар. Республиканың уңайлы урында урнашуы, юлларның әйбәт булуы, шулай ук бездә үткәрелеп килә торган халык бәйрәмнәре, төрле чаралар туризмны үстерүгә ярдәм итә.

Комитет рәисе Сангаҗи Тарбаев, үз чиратында, елга туризмын үстерү мәсьәләсенең Дума һәм Хөкүмәт дәрәҗәсенә чыгарылуын билгеләп үтте. Аның әйтүенчә, бу җәһәттән Идел буе федераль округының «Иделдә сәяхәт» проекты зур әһәмияткә ия. Хәзерге вакытта анда 7 төбәк: Татарстан, Мари Иле, Пермь крае, Түбән Новгород, Ульяновск, Саратов өлкәләре, Мордовия катнаша.

– Беренче чиратта нәкъ менә Идел туризмы белән шөгыльләнергә кирәк. Соңрак мондый проектны Дон һәм Ока елгаларына да җәелдерергә мөмкин. Тулаем алганда, Татарстан туризм өлкәсендә күп кенә төбәкләр өчен үрнәк булып тора, – диде комитет рәисе.

***

Мәскәүдә Милләтара мөнәсәбәтләр һәм дини берләшмәләр белән берлектә эшләү советы утырышы узды. Федерация Советы Рәисе урынбасары Константин Косачев үткәргән чарада 2020 елда гомумроссия тавыш бирү йомгаклары буенча Конституциягә кертелгән төзәтмәләрдән чыгып, дәүләт милли сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру мәсьәләләре каралды. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Милләтара мөнәсәбәтләр һәм дини берләшмәләр белән берлектә эшләү советы рәисе урынбасары Фәрит Мөхәммәтшин әлеге утырышта видеоконференц-элемтә аша катнашты.

«Быел дәүләт милли сәясәте стратегиясенә 10 ел тула, – диде Константин Косачев, утырышны ачып. – Әлеге документны кабул итү бик кирәк иде. Аның әһәмияте бәяләп бетергесез зур, чөнки шуның нәтиҗәсендә илдә милли сәясәтне тормышка ашыру программасы, максаты пәйда булды, бу өлкәдә федераль үзәк һәм төбәкләрнең вәкаләтләре төгәл билгеләнде». Константин Косачев әйтүенчә, Стратегия кайбер дәүләт программаларын, шулай ук төбәк дәрәҗәсендәге документлар кабул итү өчен нигез булган.

Милләтара мөнәсәбәтләргә мониторинг мәгълүматлары буенча, Татарстан узган елда дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру буенча төбәкләр арасында лидерлар өчлегенә кергән.

ЧИСТА ДА, ТӨЗЕК ТӘ БУЛСЫН

Киләсе елда Татарстанда 200 ишегалды һәм 45 иҗтимагый киңлек төзекләндереләчәк. Аларны республика халкы үзе сайлаган. Хәтерләсәгез, 15 апрельдән 30 майга кадәр Дәүләт хезмәтләре порталында бу уңайдан махсус тавыш бирү оештырылган иде. Быел анда тәүге тапкыр 14 яше тулган үсмерләр дә катнаша алды.

Татарстан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Алексей Фролов сүзләренә караганда, онлайн тавыш бирүдә катнашучылар сизелерлек арткан. «Узган ел 170 мең кеше катнашкан булса, быел 207 мең кеше үз фикерен белдерде», – ди Фролов. Казан, Чаллы шәһәрләрендә, Яшел Үзән, Алабуга, Чистай, Бөгелмә районнары халкы быел аеруча актив булган.

Республика халкына су белән бәйле һәр нәрсә кызыклы икән. Төзекләндерүгә мохтаҗ урыннарны ачыклауда иң күп тавышны әнә шул су белән бәйле җирләр җыйган. Бу юнәлештә иң күп тавышны Казанның Җиңү паркындагы сулык белән Әлмәттәге күл янындагы шәһәр комлыгының икенче өлеше җыйган. «Әлмәттә, иң беренче чиратта, Шевченко урамындагы юл кырыена җәяү йөрү яки ял итү урыны ясаячакбыз. Аны шәһәр халкы һәм җирле җитәкчелек белән бергә хәл итәчәкбез», – диде «Татарстан шәһәрләрен үстерү институты» фондының архитектура проектлары департаменты җитәкчесе Наилә Зиннәтуллина. Кукмарадагы Нурминка елгасының яр буе да – иң күп тавыш җыючылар рәтендә.

Төзекләндерүгә мохтаҗ ишегалларын, иҗтимагый киңлекләрне шул рәвешле барлау республикада 2018 елдан бирле гамәлдә. Уртак тырышлыкның телгә алырлык

dvor.tatar

нәтиҗәләре дә бар. Әйтик, 2020–2021 елларда «Безнең ишегалды» программасы кысасында Татарстанда 2167 ишегалды төзекләндерелгән.

«Республиканың иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерү тәкъдимен 2001 елда федераль дәрәҗәдә күтәреп алдылар. Шул рәвешле без хәзер ничәнче ел рәттән бөтен ил белән онлайн тавыш бирүләр оештырабыз, нәтиҗәләр ясыйбыз, өстенлекле юнәлешләрне билгелибез», – диде Алексей Фролов.

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Һаман алай булмас

Язганнарым кайчак уйдырма кебек тә тоелып китәдер, әмма һәркайсының нигезендә булган яки булырга тиешле хәл ята.

Беркөнне Арчада яшәүче каләмдәшем Ильяс Фәттахов гыйбрәтле хәл сөйләде. Баштарак ул миңа бераз мистикага тартым кебек тоелды. Бер ир үзенең улын дөнья малына артык кызыкмаска, кеше өлешенә кермәскә, урламаска кирәк дип тәрбияләгән һәм шушы сыйфатларны өч сүзгә сыйдырып, дәфтәр битенә язып куйган. Улына: «Башың бик бутала, тормышың кирегә китә башласа, шушы дәфтәргә күз салгаларсың», – дигән.

Малай үсеп җитә, үзенең бизнесын булдыра, кем әйтмешли, балда, майда йөзә башлый. Әлбәттә, дәфтәр турында уй ике ятып, бер төшенә дә керми. Акча бар җирдә пычрак җыела бит әле ул. Кайберәүләр үзен дөньяның кендеге санап яман гамәлләр дә кыла башлый. Кайвакыт: «Бездә чиста бизнес бар микән ул?» – дип тә уйлап куясың.

Безнең халык – берәр нәрсә шылт иттеме, берәр хәл булдымы – җыр чыгара бит инде ул. Шуларның берсен: «Су буенда талга кунып сайрый былбыл баласы. Аз рәхәткә, күп михнәткә түзә адәм баласы…» – дип без дә урам әйләнеп җырлап йөрдек. Яшь вакытта җырның мәгънәсенә бик игътибар ителмәгән инде. Бу җырны теге ирнең улы җырлап үскәндерме-юкмы – анысы билгесез, әмма җырласа да, мәгънәсе турында ул да бик уйланмагандыр, күрәсең. Кыскасы, эшләре артка китә башлый моның. Типтерәп яши торгач, тормыш үзе артына тибә егетнең. Алай бәргәләнә, болай бәргәләнә бу, әмма алда бер-бер яктылык, авыр хәлдән чыгу юлын күрә алмый. Шул вакыт әтисенең: «Дәфтәргә күз салгаларсың», – дигән сүзләре исенә төшә. Эзли торгач таба дәфтәрне, анда «Һаман алай булмас» дип язылган була. Ата кеше улын нинди язмыш көтәсен алдан ук белгән микәнни? Юктыр. Улына бары тик үзенчә тормыш гыйлеме, «яшәү кодексы» бирмәкче булгандыр. Ә тормыш гыйлеме – гыйбрәт инде ул.

Ильяс белән шул хакта фәлсәфә сатып утырабыз. Тормыштан икебез дә канәгать. Беркайчан да кеше өлешенә кермәдек, урлашмадык, дип шатланабыз. Артыгы булмагач, күңел тыныч, дибез. Ильяс әйтә: «Журналист нәрсә урласын инде ул?» – ди.

– Уеңда булса, урларга була, – мәйтәм.

– Мәсәлән?

– Мәсәлән, тема. Менә син дәфтәр турында сөйләдең, ә мин кайтам да шушы гыйбрәтне үзем күргән-белгән кебек язам.

– Бу теманы мин сиңа үзем бүләк итәм, рәхәтләнеп яз, үз сүзеңне әйт. Мин бертөрле әйтәм, ә син икенче төрле…

– Карале, теге егетнең язмышы белән кызыксынганың юкмы?

– Әти-әнисе исән әле аның, беркөнне сорашкан идем. Малае хәзергә эшсез, өйдә ята икән. Төрмәдән көчкә котылып калган. «Һаман алай булмас, итәгеңне җыеп йөр», – дип һаман әйтә килдем, тыңламады бит, диде әтисе.

Бу сөйләшүнең артык әһәмияте юк та кебек иде, тик менә, ни галәмәт, бөтен нәрсә җитеш булып, тормыш артык әйбәтләнсә, күңелгә барыбер шик керә башлый. Чөнки бу дөньяда һаман алай була алмый бит инде һәм тиеш тә түгел. Язмыш кешегә яхшысын-яманын бүлеп бирә дип уйлыйбыз. Бу уй күңелләргә нык кереп утырган инде. Без әнә шулай тәрбияләнгәнбез.

ГЛОБАЛЬЛӘШҮ БЕЛӘН БӘХИЛЛӘШҮ,

ЯКИ ПАРТИЗАННАР ХАКИМЛЕККӘ КИЛГӘНДӘ

Петербург икътисади форумында чыгыш ясаганда, Үзәк банк рәисе Эльвира ханым Нәбиуллина, изоляциягә алыну сәбәпле, Россиядә килеп туган вазгыятьне «озакка һәм, бәлки, бөтенләйгә дә» дип бәяләде. Илнең төп банкиры килеп туган хәлне берникадәр төзәтү өчен, җитештерүне һәм сәүдәне эчке базарга юнәлтергә тәкъдим итте.

Россиядә 140 миллионлап кеше яши икән, шул чама кулланучы бар дигән сүз. Россиялеләрнең шактый түбән хезмәт хакына яшәүләрен исәпкә алганда, җитештерүчеләр өчен базар бик тар, зур инвестицияләр ясап табыш алырга мөмкинлекләр юк диярлек. Бу юлларны язучы үзенең фикерен чынбарлыктагы фактлар белән дәлилли. Базар белгечләре илдә дуңгыз ите җитештерү перспективалары турында менә нәрсәләр хәбәр итәләр: «Дуңгыз үрчетүче эре компанияләр яңа проектларны тормышка ашыруны туктата: базар экспортның кимүе һәм халыкның сатып алу сәләте түбәнәю сәбәпле тулып ташыды. Ел нәтиҗәләре буенча дуңгыз итенең бәясе 10–15 процентка түбәнәергә мөмкин». Юк, бу юлларның авторы һич кенә дә дуңгыз асрауны яккамый, киресенчә, ул аңа каршы. Әмма мисал глобаль базарларның бикләнүе ни өчен җитештерүчеләр кризисына китерүен күрсәтеп тора.

Россиядә соңгы вакытларда пыяла җитештерү нык кими. Сәбәбе: торак төзелеше һәм автомобиль җитештерү чүгү. Пыяланың төп кулланучылары шулар бит инде. Ком җитәрлек, суга да Россиядә кытлык юк, пыяла җитештерү технологияләре дә бар, аларны эзләп читкә чыкмыйбыз, ләкин җитештерүне арттырырга чама юк. Импортны алыштыруның программаларын эшләргә һәм инвестицияләр өчен зур акча бүлеп бирергә була, әмма киң базардан башка барлык проектлар да әйләнеп капланачак. «Сколково» профессоры Андрей Шапенко бу хакта: «Беренчедән, күп кенә тармаклар өчен, масштаблы нәтиҗәләргә ирешәм дисәң, җитди ихтыяҗ таләп ителә. Эчке базар андый ихтыяҗны тәэмин итә алырлык түгел», – ди.

Хәзер инде ни өчен кешеләрнең бик ерак заманнарда ук җилкәнле кораблар ияртеп, тормышларын куркыныч астына куя-куя, ерак сәяхәтләргә чыгып китүләре аңлашыла торгандыр. Алар үзләренә яңа товарлар китерүче һәм үз товарларын илтергә мөмкинлек бирә торган базарлар эзли. Сәясәтнең барлык сәхнә арты көрәше һәм безнең күз алдында бара торган сугышлар базарлар өчен барды һәм бара. Пакьстанның апрель аенда гына түнтәрелгән Премьер-министры Гимран Хан үзен идарәдән читләштерүне Вашингтон оештырды дип бара. Янкиларга Гимран Хан ни өчен ошамаган? Россиягә килеп, 24 февраль алдыннан гына килешүләр төзеде. Пакьстан армиясен моңарчы америкаҗнар коралландырды. Шул базарны гына югалтса да, АКШның хәрби сәнәгать комплексы зур акчадан колак кагачак иде. Искәртик: Гимран Ханны яклап зур халык массалары урамнарга чыкты, ләкин уңышка ирешә алмадылар, чөнки армия яңа Премьер Шаһбаз Шәриф ягына басты. Ул фигура артында бик күп көчләрнең мәнфәгатьләре кисеште. Әйтик, төрекләр дә аның яклы иде.

Петербург форумы алдыннан гына Владимир Путин Әфганстанга 5 миллиард долларлык ярдәм күрсәтеләчәген әйтте.

vk.com

Акчалата түгел, ашлык һәм яшәеш өчен әһәмиятле булган башка стратегик товарлар озату күз алдында тотыла. Яңа әфганлы хөкүмәт белән дуслашу Кремльгә ник кирәк? Пакьстан базарына иң туры юл Әфганстан аша. Аннан Һиндстанга да ерак калмый. Әфганстанда үткән гасырның җитмешенче еллар ахырыннан алып узган елның августына кадәр барган канкоеш шул стратегик юл өчен барды да инде. Һәм табигый байлыкларга мул булган Әфган туфрагы өчен дә, билгеле. Әфганстанда оттыру – дөньякүләм йогынтыны югалтуның башы ул. Әфганлылар тик торганда гына үзләрен «империяләр каберлеге» дип атамый.

Шул урында туктыйк та нәтиҗә ясыйк: глобаль базарларга ия булу – муллык һәм үсеш, арзанлы товарлар дигән сүз. Алардан читләштерелү – матди деградация. Россиянең узган гасырның туксанынчы елларында дөньякүләм базарларга тартып кертелүе глобальләштерү сәясәте өчен котылгысыз кирәк иде. Глобаль капитализм киңәймичә яши алмый. Киңәюнең туктавы үзе үк аның үлемен аңлата. Киңәю ике юл белән тормышка ашырылды. Беренчесе – барлык дәүләтләрне дә доллар зонасына тартып кертү. Икенчесе – кредитлар биреп, ихтыяҗны ясалма рәвештә стимуллаштыру. Кызганычка, бу юлларның икесе дә тупыйкка алып бара. Беренчесе, Җир шарының чикләнгән булуы белән касыкка китереп суга. Җитмәсә, илләр һәм халыкларда хаклы рәвештә сорау туа: ә ни өчен доллар? Процентлы кредитлар сәясәте дә мәңге дәвам итә алмый, чөнки математиканы 9 сыйныф дәрәҗәсендә белгән һәремгә ачык: аның кадәр процентларны түләү мөмкин түгел. Процентларны түбәнәйтеп, хәтта тискәре процентлар кертеп тә хәлне төзәтеп булмый, чөнки инфляция баштан аша да бар нәрсәне дә әйләндереп каплый. Кояш астындагы үз урыннарын сакларга тырышып, дәүләтләр валюта һәм сәүдә сугышлары оештырып карыйлар, санкцияләр кертеп уйныйлар, чын сугышларның сценарийлары эшләнә һәм аяныч рәвештә тормышка ашырыла. Һәм без нәрсә күзәтсәк, шуны күзәтәбез инде. Югарыда саналган чаралар глобальләштерүне кире юнәлешкә бора һәм вазгыять тагын да тизрәк катлаулана: җитештерү зыянга була башлый, конвейерлар туктый, эшсезлек арта… Болар барысы да тагын да ныграк кысылырга мәҗбүр итә.

Глобальләштерү – кешелек тарихының соңгы этабының элгәресе ул. Әйдәгез, сүзне ахырзаман илчесенә бирик: «Кыямәт көне фетнә пәйда булмыйча, ялган таралмыйча һәм базарлар якынаймыйча килеп җитмәячәк». Базарлар якынаюның глобальләштерү икәнен аңлау кыен түгел, ә беренче икесен, игътибар белән карасагыз, инде алдыбызда икәнен күрми калмассыз. Хәзер һәрбер хәбәрне фейк дип атау гадәткә керде: Көнбатышта Россияне дезинформация таратуда гаепләләр. Кремль, оппонентлар алдаша, дип бара. Бер үк вакыйганы ике, хәтта өч төрле итеп шәрехләү гадәткә керде. Тыелган ресурсларның саны чамадан ашты. Кайвакыт дөреслекнең кайда икәнен белсәк тә, телне тешләргә мәҗбүрбез, чөнки «От сумы да тюрьмы не зарекайся» дигән рус әйтеме авызны ачуга искә килә дә төшә.

Кешелек җәмгыяте тупыйктан чыгу юллары эзләп талпына бүген. Франциядә соңгы сайлауда Макрон партиясе парламентта өстенлек ала алмады. «Сул»лар (социализм тарафдарлары) һәм француз фашистлары үкчәгә басып килә һәм, парламентка үтеп, хәлиткеч карарлар кабул итүгә ясарга керешәләр. Марксизм һәм ленинизм идеяләре АКШта популярлаша. 19 июнь көнне Колумбиядә – Вашингтонның Латин Америкасындагы ныгытмасы булган илдә аның тарихында беренче тапкыр социалист, элекке партизан Густаво Петро Президентлыкка килде. «Сул» көчләрнең дөньяда популярлашуы аңлашыла, чөнки мавыктыргыч тигезлек һәм туганлык идеяләрен байрак итеп күтәрәләр.

Вәләкин тәҗрибә шуны күрсәтә: социализм тарафдарлары кайда гына җиңеп чыкмасын һәм күпме генә хакимлек итмәсен, тигезлек идеясе бары тик фәкыйрьлек дәрәҗәсендә генә тормышка ашырыла һәм адәм балалары ахыр чиктә социализмнан тәмам гаҗиз була. Бу бик табигый, чөнки яратылышы белән инсаннар физик көчләре, интеллектлары, сәләтләре белән төрле дәрәҗәдә итеп яратыла. Шундый тигезсезлек булмаса, дөньяның алга барышы туктала, эшкә кеше табып булмый башлый. Аллаһы Тәгалә бу хакта менә нәрсә ди: «Без аларның дөнья мәгыйшәтләрен дә Үзебез бүлдек, кайберләрен бай, кайберләрен фәкыйрь кылдык, вә аларның бәгъзеләрен дөнья тормышында дәрәҗәдә бәгъзеләреннән артык кылдык, байлары ярлыларны хак биреп эшләтсеннәр өчен…» («Зүгъруф» сүрәсе, 32 аять, Ногмани тәфсире). Моны танымаска тырышучылар күп, әлбәттә, Аллаһ куйган шул чикне атлап чыгарга тырышу, ГУЛАГ лагерьларының киң челтәрен, рәхимсез репрессияләрне, штык терәп кешеләрне эшләргә мәҗбүр итүне гамәлгә кертә. Профессорларның кул пычкысы белән урман кисүләре безнең тарихта булды бит инде. Технологик артталыктан башка берни дә бирмәде. Процент капиталының һәм кәгазь акча хакимлегенең нәтиҗәләре дә ахыр чиктә җимергеч нәтиҗәләргә китерә, чөнки алары да – Галәмнәр Хуҗасы куйган чикне бозу. Чыгу юлы эзләп кайбер икътисад белгечләре глобаль капитализмның нигез ташлары булган кәгазь акча һәм процент капиталыннан баш тарту идеясен алга сөрә. Петербург форумында бизнес-омбудсмен Борис Титов нуль процентлы кредитлар турында фикер җиткерде. Алтын белән тәэмин ителгән Россия акчасын басу турында тавышлар ешрак яңгырый. Ләкин хәзерге икътисади система һәм дөньядагы вазгыять фонында болар әлегә мөмкин түгел. Алар – якын килачәк эше. Болар – башка идеология, башка система атрибутлары.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

kazanfirst.ru

ТИЕНЕ ДӘ КАДЕРЛЕ

Бурычлыга көн күрсәтмәсәләр, нишләргә? Әҗәтле кешенең хокуклары бармы? Бу хакта журналистларга суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча дәүләт реестрын алып бару һәм түләү вакыты чыккан бурычны кире кайтаруны хәл итүче юридик затлар эшчәнлегенә контроль бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Дмитрий Богумель сөйләде.

Хәзерге вакытта республика дәүләт реестрында вакыты чыккан бурычларны түләтү белән шөгыльләнә торган 14 оешма исәпләнә. Рәсми оешмалардан тыш, бурычларны кайтарту белән микрокредит оешмалары һәм банкларның да шөгыльләнүе мәгълүм.

Әҗәтле белән ничек эш итәргә? Иң яхшысы – арадашчысыз, ди белгеч.

– Бурычлылар белән ничек эш итәргә икәнлеге 230 номерлы Федераль законның 4 нче маддәсендә аңлатыла. Бу – иң элек, шәхси очрашулар, телефон аша аралашу, электрон элемтә чаралары аша сөйләшү, почта хезмәтеннән файдалану. Боларны башкару өчен бурычлының һәм өченче затның язмача рөхсәте булырга тиеш, – дип аңлатты Дмитрий Богумель.

Бурыч өстенә бурыч җыйгансың икән, аны кайтарту белән шөгыльләнүчеләрдән хат-хәбәр дә көт инде. Дмитрий Богумель сүзләренчә, әҗәтле физик затның үзенә генә түгел, аның гаиләсе, туган-тумачаларына шалтыратулар килә башлый. Әмма еш кына бу бурычлы кешенең рөхсәтеннән башка гына башкарыла икән. Асылда шалтырату өчен дә әҗәтле зат рөхсәт биргән булырга тиеш. Еш кына бурычлылар физик, психологик басым белән дә очрашырга мөмкин. Кайбер очракларда мондый янауларны аларның якын кешеләренә дә ишетергә туры килгәли.

Шалтырату димәктән, коллекторларның әҗәтле кешене ничә тапкыр «борчырга» хокукы бар? Дмитрий Богумель аңлатканча, телефоннан шалтырату саны аена – 8дән, атнасына – 2дән, көненә бердән артырга тиеш түгел.

Бу җәһәттән Дмитрий Богумель Татарстанда эшләп килүче оешмаларны телгә алды. Мактап, билгеле. «Бурычларны кайтарту буенча республикадагы оешмалар законга җитди карый. Быел 14 оешма арасыннан бары тик ике генә хокук бозу очрагын ачыкладык. Алары да гражданнарның хокукына кагылган эш түгел иде», – диде ул.

Халык арасында зарланучылар саны артканмы соң? Дмитрий Богумель әйтүенчә, быел ул сизелерлек дәрәҗәдә.

– 2022 елның биш аенда 392 мөрәҗәгать кабул ителде. Узган елның шушы ук чорында бу күрсәткеч 291 иде, – диде ул.

Хокуклары үтәлмичә, бурычлы кеше идарәгә мөрәҗәгать иткәндә, һәр вактөяк мөһим, дип искәртә белгеч.

Әйтик, вакыты чыккан әҗәтне кайтарту белән шөгыльләнүчеләр арасында да намуссызраклары бар бит. Алар көн дә, төн дә дими шалтыратырга, янарга мөмкин. Белгечләргә физик затның эшен караганда әнә шул шалтыратуларның вакытлары (телефонда «детализация звонков» дигән өлешендә тулырак мәгълүмат бирелә) да кирәк, янаулы «смс»ларның «скриншот»лары да булыша, дип аңлата Дмитрий Богумель.

Элек бурычлы кеше яшәгән подъездга, ул яшәгән фатир ишегенә буяу белән: «Монда бурычларын түләмәгән кеше яши», – дип язып китү очраклары күп була иде. Дмитрий Богумель әйтүенчә, бу да әҗәтленең хокукын бозу санала. Аның өчен җаваплылык каралган. Быел шуңа бәйле бер мөрәҗәгать кабул иткәннәр.

– Халыкка шуны әйтәсе килә: икътисади хәлләр катлаулы. Әмма акча белән бәйле эшкә җитди карарга киңәш итәм. Зур сумма алмасагыз да, аны кайтарасын уйлагыз. Һәр тиен кадерле. Шикле оешмалардан акча алып торыр алдыннан, берничә кат уйларга кирәк, – дип кисәтте Дмитрий Богумель.

Истә тот:

✓ фатирга көч кулланып керү тыела, бу да канун бозу санала;
✓ коллекторлар әҗәтле кешенең эш урынына килә икән, бу да – канун бозу. Андый очракта ярдәм сорап, хокук саклау органнарына да хәбәр итәргә була;
✓ үтерү, кыйнау, җәрәхәтләү кебек янаулар өчен дә закон буенча җавап бирәсе. Милекне җимерү, юк итү, ут төртү кебек гамәлләр дә тыела;
✓ андый күңелсез хәлләр килеп чыккан икән, полициягә мөрәҗәгать итәргә була. Дәлил итеп, фото-аудио-видеоязмалар, бу хәлнең шаһиты булган кешеләрнең күрсәтмәләре файдаланыла.

Сәяси сәгать

ЖУРНАЛИСТ АЛЬБЕРТ ШАКИРОВ:

«Бу вакыйгаларның килеп чыкмый хәле юк иде»

Без әле кая барабыз? Дөньяда ниләр бар? Бу сорауларга җавапны журналист, блогер Альберт ШАКИРОВ белән эзлибез.

:: Альберт, бу арада халык Сабан туе дип мәш килә. Авылларда, шәһәрләрдә бәйрәм итәләр, башка төбәкләргә, хәтта чит илләргә барып чыгабыз. Сабан туе безне әле дә берләштерәме?

– Сабан туеның берләштерү көче авылда сизелә. Туган авылым Сабан туенда булдым, Бәрәскәгә барып кайттым. Алар әле җыйнак, артык тавышсыз уза. Кызганыч, быел күрше Мари Илендәге Бәрәңге районына чыгып булмады. Аларда Сабан туйлары элекке гадәт белән ихлас уза. Шоу-тамашага әйләнмәгән. Без сагынган авыл Сабан туйлары рәвешендә оештыралар. Менә ул чыннан да берләштерә. Авылда кеше калмаса да, җыелып кайтып, үзләре уздыра. Зур бәйрәмнәр, кызганыч, күбрәк зур концертка әверелә бара. Сабан туена барыр алдыннан, кем килә, дип кенә сорыйлар хәзер. Танылган җырчы килсә генә чыгабыз, янәсе.

Читтәге Сабантуйларга килгәндә, алар Татарстанның визит карточкасы булып калсын инде. Әмма татар мәдәниятен, гореф-гадәтен дөнья күләмендә күрсәтү өчен бу гына җитми. Мәдәни мирасыбыз реестрларга керсә, халыкара оешмаларның игътибарын җәлеп итсә, яхшырак булыр иде. Дөньялар болай гына бармас, чикләр кайчан да булса барыбер ачылачак бит инде.

:: Игътибар димәктән, соңгы көннәрдә Татарстан турында күп сөйләделәр. Әйтик, Санкт-Петербургта узган икътисади форумда күп килешүләр төзелде. Шунда ук безгә 2024 елда буласы «Киләчәк Уеннары»н оештыруны ышанып тапшырдылар. Берничә көн элек Президент Рөстәм Миңнеханов Владимир Путин уздырган киңәшмәдә барлык губернаторлар исеменнән чыгыш ясады. Мондый игътибарның асылы нидән гыйбарәт?

– Рөстәм Миңнеханов федераль дәрәҗәдә катнашкан комиссия һәм эш төркемнәрен саный китсәң, бик зур исемлек килеп чыга. Мондый игътибар быел гына барлыкка килмәде. Шул ук Санкт-Петербургта тик торганнан гына 40 килешү имзаламыйлар бит инде. Татарстанның икътисади яктан нәтиҗәле эшләвен, алдынгы төбәк булуын таныйлар. Рөстәм Миңнеханов төзелеш яки спорт кына түгел, башка юнәлешләрдә дә эшли. Безнең Президент – федераль дәрәҗәдәге дәүләт эшлеклесе. Россиядә аның фикерен тыңлыйлар. Электән килгән эш нәтиҗәсе бу.

:: Бүгенге шартларда бу игътибар тагын да артачак кебек.

– Җирле үзидарә турында закон бар. Безнең әни шул өлкәдә эшләгәч, әлеге закон искә төшкән саен, болай дип әйтә иде: «Шуның кадәр яхшы закон бу. Барысы да тәфсилләп язылган. Бирелгән вәкаләтләр янына бераз гына акчасын да өстәсәләр икән». Кыскасы, төбәкләргә вәкаләтләр күп бирелгән. Шулар янына бюджетының булуы кирәк. Бу мәсьәләдә үзгәреш булыр дип уйлыйм. Чөнки һәрбер төбәк, бигрәк тә хәзерге шартларда, эшне тиз арада башкарып чыга алмый икән, алга китеш булмаячак. Моңа кадәр «гайка»ларны тыгызлап килделәр, хәзер аларны кире бушатмыйча хәл юк. Һәрбер төбәк үзе башын эшләтә торган чор. Мәскәү нәрсә әйтер икән, дип утыра торган вакыт түгел. Документыңны алып, чемоданыңны асып барып, үзең сорап алырга кирәк. Татарстанның бу мәсьәләдә тәҗрибәсе бар.

:: Сине авыл белән ике арада йөри торган кеше дип беләбез. Сала кешесе дөньяда булып яткан вакыйгалар белән ни дәрәҗәдә кызыксына?

– Печән җитәрме, ашлык, сөт бәяләре ничек үзгәрер, ягулыгы, ашламасы булырмы? Авыл кешесен иң элек әнә шулар борчый. Халыкның яшәеше шул килеш. Авыл кешесе үз көен үзе күрә ул, үз тамагын үзе туйдыра. Хуҗалыгы бар икән, шуңа таянып яши. Эшләргә, үз көченә таянырга күнеккән. Дөньядагы хәлләр артык дулкынландыра дип уйламыйм. Нәрсәгәдер өметләнсә дә, артыгына ышанмый.

:: Владимир Путинның матбугат сәркатибе Дмитрий Песков, NBC каналы хәбәрчесе белән сөйләшкәндә, мондыйрак сүзләр әйткән: «Бу кризис озакка сузылачак. Без кабат беркайчан да Көнбатышка ышанмаячакбыз». Ничек уйлыйсың, кая барып чыгарбыз?

– Бу хәлләр икътисади яктан үзен нык сиздерәчәк һәм бик озакка барачак. Монысы көн кебек ачык. Хәтта Үзәк банк та өметле фаразлар бирми, сабыр булырга, итәкләрне җыебрак йөрергә киңәш итә. Сәясәт өлкәсенең исә тиз генә төенләнеп, тиз генә чишелә торган гадәте бар. Без хәтерләгән чорда гына да АКШ белән мөнәсәбәтләр күп мәртәбә үзгәрде. Ызгышы да булды, «перезагрузка» дип аталган төймәгә дә бер генә басылмады. Сәясәттә бүгенге сүзнең иртәгә ярамаган вакытлары да бик күп. Бүрекне кырын салып, «без болар белән сөйләшмибез» дигән вазгыять озакка бармас дип уйлыйм. Йомылып, ябылып яши алмыйбыз. Дөнья да Россиясез яши алмый. Дөньяда барысы да бер-берсенә бәйле. Шуңа күрә кайчан да булса чишеләчәк. Әмма көчләр балансы башка якка авышырга мөмкин. Үзгәрешләр заманында яшибез. Бу вакыйгаларның килеп чыкмый хәле юк иде. Дөнья шул чиккә килеп җиткән иде. Хәзер иң мөһиме – минималь югалтулар белән уздырып җибәрү. Песков, Лавровлар әйткән сүзләр – дипломатия теле ул. Катырак әйтеп, сигналлар җибәрү омтылышы. Шау-шу бар, әмма барыбер сөйләшергә туры киләчәк.

Әңгәмәдәш – Илнар ХӨСНУЛЛИН

КЫЙММӘТЛЕ АЧКЫЧ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин Россиядә ташламалы ипотека буенча процент ставкасын еллык 9 проценттан 7 процентка кадәр киметү турында карар имзалады. Ташламалы кредитның максималь суммасы Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре, Мәскәү һәм Ленинград өлкәләре өчен – 12 миллион сум, ә Россиянең башка төбәкләре өчен 6 миллион сум тәшкил итә.
Хөкүмәт Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин исә кулланылган фатир алучыларга да ярдәм кирәклеген әйтә. «Яңа торакны сатып алуга ярдәм итү генә түгел, ә икенчел торакны тизрәк финанслау өчен механизмнар табу да мөһим. Шунсыз яңа торакны сату да кыен булачак», – диде ул Президент Владимир Путин уздырган киңәшмәдә.

Гел кайнап торыр кебек тоелган торак базарына да авыр көннәр килде. Фатирларның яңаларын да, искеләрен дә алучы юк. Июнь аеның беренче ике атнасында Казанда нибары 61 фатир сатылган. Төзүчеләр күзгә таба вазгыять бераз җайланмасмы дип өметләнә. Белгечләр исә башка фикердә.

Фатир кайгысы түгел

Май аенда Казанда 800 миллион сумга 687 фатир сатылган. Июньнең беренче яртысында исә башкалада 200 миллион сумга 61 фатир гына сатылган. Араларында бу ике айда бер фатир сата алмаган төзүчеләр дә бар. «Сравни Дом» милек аналитиклары агентлыгы мәгълүматлары шул хакта сөйли. Бер ай эчендә Татарстанда төзелештә өлешләп катнашу турында төзелгән килешүләр дә 72 процентка кимегән.

Төп ставканың ел башындагы күрсәткечләргә кире әйләнеп кайтуы да вазгыятьне үзгәртә алмаган, димәк. Хәтерләсәгез, 1 март көнне Россия Үзәк банкы төп ставканы 9,5 проценттан 20 процентка кадәр арттырып куйды. Үзәк банкның көтелмәгән хәбәреннән соң банклар барлык төр кредит һәм кертемнәргә ставканы арттырды. Ипотека ставкалары 15–20 процентка ук җитте. Соңрак Үзәк банк төп ставканы берничә тапкыр киметеп, 17, 14, соңрак 11 процентка калдырды. Әле күптән түгел генә ул янә 9,5 процентка кадәр төште.

Финанс аналитигы Александр Гусев торак базарын катлаулы хәлдә калдырган берничә сәбәпне атый. «Халыкның керемнәре әле дә булса үзгәрешсез кала бирә. Дәүләт программасы белән ипотека рәсмиләштерә алсаң, азмы-күпме отасың әле. Әмма ул «бәхет» тә бөтен кешегә тәтеми. Ә инде 11–12 процент белән рәсмиләштерелгән ипотеканы һәркем тарта алмый. Иртәгәге көнгә ышаныч булмау да үз эшен башкара. Андый чакта берәүнең дә, муеннан әҗәткә батып, кредит тозагына керәсе килми, билгеле. Бу сезонлы күрсәткеч тә булырга мөмкин. Җәйге яллар чоры башлану белән кешедә фатир алу, яңарту кайгысы калмый», – дип белгеч.

Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов та торак базарындагы хәлләрне халыкның керемнәре киму белән аңлата. «Төзүчеләр тарафыннан ясалган ташламалар да сатылган фатирлар санын арттырырга ярдәм итә алмый. Бүген фатир алучылар аның бәясеннән бигрәк, айлык түләүнең күпме булачагына игътибар итә. Хәзерге процент ставкалары белән бик зур сумма килеп чыга бит. Андый айлык түләүне каплап бару күп кенә гаиләләрнең көченнән килми», – ди белгеч.

Күзгә ышаныч юк

Тәҗрибәле риелтор Дамир Сафиуллин сүзләренә караганда, төп ставка ел башындагы күрсәткечләргә кайту белән торак базары бераз җанлана башлаган. Әмма бу зурдан кубып сөйләрлек үзгәрешләр түгел. «Ипотека рәсмиләштереп, фатир алырга теләүчеләр бар, әмма бүгенге бәяләр белән ул күп кешенең көченнән килми. Шуңа күрә торак базарында ихтыяҗ түбән булып кала бирә», – ди белгеч.

Ипотека ставкалары да төшкән. Хәзер аны уртача 10,5–11 процент белән рәсмиләштерергә мөмкин. «Күзгә таба ипотека ставкаларының нинди булачагын фаразлау кыен. Бар нәрсә төп ставкага барып тоташа. Бүген ул 9,5 процент тәшкил итә. Узган елның шушы чорында Үзәк банкның төп ставкасы 4,5 процент тәшкил итә иде. Ул чакта ипотеканы, ким дигәндә, 7–7,5 процент белән рәсмиләштерергә мөмкин иде», – ди белгеч.

Төп ставка төшү белән икенчел торак базарындагы фатирлар да очсызлана башлады. Дамир Сафиуллин сүзләренә караганда, бүген алар уртача 5 процентка арзанайган. Бу бәяләр җәй азагына кадәр сакланыр дип фаразлый ул. «Милекчеләргә, фатир сатканда, бәяләрне шактый төшерергә туры килә. Юкса фатир бик озак сатылачак. Әмма аларның барысы да фатир бәясен төшерергә әзер түгел. Тагын бер айдан фатирының тагын да арзанаячагын аңлаган кеше, ничарадан бичара, моны эшләде инде. Кемдер сатуга куйган фатирының бәясен – 5 процентка, кемдер 10 процентка төшерде», – ди риелтор.

Яңа фатирлар базарындагы вазгыять исә башкачарак. Бередә торак бәяләре үзгәрешсез калган. Ник дигәндә, яңа төзелгән йорттан фатир алучыларга дәүләт тарафыннан субсидияләнгән кредитлар бирелә. Бүген ташламалы дәүләт программасы буенча ипотеканы 6,7 процент белән бирәләр. Аның буенча 6 миллион сумга кадәр кредит бирелә. Өстәвенә аларга еш кына төзүчеләр үзләре дә ташлама ясый. Аптыраган үрдәк суга арты белән чума дигәндәй, аларның кайберләре фатир хакының 10 процентын түләп бирергә үк вәгъдә итә. Әйтик, кулындагы фатирның 5 проценты куләмендә акчаң булса, фатирның тагын 10 процентка кадәр өлешен төзүче оешма каплый булып чыга. Фатир хакының калган өлешенә ипотека рәсмиләштереп түләп бетерәсе булачак.

Дамир Сафиуллин торак шартларын яхшыртырга теләгән кешегә хәзер моны эшләү өчен иң кулай вакыт дип саный. «Күзгә таба торак базарында нәрсә булачагын фаразлыйсы кыен. Бүген хәтта киләсе айда нәрсә булачагын да чамалап булмый. Әгәр кешенең кулында акчасы бар икән, фатирны хәзер алып кую яхшы. Күреп торабыз: вазгыять катлаулы. Мондый шартларда булган акчаны күчемсез милеккә тотудан да яхшысы юк. Акча үз кыйммәтен югалта ала. Артык акчаны депозитка салып куюдан да мәгънә юк. Бүген аларның процентлары бик түбән», – ди белгеч.

Юрганыңа карап сузасы

Елның-елында көзен торак базары җанланып ала. Ник дигәндә, җәйге ялга киткән студентлар кабат калага юл тота. Шуңа бәйле рәвештә башкалада фатир арендалауга да сорау арта. Соңгы елларда мөмкинлеге булган ата-ана студент баласына кечкенә генә гостинка яки бер бүлмәле фатир алып бирергә тырыша. Әмма белгечләр, быел моның да сирәк күренеш булыр, дип фаразлый. Дамир Сафиуллин бу очракта да аякны юрганга карап сузарга киңәш итә. «Әгәр беренчел кертемгә җитәрлек акча бик аз булса, шуның аркасында ипотеканың айлык түләве 30 меңнән артса, студентны вакытлыча фатирга кертеп укытуың отышлырак, билгеле. Бер бүлмәле фатир өчен 30 мең сум кредит түләп яшәгәнче, шул ук бер бүлмәле фатирны 15 мең сумга арендалап торуың отышлырак чыга», – ди белгеч.

Соңгы арада Казанда фатир бәяләре яшен тизлегендә үсте. Дамир Сафиуллин сүзләренә караганда, соңгы бер ел эчендә алар 20 процентка кыйммәтләнде. «Шуңа күрә аларга сорау да кимеде. Алучы булмагач, фатир бәяләре тора-бара барыбер төшәчәк. Шуңа күрә якын киләчәктә фатир бәяләре 2020–2021 елдагы хакларга калыр дип уйлыйм. Акрынлап шуңа барабыз», – ди риелтор.

Шулай да соңгы арада күпләр үз йорты белән яшәүне өстенрәк күрә башлады. Рәсми саннардан күренгәнчә, соңгы өч айда шәһәр яны йортларына ихтыяҗ 30 процентка арткан. «Соңгы арада дәүләт үз йортында яшәргә теләүчеләргә дә ярдәм итә башлады. Гаилә ипотекасы, авыл ипотекасы программасы буенча йорт төзергә, төзетергә була. Өстәвенә төзүчеләр йортлы булырга теләүчеләргә дә яхшы ук ташлама ясый. Хәзер үз көче белән йорт җиткерергә теләүчеләргә дә 9 процентлы ипотека бирә башладылар. Дөрес, әлегә аны «Дом.РФ» һәм «Саклык банкы»нда гына рәсмиләштерергә мөмкин. Әле бер ел элек кенә үз йортын төзүчеләр өчен мондый мөмкинлекләр юк иде. Йортны үз акчаңа, яки милекне залогка кую хисабына кредит рәсмиләштереп кенә алып була иде», – ди Дамир Сафиуллин.

Сүз уңаеннан, соңгы арада Россиядә автокредит рәсмиләштерүчеләр саны арткан. Май аенда банклар әлеге төр кредитларны апрель ае белән чагыштырганда 48 процентка күбрәк биргән. Язның соңгы аенда Россиядә 36,7 млрд сумлык автокредит рәсмиләштерелгән. Бүген ил халкы, нигездә, тотылган машиналарга өстенлек бирә, ди белгечләр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ФАТИР САТЫП АЛЫРГА ҖЫЕНУЧЫЛАРГА БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ

➤Фатир сатып алганда, бу юнәлештә эшләгән белгечкә мөрәҗәгать итү хәерле. Риелтор сезгә беренчел базардан яхшы процент ставкалы кредит рәсмиләштерергә, икенчел базардан фатирны зур ташлама белән сатып алырга ярдәм итә алачак.

➤Бүген икенчел базардан торак сатып алганда алдану куркынычы да артты. Ник дигәндә, милекче банкротлыкка чыккан яки банкрот хәлендә булырга мөмкин. Шуңа күрә фатир сатып алганда документларны юридик яктан яхшылап тикшерергә, килешүне дөрес итеп тутырырга кирәк. Шуңа күрә монда белгечтән башка булмый.

➤Хәзер фатир алып калу өчен кулай вакыт. Кулыгызда «тере» акча булса, икенчел базардагы торакны карарга киңәш итәр идем. Фатир хакының бик аз өлешенә генә кредит алган очракта да шушы төркемгә кергән фатирларга өстенлек бирү хәерлерәк. Ник дигәндә, бүген икенчел торак базарында бәяләр түбән тәгәрәгәндә, отышлы гына бәядән фатир алып калырга була. Кулдан фатир алганда, бәяне тагын бераз төшертеп тә була. Яңа төзелгән йортлардагы фатирларны да бик яхшы процент ставкалы кредит нигезендә алырга була. Әйтик, бүген хәтта өч бүлмәле фатирны да айлык түләве 16900 сумнан да артмаслык кредит шартларында эләктереп калырга мөмкин.

Казанда яңа төзелгән йортларда бер квадрат метр бәясе (RealtyMag.ru мәгълүматлары нигезендә)

	Гыйнвар	Июнь	Үсеш
Авиатөзелеш	117,5 мең сум	142,7	21%
Вахитов	133,8 мең сум	175	31%
Киров	104,4 мең сум	154,5	48%
Мәскәү	мәгълүмат юк	мәгълүмат юк	мәгълүмат юк
Яңа Савин	164,3 мең сум	191,5	17%
Идел буе	122,4 мең сум	141,3	15%
Совет	139,1 мең сум	167,8	21%

1 июльдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Зөһрә Садыйкова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Салютлы җирләү рөхсәтме?

«Кайнар нокта»лардан яшь солдатларның мәетләрен туган җирләренә кайтаралар. Алар арасында ислам динендәгеләр дә, христиан динендәгеләр дә бар. Мөселман егетләрне татар авылларындагы зиратларда җирлиләр. Мәетне кабергә төшергәндә мылтыктан атып торалар. Дин әһелләре бу гамәлне ничек бәяли икән?

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ.
Казан

Айморат хәзрәт Хаҗиев, «Мәрҗани» мәчетенең икенче имамы:
– Армиянең үз системасы, эчке кануннары, гадәтләре бар. Һәлак булган хәрбиләрне шул рәвешле данлыйлар. Әлбәттә, хәрбине дин шартларына туры китереп җирлиләр икән, мылтыктан атуның зыяны юк. Андый гадәтне юкка чыгарып булмый. Иң мөһиме, әйтүемчә, мәетнең динебез шартларын үтәп җиргә индерелүе. Пәйгамбәребез (с.г.в) чорында да сугышлар булган.

Исем кемгә бирелә?

Әллә нигә бер кан бирәм. Почетлы донор исемен алырга мөмкин дип ишеттем. Аның өчен нишләргә? Ул кемнәргә бирелә?

РОЗАЛИЯ.
Казан

Руслан Шекуров, «DonorSearch» проектына нигез салучы:
– 40 мәртәбә һәм аннан да күбрәк кан, 60 тапкыр һәм аннан да күбрәк плазма, 25 мәртәбә кан (аннан да күбрәк) һәм 40 мәртәбә плазма, 25тән азрак кан һәм 60 мәртәбә плазма тапшырган кешеләр бу исемгә лаек булырга мөмкин. Почетлы донорга түбәндәге ташламалар каралган: ял, дәүләт учреждениеләрендә медицина ярдәме һәм санаторий-курортка юллама. Моннан тыш еллык түләү. 2022 елда ул 15713 сумны тәшкил итә.

Фикер

***

Хөрмәтле «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе!

«Ватаным Татарстан» газетасы белән озак еллардан бирле танышып барам. Минем өчен бигрәк тә газета битләрендә аналитик мәкаләләр бирелүе ошый.

Соңгы елларда бигрәк тә Рәшит Фәтхрахмановның икътисади, сәяси-иҗтимагый темаларга язылган аналитик мәкаләләрен яратып укып барам. Теманы тирәнтен өйрәнеп, анализлап язган мәкаләләре өчен авторга зур рәхмәт! Киләчәктә дә укучыны мавыктыргыч язмалары белән таныштыруын көтеп, иҗатында зур уңышлар, ныклы сәламәтлек теләп калам!

Шәүкәт ХӨСӘЕНОВ.
Кукмара районы Зур Сәрдек авылы

***

«Ватаным Татарстан»ның һәрбер сәхифәсе ошый. Һәркайсына шактый урын бирелә. Тема белән кызыксынган кешегә шактый мәгълүмат алырга була. Яңалыклар өлешен яратам, сәяси вакыйгаларга, көнүзәк мәсьәләләргә игътибар бирәсез. Соңгы арада икътисадка бәйле кызыклы мәкаләләр дә басылды. Халыкка аңлаешлы тел белән язылган иде алар. Дин дә, артистлар, язучылар тормышы да укучы өчен кызыклы. Мин газетаны соңгы битеннән укырга яратам, иң тәмлесен азакка калдырам. Риман абый Гыйлемхановның мәкаләләрен яратып укыйм. QR-кодлар куллануыгыз отышлы. Уйлы, фикерле укучы рәхәтләнеп сезнең белән яши ала!

Эльвира ИХСАНОВА.
Азнакай районы Урманай авылы

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Укучы сүзе

«ТЫНЫЧ ЙОКЛАГАН ЧАК СИРӘК» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ
Рузилә – бик тырыш, үз эшенең остасы. Авылда аны хөрмәт итәләр. Күп еллар инде авыл халкына тугры хезмәт итә. Төн уртасында да аңа тыныч йокларга юк. Авырулар шалтыратуга килеп җитә.

Фаягөл СӨНГАТОВА

«БУЛГАНДА, НИК БИРМӘСКӘ?» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ
Бик күркәм гамәл. Мин үзем яши торган күпкатлы йортта әлеге гамәлне керттем. Кешегә кирәкмәгән кием-салымнарны, аяк киемнәрен, пыяла банка, балалар уенчыкларын, хәтта гөлләргә кадәр йортыбызның беренче катына төшереп куябыз, кемгә нәрсә кирәк, сайлау мөмкинлеге бар. Әле бер нәрсәнең дә чүплеккә чыгарып ташланганы юк. Хәтта җиһазлар да булгалый.

Шәргыя ФӘТИЕВА

КҮЧМӘ МИЧ ЯСАГАН РИФКАТЬ КАМАЛОВ ТУРЫНДА ЯЗМАГА КАЙТАВАЗ
Рифкать – безнең Кариленең данлыклы егете ул. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, диюләре нәкъ менә аның турында. Кулыннан алтын коела. Афәрин, күршем, яшьтием, балачак дустым!

Рәхилә ЗӘЙНУЛЛИНА-ХӘСӘНОВА

САНДЫК ЯСАУ ОСТАСЫ РӘЙХАТ САФИУЛЛИН ТУРЫНДА ЯЗМАГА КАЙТАВАЗ
Сандык – үзе бер байлык. Минем дә әткәем заманында бик күп кызларга ясап бирде аны. Бик нәфис эш. Әле элек калае да юк иде бит аның, тактасын да сайлап кына эшли иде.

Зәмзәмия РӘХМӘТУЛЛИНА

***

1975 елны кияүгә урладылар. Әткәй-әнкәйгә зур рәхмәт, сандык тутырып бирнә белән озаттылар. Ул вакытта сандык белән кияүгә бару гадәте иде бит.

Зөлфия ЧИРАЕВА

***

Кулларына күз тимәсен. Минем кияүгә чыккандагы сандыгым әле дә саклана. Без инде 50 ел гомер итәбез. Сандык һаман да өр-яңа кебек. Тагын да безне куандырып, яшәртеп торсын туй сандыгыбыз.

Гөлсинә ХӘЛИУЛЛИНА

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Оештыручылар – «Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте

Үзегез яшәгән җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында «Ватаным Татарстан» газетасына «бәйге» дигән тамга белән язмалар юллый аласыз.
Бәйгедә өч урын билгеләнәчәк. Аларны бүләкләү түбәндәгечә:
I урын – 10 мең сум;
II урын – 7 мең сум;
III урын – 5әр мең сум күләмендә ике премия.
Бер җиңүчегә Татарстан Диния нәзарәтеннән 10 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылачак.

Бәйгенең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе.

БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ:
«Безнең авыл имамы» бәйгесенә язмалар 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 10 июленә кадәр кабул ителә. Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин. Бәйгегә башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта 3 биттән (юл арасы – 1,5 интервал) артмаска тиеш.

Материаллар 420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт адресы буенча яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. **Белешмә өчен телефон: (843) 222-09-70, 8 917-927-00-40.** Бәйгедә катнашучының 2022 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция күчермәсе редакциягә язма белән бергә җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат www.vatantat.ru сайтында.
2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 1 августына кадәр дәвам итә.
Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Реклама. 16+

27 июнь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 15.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ 2» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл батл» 0+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 Телевизионный фильм о национальных праздниках народов Татарстана 6+
19.00, 20.00, 01.05 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Уроки истории». Казанское ханство 6+
00.40 «Каравай». Сохраняя традиции. Ильдар Хайруллин 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Фәннур Сафин турында телеочерк 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 К 100-летию нелегальной разведки. Премьера. Агния Дитковските, Александр Устюгов. «МИССИЯ «АМЕТИСТ» (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
23.40 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер» 12+
23.55 К юбилею Карена Шахназарова. Елизавета Боярская, Виталий Кищенко, Кирилл Гребенщиков. «АННА КАРЕНИНА» 12+
00.55 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ» 12+
02.45 «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.30, 14.50, 16.50, 18.55 Новости
06.05, 22.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.10 «Кубок PARI Премьер». Специальный репортаж 12+
09.30 Футбол. Кубок PARI Премьер. «Сочи» – «Зенит» (Санкт-Петербург). Трансляция из Санкт-Петербурга 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35 Специальный репортаж 12+
12.55, 14.55 «ПОБЕГ» 16+
15.50, 16.55 «Человек президента» 16+
17.50 «Громко». Прямой эфир
19.00 Смешанные единоборства. One FC. Ислам Муртазаев против Регьяна Эрселя. Трансляция из Сингапура 16+
20.00 Профессиональный бокс. PRAVDA FC. Дмитрий Кудряшов против Вагаба Вагабова. Трансляция из Москвы 16+
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
23.15 «13 УБИЙЦ» 16+
01.45 «Есть тема!» 12+
02.05 «Karate Combat 2022. Эпизод 4» 16+
03.40 Новости 0+
03.45 Вольная борьба. Чемпионат России. Трансляция из Кызыла 0+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) 6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ» (S) 16+
21.45 Премьера. «ПЕРЕСУД» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
02.45 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Затворницы» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ВСПОМИНАЯ ТЕБЯ» 16+
19.00 «ДОЛГАЯ ДОРОГА К СЧАСТЬЮ» 16+
22.35 «Порча» 16+
23.05 «Знахарка» 16+
23.40 «Верну любимого» 16+
00.15 «Понять. Простить» 16+
01.15 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 1-я и 2-я серии 16+
02.55 «Тест на отцовство» 16+
04.35 «Давай разведёмся!» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «БЛАГОСЛОВИТЕ ЖЕНЩИНУ» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.35 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ» 12+
11.20, 18.50 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 14.05 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
20.50 Новости дня 16+
21.50 «Загадки века». Док. сериал. «Как передавали Крым Украине. Мифы и реальность» 12+
22.40 «НЕСЛУЖЕБНОЕ ЗАДАНИЕ» 16+
00.30 «ДЕЙСТВУЙ ПО ОБСТАНОВКЕ!» 12+
01.35 «ЗАБУДЬТЕ СЛОВО СМЕРТЬ» 12+
02.55 «В ДОБРЫЙ ЧАС!» 12+
04.30 «Перелом. Хроника Победы» 16+
05.00 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+

28 июнь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
10.00, 00.30 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ 2» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.10 Телевизионный фильм о национальных праздниках народов Татарстана 6+
01.15 «Видеоспорт» 12+
01.40 «Соотечественники». Кибитка Пушкина 12+
02.05 «Каравай». Национальный марийский костюм 6+
02.30 «Манзара» 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Гомәр Бәширов турында телеочерк 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «МИССИЯ «АМЕТИСТ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.55 К юбилею Карена Шахназарова. Елизавета Боярская, Максим Матвеев, Виталий Кищенко, Кирилл Гребенщиков, Виктория Исакова, Татьяна Лютаева. «АННА КАРЕНИНА» 12+
00.55 Ольга Иванова, Никита Тезин, Юрий Батурин, Александра Мареева, Мария Порошина, Сергей Никоненко. «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ» 12+
02.45 «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.30, 14.50, 16.50 Новости
06.05, 20.00, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.35 Специальный репортаж 12+
09.20 Футбол. Лига Европы. «Ливерпуль» (Англия) – «Боруссия» (Дортмунд, Германия) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55, 14.55 «ПОБЕГ» 16+
15.50, 16.55 «ЧЕЛОВЕК ПРЕЗИДЕНТА: ЛИНИЯ НА ПЕСКЕ» 16+
17.50, 20.50 Футбол. Чемпионат Европы среди юношей (U-19). 1/2 финала. Прямая трансляция из Словакии
23.45 Бокс. Bare Knuckle FC. Элвин Брито против Луиса Паломино. Трансляция из США 16+
00.50 «Есть тема!» 12+
01.10 Футбол. Кубок Либертадорес. 1/8 финала. «Эмелек» (Эквадор) – «Атлетико Минейро» (Бразилия). Прямая трансляция
03.25 Футбол. Кубок Либертадорес. 1/8 финала. «Коринтианс» (Бразилия) – «Бока Хуниорс» (Аргентина). Прямая трансляция

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) 6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ» (S) 16+
21.45 «ПЕРЕСУД» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
02.40 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Проклятый автомобиль» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «СЛЕПОЙ ПОВОРОТ» 16+
19.00 «КОМПАНЬОНКА» 16+
22.40 «Порча» 16+
23.10 «Знахарка» 16+
23.40 «Верну любимого» 16+
00.15 «Понять. Простить» 16+
01.15 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 3-я и 4-я серии 16+
02.55 «Тест на отцовство» 16+
04.35 «Давай разведёмся!» 16+
05.25 «6 кадров» 16+
05.30 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

06.55 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20 «Освобождение» 16+
09.45 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ» 12+
11.20, 18.50 «Открытый эфир» 16+
13.25, 14.05 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
20.50 Новости дня 16+
21.50 «Без права на славу». Док. фильм. Премьера! 16+
22.55 «ВЗРЫВ НА РАССВЕТЕ» 16+
00.35 «НЕЖНЫЙ ВОЗРАСТ» 12+
01.55 «РОЗЫГРЫШ» 12+
03.30 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+
04.50 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
05.00 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ

27 ИЮНЬ – 3 ИЮЛЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Бу атна тулысынча һөнәри эшегез турында уйлап, кайгыртып, мәшәкатьләнеп үтәр. Элеккеге эшлекле дусларыгыз белән элемтәләрне яңартып җибәрү кирәк булыр. Алар сезгә акчалы хезмәттәшлек тәкъдим итәргә мөмкин.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Билгесезлекнең аяк чалуы бар. Нәрсә теләгәнегезне беләсез аныса, тик менә бер шикләнү генә... Хафаланмагыз: якыныгыз шик-шөбһәләрегезнең урынсыз булуын бик төгәл аңлатып, күңелегезгә тынычлык иңдерер.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Бал кортлары кебек, бертуктаусыз тыз-быз килеп эшләргә кирәк булыр. Канәгатьлек хисе әллә ни китермәсә дә, шәп кенә әҗере белән куандырыр бу. Тормышыгызга бераз җиңеллек китереп, яңачарак сулыш өрердәй хәлләр көтегез.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Җәй сез теләгәнчә үк башланып китмәде бугай. Шулаймы? Аның каравы ай ахыры ничектер шәп узар. Теләгәнегез тормышка ашып, үзегезне бу дөньядагы иң бәхетле кеше итеп тоюга китерер.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Вакытны үзегезгә багышлау: өс-башны карау, хатын-кызларга – матурлык салонына барып килү, ир-атларга – гәүдәнең төзелеген, ныклыгын кайгырта башлау өчен искиткеч шәп атна. Тик менә кешеләр белән аралашу авыррак туры килер: ачык кына итеп әйтелмәгән сүзләрнең төбендә нәрсә ятуын шундук аңламассыздыр.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Бу атнада яшен алдыннан тынлык урнашкан кебек. Хәер, яшен дигәнебездән куркасы юк, киләсе атнада баштанаяк эшкә күмелергә туры киләчәк дигән сүз генә бу. Әлегә үзегезне карап, дөньяга хозурланып, ял итә-итә генә эшләрсез.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Күңелегездә көнчелек кузгалу сөеклегез белән араларны бераз гына суытып җибәрер. Ләкин тикмәгә икәнен тиз генә абайлап, мөнәсәбәтләрне үз җаена кайтаруга ирешерсез.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Гаиләгездә үзегезне рухи яктан әйтеп бетергесез канәгатьлек хисенә күмәрдәй хәлләр булып алыр. Бер танышыгызның киңәше чираттагы ялны кайда уздырачагыгызга ачыклык кертер. Атна ахырында күчемсез милек буенча әйбәт яңалык ишетелер.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Барысын да аңлап калу һәм барысын да белеп тору теләгеннән читкә куеп тору хәерле. Беренчедән, барыбер берни аңламаячаксыз (аңларлык әйбер булмагач...), икенчедән, нәрсә бу, кайдан, ничек шулай килеп чыккан, дип баш катырып тормыйча, килеп туган мизгелдән, ниһаять, канәгатьлек хисе алырга өйрәнәчәксез.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Сөеклегезгә үзен күрсәтү мөмкинлеге бирегез. Ничек тели – шулай! Юкса аралар салкынаеп китәргә мөмкин. Атна ахырында бер көнкүреш мәсьәләсе баш мие күзәнәкләрен ныклап эшләтеп алырга мәҗбүр итәр.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Кемнәргәдер ярдәм итәргә туры килер. Кирәк булган өчен генә йөрү күңелегездә канәгатьсезлек уятыр. Ләкин озакка түгел. Хәлләр кисәк кенә сезнең файдага үзгәрер һәм бу, әлбәттә, шундук кәефегездә чагылыш табар.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Ниндидер бер максатка таба бик озак бардыгыз. Үзегезне аямыйча, эшләдегез дә эшләдегез түгелме? Хәзер менә шул хезмәтегезнең бик тә матур әҗерен күрер чак!

УВЕДОМЛЕНИЕ ЧЛЕНОВ СНТ «САЙЯР»
Ахатова Н.Г. уведомляет членов СНТ «Сайяр» о намерении обратиться в суд с иском о признании недействительным решения общего собрания СНТ «Сайяр» от 22.04.2022 г. ввиду допущенных существенных нарушений порядка принятия решения о проведении, порядка подготовки и проведения заседания общего собрания, допущенного нарушения равенства прав участников.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Редакция белдерүләрнең эчтәлеге өчен җавап бирми.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БЫГЫРДАМЫЙ, КИСӘТӘ

Эчнең һич көтмәгәндә быгырдый торган гадәте бар. Еш кына аны тамак ачу белән бәйләргә күнеккән без. Әмма белгечләр эчнең мондый көйсезлеге җитди чирләр турында да кисәтергә мөмкин дип ышандыра. Кайсы очракта чаң сугарга? Эч быгырдауны алдан кисәтеп буламы?

Табиб-гастроэнтеролог, инфекционист, педиатр Наилә ДРОЗДОВА шушы сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Эч быгырдауны мөстәкыйль авырулар рәтенә кертеп буламы?

– Эч быгырдау ашказаны, эчәк авырулары турында кисәтүче бер билге булып тора. Табиблар аны аерым бер чиргә санамый. Фәнни телдә ул борборигм дип йөртелә. Организмдагы ашкайнату процессы һәрчакниндидер тавышлар белән уза. Бу эчәклек стенкалары кыскару белән бәйле. Гади телдә ул эч быгырдау дип йөртелә. Эч быгырдауга китергән берничә сәбәпне атарга мөмкин.

:: Эч быгырдау борчыганда табибка мөрәҗәгать итәргә кирәкме? Әллә аннан үзлегеңнән генә дә котылып буламы?

– Табиб буларак, мин теге яки бу билге күзәтелә башлауга ук белгечкә күренергә киңәш итәм, билгеле. Ә эч быгырдау, әйткәнемчә, ашказаны-эчәк авырулары турында кисәтергә мөмкин. Үз-үзеңне дәваларга маташу – зур хата. Халык медицинасына да, табиб сезне тикшереп, төгәл диагноз куйган очракта гына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Эч быгырдау – табигый халәт кенәме, әллә берәр чирнең билгесеме? Иң элек әнә шуны ачыклау мөһим. Шуңа күрә эч быгырдау борчыганда башта табиб-гастроэнтерологка мөрәҗәгать итәргә, корсак куышлыгына УЗИ ясатырга, биохимик, гомуми кан анализы, бәвел тапшырырга, копрограмма узарга кирәк.

:: Метеоризм, эч быгырдау ниндидер җитди чир, әйтик, яман шеш билгесе дә була аламы?

vk.com

– Әйе, гади генә эч быгырдау да организмда җитди чир барлыгы турында кисәтә ала. Әйтик, организм глютенны эшкәртә алмаганда (целиакия) да еш кына эч быгырдый. Тора-бара моңа диарея, гәүдә авырлыгын югалту кебек билгеләр дә өстәлә. Организм сөт шикәрен (лактоза) кабул итә алмаганда да эч быгырдау башлана. Эч быгырдаудан башлана алган иң куркыныч чир булып юан эчәк яман шеше санала.

:: Эч быгырдаган вакыттагы тавыш буенча ашказаны-эчәк трактының нәкъ менә кайсы өлешендә хилафлык барлыгын чамалап буламы?

– Әгәр эч, нигездә, төнлә быгырдый икән, бу – ашказаны-эчәк тракты мускулларының эшчәнлеге бозылган дигән сүз. Эч быгырдау аркада ятканда көчәйсә, монда эчәклек белән проблемалар бар дип шикләнергә җирлек бар. Эч быгырдау сул якка ятканда көчәйсә, ашказаны асты бизен тикшертергә кирәк. Иртәнге якта – йокыдан торгач яки уң якта ятканда эч быгырдау үт куыгындагы хилафлыклар турында кисәтә. Әгәр эч берөзлексез быгырдап торса, эчәклекнең сыеру үзлеге начарланган яки организмда су чамадан тыш күп дигән сүз. Шуңа күрә ашаганда коры су эчмәү хәерле. Гомумән алганда, әгәр эч быгырдау даими рәвештә борчыса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Эч быгырдауны алдан кисәтеп буламы?

– Әгәр табибка күренгәннән соң, белгеч куркырга җирлек юк дип тапса, гади генә кагыйдәләрне үтәргә кирәк. Эч быгырдамасын өчен, иң беренче чиратта ач йөрмәү зарур. Көн саен билгеле бер вакытта ашауны гадәткә кертегез. Иртүк ашап киткәннән соң, көне буе ач йөреп, кич белән генә тамак ялгау – дөрес түгел. Ашаган ризыкны ашыкмыйча, яхшылап чәйнәргә кирәк. Парда пешкән җиңелчә ризыклар ашау, көн дәвамында җитәрлек күләмдә чиста су эчү дә эч быгырдауны кисәтә. Билгеле булганча, кеше тәүлегенә гәүдә авырлыгының һәр килограммына 30–40 мл күләмендә чиста су эчәргә тиеш. Әмма аны ризык белән түгел, ашаудан бушап торган арада эчәргә кирәк. Кәһвә эчүне дә чикләү зарур. Газлы эчемлекләрдән бөтенләй баш тартсаң яхшы. Шикәр, бигрәк тә җиңел углеводлардан да ерак торыгыз. Алар организмда ачу процессы китереп чыгара. Бу шулай ук эч быгырдау, эч күбүләргә китерә. Стресстан да сакланыгыз. Көненә ким дигәндә өч тапкыр спорт белән шөгыльләнү, көненә 10 мең адым җәяү йөрү дә эч быгырдауны кисәтергә, ашкайнату эшчәнлеген яхшыртырга ярдәм итә.

Тамак ачу. Эч быгырдау, нигездә, кешенең тамагы ач булганда күзәтелә. Ашказаны белән эчәклек бик нык кыскара, бу исә үз чиратында тавыш китереп чыгара. Озак вакыт ашамыйча торганда газлар ашказаны буйлап «йөри» башлый. Ул исә үз чиратында билгеле бер тавыш рәвешендә уза. Эч быгырдауның никадәр көчле булуы шушы эчәклек эченә җыелган газларның күплегенә бәйле.
Эч газлану. Билгеле бер продуктлар, әйтик, шул ук борчак, нут кебек кузаклылар, кәбестә ашаганнан соң да эч газланырга мөмкин. Алар эшкәртелгән чакта бик нык әчи, нәтиҗәдә эчтә газ җыела. Андый чакта шулай ук эч быгырдый.
Күп итеп һава йоту. Хәзер кеше ризыкны озаклап чәйнәмичә, аягүсте генә ашарга күнеккән. Ашыгып чәйнәгәндә, күп итеп һава йотыла. Бу шулай ук эч быгырдауга китерә. Ашказаны-эчәк трактындагы ялкынсынулар, дисбактериоз. Бу авырулар ашказаны-эчәк трактына зур басым ясый. Әмма ялкынсыну вакытында эч быгырдаудан тыш кеше эч авыртудан, күңел болгану, диареядан да зарланырга мөмкин.
Кешенең психологик халәте. Даими рәвештә стресс кичергән кеше еш кына ашказаны-эчәк тирәсендә уңайсызлык сизә башлый. Киеренке халәттә, гадәттә, эч быгырдау, эч авырту, күңел болгану борчый.
Организмга ферментлар җитмәү. Ашказаны белән бәйле ниндидер хроник хилафлык аркасында ашказаны тиешенчә эшләп бетерми. Нәтиҗәдә ризык та тиешенчә эшкәртелми. Бу шулай ук эч быгырдауга сәбәпче була ала.

Лимон согы ябыктыра

Зифа буй-сынлы булу өчен лимонлы су белән дуслашырга кирәк, ди белгечләр. Ник дигәндә, лимонлы су матдәләр алмашын яхшырта. Ябыгу өчен 1 стакан җылы суга ярты лимон согы сыгарга, шуны көнгә ике тапкыр яртышар стакан эчәргә кирәк. Бал кушарга да ярый. Аны ач карынга эчү файдалы.

Моннан тыш лимон С витаминына бай. Анда А, В, Р витаминнары күп. Ул иммунитетны күтәрә, С витамины грипп һәм салкын тиюдән саклый. Ашкайнату эшчәнлеген җайга сала, эч күперү, паразитлар булганда да файдасы бар. Бөерләр эшчәнлеген яхшырта, бәвелне, үт суын куа, токсиннарны чыгара, канны, бавырны чистарта. Лимон суы организмда лайланы киметә, шуңа аның астма, бронхит авыруларыннан да файдасы исбатланган.

Әмма лимон согын чамасын белеп кенә кулланырга кирәк. Ул теш эмален какшата. Шуңа күрә лимон согы эчкәннән соң авызны чайкату хәерле. Аны көнгә 1 стаканнан да артык эчәргә ярамый. Сару кайнау, ашказаны-эчәк чирләре булганда да лимон согы эчәр алдыннан табиб белән киңәшләшергә кирәк.

Тест

СӘЛАМӘТМЕ, ЮКМЫ?

Үзеңнең сәламәтме, түгелме икәнлегеңне гади генә тест ярдәмендә дә ачыклап була. Түбәндәге сорауларның барысына да «әйе» дип җавап биргән кешенең күңеле тыныч булсын – ул сау-сәламәт.

✱ Тамак ачкач кына ашыйсыз. Ашказаны тулганчы ашамыйсыз.
✱ Көнгә өч тапкыр туклыклы итеп ашыйсыз (аксым, май, углевод, клетчаткалы ризыклар).
✱ 5–6 нчы катка баскычтан җиңел генә күтәрелә аласыз. Тынызыз бетми.
✱ Иртән будильниксыз да җиңел генә уяна аласыз.
✱ Йокларга яткач, 10–15 минут эчендә йоклап китәсез.

✱ Эштән кайтканнан соң яраткан хоббиегыз белән шөгыльләнергә вакытыгыз бар.

Шаулап кына калмый

Колак шауласа, баш миендә яман шеш булуы ихтимал. Бу турыда табиб-отоларинголог Владимир Зайцев әйткән. «Колак шаулауның берничә сәбәбе булырга мөмкин. Шулар арасында иң куркынычы – баш мие яки эчке колак яман шеше», – ди белгеч. Моннан тыш, сенсоневраль саңгыраулык та колак шаулауга китерә. Бу очракта тавыш нервына кан килүе начарланган була. Артык арганда, кан басымы күтәрелгәндә дә колак шауларга мөмкин. Шулай ук колакта күкерт бөкесе булса да колакның шаулавы бар. Бер көннән артык колак шауласа, төнлә дә туктамаса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк, ди белгеч.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

Җиләк көткәндә

Җәй соңарып килгәнлектән, быел җиләк сезоны да бераз соңара. Шунлыктан әле яңа чәчәк аткан, җимеш төшә башлаган үсентеләрне тукландыру өчен менә дигән вакыт. Һәвәскәр бакчачы Гөлфия Хәнипова кул астындагы гап-гади әйберләр белән җиләкләрне тукландыру буенча киңәшләрен бирде.

Һәр нәрсәнең – үз вакыты

Җиләкне тиешенчә карау, тукландыру уңышны гына түгел, хәтта тәмен, сыйфатын да үзгәртә. Вакытында тукландырылган җиләк тә тәмле, сусыл һәм матур була. Җиләкне елына кимендә өч тапкыр тукландырырга кирәк. Беренчесе – язын, вегетатив фаза вакытында, икенчесе – чәчәк ата башлагач һәм өченчесен – көзен, салкыннар башланганчы.

Әлбәттә, җиләкләрне тукландыру, корткычлардан саклау өчен сатуда нинди генә препаратлар юк хәзер. Тик күп кенә бакчачылар тулысынча диярлек «химия»дән баш тартуны хуп күрә. Чыннан да җиләкне чәчәк аткан вакытта кул астындагы чаралар белән тукландырып, мул уңыш җыеп алырга була.

vk.com

Тукландыру ысуллары

▸ **АГАЧ КӨЛЕ.** Көл фосфор, калий һәм кальцийга бай булганлыктан, җиләк чәчәк аткан вакытта тукландыру өчен иң яхшы чараларның берсе булып тора. Файдалы катнашманы 10 л суга бер стакан көл болгатып ясап, кичкә калдырырга һәм икенче көнне һәр төпкә бер литр сибеп чыгарга киңәш ителә.

▸ **КЫЧЫТКАН ТӨНӘТМӘСЕ.** Әлеге төнәтмә туфракны калий, кальций, тимер һәм марганцовкага баета, шунлыктан тамыр системасын көчәйтеп җибәрә, уңыш күләмен арттыра. Моның өчен мичкәнең яртысына сабагы белән бергә вакланган кычытканны салып, су өстәргә һәм 10–14 көнгә караңгы урында төнәтергә кирәк. Әзер төнәтмәне 10 л суга бер литр болгатып сибәргә киңәш ителә.

▸ **ТИРЕС ЯКИ ТАВЫК ТИЗӘГЕ.** Алар җиләк чәчәк аткан вакытта кулланыла торган иң яхшы чаралардан санала. Катнашма калий, азот һәм фосфорга бай. Ул яңгыр суалчаннарын җәлеп иткәнлектән, туфрак та сыйфатын яхшырта. Файдалы катнашманы әзерләү өчен мичкәнең өчтән берен тирес яки тавык тизәге салырга һәм мичкә авызына җиткәнче су тутырып каплап куярга. Катнашма бер атна торганнан соң тиреснекен 1:10, тавык тизәгеннән ясалганын 1:20 исәбеннән су белән болгатып, һәр төпкә бер литр чамасы сибеп чыгарга.

▸ **ЧИ ЧҮПРӘ.** 100 г чи чүпрәне 10 литр җылы суга салып болгатып, капкач белән каплап кичкә әчетергә калдырырга. Җылы һәм яңгырсыз көнне һәр төпкә ярты литр сибеп чыгарга кирәк.

▸ **ЙОД.** Ул җиләкне корткычлардан саклый, дымлы вакытта авыруларга каршы торучанлыгын арттыра. Аны, гадәттә, көл белән бергә кулланалар. 10 л суга бер стакан көл, 10 тамчы йод салып болгатырга һәм һәр төпкә ярты литр сибәргә киңәш ителә.

▸ **НАШАТЫРЬ СПИРТЫ.** Әлеге катнашма җиләкнең авыруларга карата иммунитетын арттыра. 10 л суга 40 мл нашатырь спирты, бераз эретелгән хуҗалык сабыны кушып болгатырга һәм лейка белән җиләкләрнең өстенә сибеп чыгарга. Катнашманы ясаганда һәм сипкәндә респиратор һәм перчатка кулланырга киңәш ителә.

Тәмле булсын!

«ТОМ ЯМ»

Гөлназ ЗАРИПОВА рецепты

Кирәк: *1 л тавык шулпасы, 150 г креветка, 150 г шампиньон гөмбәсе, 3–4 уртача зурлыктагы помидор, 1 баш суган, 2 теш сарымсак, бер кап «Том ям» пастасы, яшел тәмләткечләр, 1 банка кокос сөте, тәменчә тоз.*

Шулпага креветка белән туралган гөмбәне салып пешерергә. Табада ваклап туралган суган, сарымсак, помидорны кыздырырга һәм шулпага салырга. Пешеп чыгар алдыннан кокос сөте һәм «Том ям» пастасын өстәп кайнатып чыгарырга һәм сүндерергә. Табынга өстенә яшел тәмләткечләр салып бирергә. Рестораннардагыча тәмле аш әзер!

Белеп тор!

Хуҗабикәгә киңәшләр

✓ Кунада нәрсә дә булса тураганда өстәл өстендә шуып йөдәтмәсен дисәгез, аның астына бераз дымлы чүпрәк җәегез.

✓ Бөртекле тәмләткечләрнең тәме һәм исе җетерәк булсын өчен аларны бераз гына табада кыздырып алыгыз.

✓ Яшел тәмләткечләрне кышка саклауның җайлы ысулы бар. Боз катыра торган шакмаклы савытларга туралган яшел тәмләткечләрне салып, өстенә бераз су агызып, катырырга куегыз. Каткач, аерым савытларга тутырып куярга була. Кирәк саен яшел тәмләткеч кул астында дигән сүз.

✓ Камыр ризыкларын пешкәч табадан алу җиңел булсын өчен майланган табага камырны салыр алдыннан бераз гына он сибегез.

✓ Йомшак торт яки сырны пычак белән кискәндә ул изелеп бетәргә мөмкин. Моның өчен теш өчен кулланыла торган яки башка төрле ефәк җеп кулланырга була.

Ир + хатын

Ирне бәхетле итүнең 5 ысулы

1 Ир ул – малай түгел. Ул үз тормышының режиссеры икәнлеген тоярга тиеш. Гадәттә, хатын-кыз гаиләнең дирижеры ролен үти: балалар, ашау-эчү, киенү, туләүләрнең һәммәсен үз өстенә ала. Ә иргә акча табу гына йөкләнә һәм ул гаилә мәшәкатьләреннән читтә кала. Аңа мондый мөнәсәбәт аны ялланган эшче яки үсми калган малай рәвешенә кертеп, бәхетсез итә. Ир дә гаилә тормышында кайнап яшәсен.

2 Позитив кичерешләрен хуплагыз. Әлбәттә, көн гел күңелле хәлләрдән генә тормый. Һәрбер нәрсәнең, хәтта уңышсызлыкларның да уңай якларын күрергә тырышыгыз. Ирегезгә нәрсә сөенеч китерүе турында сорашыгыз. Кичен ирегезнең көн дәвамында булган уңай кичерешләрен барлауны гадәткә кертегез. Шул рәвешле сезнең психикагыз позитивка игътибар юнәлтеп, моны гадәткә әйләндерәчәк.

3 Мавыгуларын кабул итегез. Күп очракта хатын-кызлар ирләрен хоббиларына «көнли». Нәфис затларга ирләренә аннан башка бер җирдә дә яхшы булмаска тиеш шикелле тоела. Ләкин ирнең мавыгулары булганга куанырга кирәк. Аны илһамландыра торган шөгыле, сез аңлап кабул иткән очракта, тормышыгыз көйләнүгә һәм мөнәсәбәтләр ныклыгына китергәнен дә онытмагыз.

4 Мактагыз, яратуыгызны яшермәгез. Ирләр өчен ихлас хисләр бик мөһим, алар ясалмалылыкны яратмый. Әгәр сезнең җылылыкны, аңлап кабул итүегезне тойса, ирегез үзен бик бәхетле хис итәчәк.

5 Дуслары белән аралашуны тыймагыз. Ирләрнең бәхете башкалар белән аралашып яшәүдә дә. Дуслары белән аралашу, ирләр темасына сөйләшү, уңышлары турында бераз «мактанып» алу аларга канәгатьлек бирә. Дусларының һәм фикердәшләреннән башка ирләр үзләрен бик үк бәхетле итеп тоймаячак. Яхшы дуслар белән аралашу, аңлашу, тормыш мәшәкатьләреннән беразга булса да арынып тору ирегезгә һәм сезгә дә файдага булыр.

Үзем сынадым

КЫЯР СОДА ЯРАТА

Үзган ел кыярларымның яфраклары саргаеп, бөтенләй уңышы кимегәч, бакча күршем бер киңәш биргән иде. Ул миңа 10 л суга 3 аш кашыгы сода салып болгатып, лейка белән өстенә сибеп карарга кушты. Мин ышаныр-ышанмас кына, ни булса, шул булыр, дип сипкән идем дә аннары шаккаттым! Кыярларым тернәкләнеп, көчәеп китте һәм бик озак уңыш бирде.

Лилия АРСЛАНОВА.
Казан

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЧАМА ХИСЕ ҺӘМ ИХЛАС НИЯТ КИРӘК

Тормышыбызның никадәр бәрәкәтле, мул булуын мәҗлес-бәйрәмнәрдән дә чамаларга була. Аш-су җыйганда йорт хуҗалары табынны да мөмкин булганча затлырак, мулрак итеп корырга тырыша, сәдака, бүләк-күчтәнәчләрен дә өеп бирә. Аш уздыруның нинди таләп-кагыйдәләре бар? Дини мәҗлескә барганда күчтәнәч алу кирәкме? Табын корганда нәрсәләрне истә тотарга?

Бу һәм башка кызыксындырган сорауларга Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ җавап бирде.

:: Хәзрәт, дини мәҗлеснең максаты бит ашау-эчү генә түгел. Мәҗлес җыюның асылын аңлатсак иде.

– Аш уздыруның максаты-асылы – өйгә Коръән укыту. Ягъни Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен, йорт хуҗалары нининдер максат белән мәҗлес җыя. Имамның максаты – аңлаешлы, кеше кабул итәрлек итеп вәгазь сөйләү, Коръән уку, дога кылу. Йортта Коръән укыту бик хәерле. Хәдисләрдә дә бу хакта еш әйтелә, андый йортка шайтан кермәс, бәрәкәт булыр, диелә.

Кызганыч, соңгы вакытта шул күзәтелә: ашка ризыкны кирәгеннән артык әзерлиләр. Ул кала. Исраф ике төрле була. Берсе – күп ашау, икенчесе – ризыкның артып калуы. Әлбәттә, кунак җыеп, әзерләгән ризыклар ашалып бетсә, бик яхшы. Әмма күп очракта алай түгел. Кирәгеннән артыкны әзерләргә кирәкми.

:: Бу җәһәттән табын кору буенча нинди киңәш бирерсез?

– Бар дөньяны шаккатырам дип эшләргә кирәкми. Иң мөһиме – ихлас ният, Аллаһы Тәгаләнең кабул кылуы. Аш уздырырга җыенганда, ризыкның хәләл булуын карарга кирәк. Күплегенә түгел, сыйфатына басым ясау хәерле. Күп очракта, кызганыч, хәләллегенә игътибар ителми. Авылдан килгән ит хәләл инде ул, дибез. Әмма мал суйганда «бисмилләһ» әйтелмәсә, бу ит хәләл булмый бит. Сыр, ит, краб таякчыклары куйганда игътибарлы булырга кирәк.

:: Кайбер җирләрдә кунак өчен аерым пакетлар тутыралар, өч-дүрт кисәк пирогны тәлинкәгә бүлеп, алларына куялар. Болай эшләү дөресме?

– Бу, чыннан да, модага кереп китте. Моңа ике яклы карарга була. Беренчедән, йорт хуҗасы аны кунакның күңеле булсын, өенә күчтәнәч алып кайтсын дип әзерләргә мөмкин. Әмма, икенче яктан карасак, төрле кеше бар бит. Кайберәүләр, шундый гадәт кабул ителде инде дип, акчасын әрәм итә-итә ризык җыярга мөмкин. Ашны уздырдык, кешеләр тукланды, кунак кеше үз йортына бер кисәк ризыгын алып китсә дә җитә бит. Әйткәнемчә, бу эш ихлас ният белән башкарылырга һәм ризык исраф калмаска тиеш.

:: Мәҗлес җыйганда хатын-кызларны – аерым, ир-атларны аерым чакырыргамы? Бергә булганда, аерым бүлмәләргә утыртыргамы?

– Аерым утырсалар, хәерлерәк булыр. Коръән укыганда, вәгазь сөйләгәндә, шәхсән үзем хатын-кызларны бүлмә почмагына булса да утыртырга тырышам. Аны тыңлау хәерле бит. Кеше дога кыла икән, ул Аллаһы Тәгаләгә якыная дигән сүз.

:: Кайбер кеше юбилей, туган көннәрен дә Коръән ашы итеп уздыра. Бу – дөрес гамәлме?

– Элек туган көннәрне хәмер белән уздыру гадәте бар иде. Ахыры ничек була әле андый мәҗлесләрнең. Менә шундый очраклар булмасын өчен, хәләл табын кору кирәк. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен, аңа шөкер итү йөзеннән, хәләл ризыклардан өстәл әзерләп, хәләл рәвештә бәйрәмен уздыра икән, бу бик яхшы! Һәм, билгеле, ихлас булырга онытмыйк. Туган көн иясе үткән тормышына шөкер итеп, алдагысына Аллаһы Тәгаләдән бәрәкәт сорап, хәләл бәйрәм оештыра икән, бу хуплана. Туганнар, кардәшләр җыелгач, әйбәт бит. Финанс мөмкинлекләренә дә игътибар итәргә кирәк. Бурычка бата-бата, зур мәҗлесләр үткәрүгә караганда, берничә кеше җыеп, Коръән укып, дога кылу хәерлерәк. Күп кешеләр шулай эшли дә. Бу да бик дөрес. Мәҗлес тә шау-гөр килә торган чарага әверелми.

:: Дини мәҗлескә барганда бүләк-күчтәнәч алып бару кирәкме?

– Гадәткә карарга кирәк. Моңа кадәр дә кунакка күчтәнәч белән йөрсәгез, алып барасыз. Диндә мәҗбүрият юк. Бер-беребезгә карата хөрмәт йөзеннән күчтәнәч бирешсәк, начар түгел. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен эшләнсен ул. Әлбәттә, моңа кешенең матди мөмкинлеге рөхсәт итсен.

:: Дини мәҗлестә сәдака өләшү тәртибен дә аңлатсагыз иде, хәзрәт.

– Барысы да йорт вәкилләреннән тора. Хәер-сәдака өләшү безнең гадәткә кергән. Кайбер җирдә сәдаканы мәчеткә җыеп тапшыралар. Кайсылары йортта җыеп, авыр хәлдәге кешегә бирәләр. Бу – ирекле эш. Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән бу эш эшләнсә, хәерле. Һәр кеше үз мөмкинлегеннән чыгып хәл итә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Июль аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Җом	01:03	03:03	17:34	20:31	22:01
2	Шим	01:04	03:04	17:34	20:30	22:00
3	Якш	01:04	03:04	17:34	20:30	22:00
4	Дүш	01:05	03:05	17:33	20:29	21:59
5	Сиш	01:06	03:06	17:33	20:28	21:58
6	Чәрш	01:07	03:07	17:33	20:28	21:58
7	Пәнҗ	01:08	03:08	17:33	20:27	21:57
8	Җом	01:10	03:10	17:32	20:26	21:56
9	Шим	01:11	03:11	17:32	20:25	21:55
10	Якш	01:12	03:12	17:31	20:24	21:54
11	Дүш	01:13	03:13	17:31	20:23	21:53
12	Сиш	01:15	03:15	17:30	20:22	21:52
13	Чәрш	01:16	03:16	17:30	20:21	21:51
14	Пәнҗ	01:17	03:17	17:29	20:19	21:49
15	Җом	01:19	03:19	17:29	20:18	21:48
16	Шим	01:20	03:20	17:28	20:17	21:47
17	Якш	01:22	03:22	17:27	20:16	21:46
18	Дүш	01:23	03:23	17:27	20:14	21:44
19	Сиш	01:25	03:25	17:26	20:13	21:43
20	Чәрш	01:27	03:27	17:25	20:11	21:41
21	Пәнҗ	01:28	03:28	17:24	20:10	21:40
22	Җом	01:30	03:30	17:24	20:08	21:38
23	Шим	01:31	03:31	17:23	20:06	21:36
24	Якш	01:33	03:33	17:22	20:05	21:35
25	Дүш	01:35	03:35	17:21	20:03	21:33
26	Сиш	01:37	03:37	17:20	20:01	21:31
27	Чәрш	01:38	03:38	17:19	20:00	21:30
28	Пәнҗ	01:40	03:40	17:18	19:58	21:28
29	Җом	01:42	03:42	17:17	19:56	21:26
30	Шим	01:44	03:44	17:16	19:54	21:24
31	Якш	01:46	03:46	17:14	19:52	21:22

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Нәсыйхәт



▶«Аллаһ берәүгә хәерлелек теләсә, Ул аны сынауларга дучар итә».

▶«Әгәр сезнең берәрегез үзеннән баерак һәм матуррак булган кешегә караса, үзеннән фәкыйрьрәк һәм түбәнрәк булучыларга да карасын».

▶«Аллаһ Тәгалә биргән нигъмәткә шөкер итү ул нигъмәтнең бәрәкәтле булуына һәм артуына сәбәп булыр».

Йәгез, бер дога!

БАРЛЫК ЭШЛӘРДӘ ЯРДӘМ БУЛСЫН ӨЧЕН УКЫЛА

Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.): «Һәркем сәхәрдә 7 тапкыр вә ахшамда 7 мәртәбә бу доганы укыса, дөнья вә ахирәткә бәйле бөтен эшләрендә Аллаһ аңа ярдәм бирер», – дигән.

«Хәсбийә-ллааһу ләә иләәһә илләә һүүә галәйһи тәүәккәльтү үә һүүә Раббун галәййә газыйм».

***Мәгънәсе:** «Аллаһ – минем ышанычым, Аның үзеннән башка бернинди илаһи зат юк, мин Аңа тәвәккәлләдем һәм Ул – биек һәм бөек булучы Раббым».*

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

РАМИЛ ШӘРӘПОВ:
«КАЙЧАКТА ХАТЫН БЕЛӘН ШӘРӘПҖАН ӘЙТКӘЛӘШӘ»

Аның сызылып киткән кара мыегы, ак майкасы, кызыл әчле галушлары инде күпләргә таныш. Һәр мәхәббәт корты үзенең «красопетка»сына багышлый ала торган җырын да күпләр беләдер. Шәрәпҗан – Рамил ШӘРӘПОВ белән җәһәт кенә әңгәмә кордык.

:: Ни хәл?
– Бик яхшы, Аллага шөкер. Сабантуйларны гөрләттек. Быелгы бәйрәмнәр минем өчен үзенчәлекле булды – Сабантуйларны Шәрәпҗан белән «бергә» алып бардык. Яртысын – ул, калганын – Рамил Шәрәпов.

:: Арча районындагы бер авылга барып, бушка Сабан туе да уздырдыгыз.
– Әйе. Көтмәгәндә-уйламаганда, бер артист та килмәгән авылга барып, сюрприз ясарга кирәк дигән идея килде башыма. Айван авылына барып, халыкның гына түгел, үземнең дә күңелне күрдем. Аларның сөенгәннәрен күреп, үзем икеләтә сөендем. Бик чакырганнар иде инде. Барлык авыллар да бәйрәмгә артист чакырыр өчен иганәче табып бетерә алмый бит, күпләр үз көчләре белән уздыра Сабантуйларны. Киләчәктә шушы эшне дәвам итәргә, һич югында елга бер мәртәбә шундый бәйрәм оештырырга телим. Заманасы болганчык, иртәгә нәрсә буласын белгән юк. Бөтен әйбер акчага терәлмәгән бит.

:: Күптән түгел Шәрәпҗан да җырлый башлады. «Красопетка»ның язылу тарихын сөйләгез әле.
– Шәрәпҗанны җырлату күптәнге хыялым иде. Әйтик, урыс эстрадасындагы Михаил Галустян, Александр Ревваның образларына туры килердәй җырлары бар. Без дә яздырырга булдык. Җыр февральдә үк әзер иде, ил-көндә хәлләр тыныч булмагач, бераз көттек.

:: Клибы да шактый үзенчәлекле. Сценарийны үзегез яздыгызмы?
– Анысын курсташым, дустым Алмаз Гыйльметдинов белән яздык. Бер көндә генә түгел, берничә ай буе күңелебездә йөрттек, уйлаштык. Үзгә стиле дә булсын, халыкчан да булсын дип тырыштык. Әйбәт килеп чыкты дип уйлыйм. Командабыз зур иде, профессионаллар белән

һәр образны уйлап эшләдек. Сүз уңаеннан, Шәрәпҗан өстендәге кып-кызыл костюмны киеп өйләнгән идем мин. Ул вакытта зуррак иде, хәзер кечерәйгән. Әллә Шәрәпҗанның җилкәсе киңрәк булып чыкты шунда...

:: Халык кабул иттеме «Красопетка»ны?
– Төрле фикерләр булды. Һәрвакыттагыча инде – кемгәдер ошый, кемдер яратмый. Барысына да ошасын әле,

Блиц-сораштыру

– Шәрәпҗанның кайсы сыйфатлары Рамил Шәрәповта да бар?
– Иң беренче чиратта, гадилектер. Икесе өчен дә иң мөһим сыйфат.
– Юмор – кем өчендер юаныч. Ә сезнең өчен нәрсә?
– Тормыш рәвешем, яшәү чыганагым. Юморсыз үземне, тормышымны күз алдына да китерә алмыйм. Гәрчә драма артисты булсам да.
– Кәефсез чакта нәрсә эшлисез?
– Елмаерга тырышам. Күңел тулганда, шигырьләр дә укыйм, видеога яздырам. Андый чакта алар тагын да ихлас, гади килеп чыга.
– Тормыш девизыгыз?
– Бары тик үзеңә генә ышан.

дип эшләсәң дә, аны яратмаган ике кеше булса да табылачак. Үзем исә клипны да, җырны да уңышлы дип саныйм. Шәрәпҗанның юморы күбрәк абый-апаларга якын булса, җырны яшьләр яратыр, миңа калса.

:: Тавышны шулай озак үзгәртеп тору кыендыр ул...
– Элек тавыш тизрәк арый, авыррак иде. Хәзер ияләштем. Тавышны җәһәт кенә үзгәртү дә кыен димәс идем. Кайвакыт өйдә дә, хатын белән әйткәләшә башласак, Шәрәпҗан булып сөйләшәм. Ничектер йомшаграк, кызыграк килеп чыга.

:: Ә Рамил Шәрәповның хәлләре ничек? Шәрәпҗан белән чагыштырганда, игътибар кимеде кебек тоелмыймы?
– Шәрәпҗан популяр булганга шулай тоеладыр ул. Ләкин алар – икесе ике төрле кеше. Беренчесе халыкны көлдерсә, Рамил Шәрәпов җитдирәк. Шигырьләр сөйләп, халыкны рухи яктан баетырга тырышып иҗат итә ул.

:: Элегрәк татар юмор эстрадасында Шәрәпҗан кебек образлар шактый популяр иде. Аннан соң берара бетеп торды. Хәзер менә тагын шуңа әйләнеп кайттык. Сәбәбе нидә икән?
– Мондый хәл бит юмор өлкәсендә генә түгел, башка өлкәләрдә дә күзәтелә. Әйтик, моданы гына алыйк. Әүвәлге киенү стиле, элеккеге модага әйләнеп кайттык. Юморда да шулай. Берара югалып торып сагындыра, тансыкка әйләнә дә яңадан халыкка ошый башлый.

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*Газетабызның узган санында чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып Саба районының Яңа Мичән авылыннан **Сөмбелә Ибраһимова** танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Илсөя Бәдретдинова башкаруындагы «Камыш әйтә – мин әйтәм», Салават Фәтхетдиновның «Яран гөл» һәм Зөлфәт Зиннуров репертуарыннан «Өйләнмим» җырларын яшергән идек.*

Җырчы, иң кадерле кешеләребезнең җаннары әрнемәсен иде, ди. Сәгатьләрне санап көтәләр, шуңа да янарына кайтырга өнди ул.

Әлеге җыр сүзләр турында. Гади сүзләр түгел, җырчы кояш чыгарырдай, сөеп юатырдай, җаннан китми торганнары турында җырлый.

Бу җыр капма-каршы мәгънәле сүзләрдән тора. Ул сине сагына, ләкин күрә алмый, бармыйм, дисә дә, сиңа таба атлый.

29 июнь | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ 2» 16+
11.00, 00.15 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «Ай тулганда» 16+
13.00, 00.40 «Жырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия» 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00, 01.30 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00, 23.50 «Соотечественники» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Сакладым сине күңелемдә». Гөлшат Зәйнашева турында телеочерк 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
04.15 «Сакладым сине күңелемдә». Гөлшат Зәйнашева турында телеочерк 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «МИССИЯ «АМЕТИСТ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.55 К юбилею Карена Шахназарова. Елизавета Боярская, Максим Матвеев, Виталий Кищенко, Кирилл Гребенщиков, Виктория Исакова, Татьяна Лютаева, Дмитрий Миллер, Анастасия Макеева, Любовь Германова, Никита Ефремов, Борис Каморзин, Владимир Ильин. «АННА КАРЕНИНА» 12+
00.55 Ольга Иванова, Никита Тезин, Юрий Батурин, Александра Мареева, Мария Порошина, Сергей Никоненко, Геннадий Смирнов, Алика Смехова. «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ» 12+
02.45 Мария Порошина, Вячеслав Разбегаев, Владимир Епифанцев. «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.30, 14.50, 16.50, 18.50 Новости
06.05, 22.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 Специальный репортаж 12+
09.20 Футбол. Лига чемпионов. «Байер» (Германия) – «Рома» (Италия) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35 «Кубок PARI Премьер». Специальный репортаж 12+
12.55, 14.55 «ПОБЕГ» 16+
15.50, 16.55 «В ПОИСКАХ ПРИКЛЮЧЕНИЙ» 16+
17.50 Смешанные единоборства. UFC. Исраэль Адесанья против Роберта Уиттакера. Трансляция из США 16+
18.55 Все на Кубок PARI Премьер! Прямой эфир
19.30 Футбол. Кубок PARI Премьер. ЦСКА – «Зенит» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция из Москвы
23.00 «ЧЕЛОВЕК ПРЕЗИДЕНТА» 16+
00.50 «Есть тема!» 12+
01.10 Футбол. Кубок Либертадорес. 1/8 финала. «Серро Портеньо» (Парагвай) – «Палмейрас» (Бразилия). Прямая трансляция
03.15 Новости 0+
03.20 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Трансляция из Москвы 0+
04.40 Смешанные единоборства. ACA. Артём Резников против Дави Рамоса. Трансляция из Сочи 16+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) 6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ» (S) 16+
21.45 «ПЕРЕСУД» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
02.45 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». «Обещание» 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «ДОЛГАЯ ДОРОГА К СЧАСТЬЮ» 16+
19.00 «ВОСПИТАНИЕ ЧУВСТВ» 16+
22.30 «Порча» 16+
23.00 «Знахарка» 16+
23.30 «Верну любимого» 16+
00.05 «Понять. Простить» 16+
01.05 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 5-я и 6-я серии 16+
02.45 «Тест на отцовство» 16+
04.25 «Давай разведёмся!» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

06.55 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ» 12+
11.20, 18.50 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.25, 14.05 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
20.50 Новости дня 16+
21.50 «Секретные материалы». Док. сериал. «Жаркая осень холодной войны. Подводные тайны Карибского кризиса» 16+
22.40 «КОНТРАБАНДА» 12+
00.20 «ПОХИЩЕНИЕ «САВОЙИ» 12+
01.50 «НЕЖНЫЙ ВОЗРАСТ» 12+
03.10 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...» 12+
04.25 «Перелом. Хроника Победы». Док. сериал 16+
05.00 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+

30 июнь | Пәнҗешәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 16.00 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
10.00, 00.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ 2» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 17.00 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
17.30 «Трибуна «Нового Века» 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
21.00 «Чёрное озеро» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Наша Республика – наше дело» 12+
00.50 «Видеоспорт» 12+
01.15 «Соотечественники». Муза Назиба Жиганова 12+
01.40 «Каравай». Якутская выставка 6+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ шоу» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Нәҗип Җиһанов турында телеочерк 6+
15.30 «Халкым минем» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Булат Гыйльванов турында телеочерк 6+
21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05, 04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «МИССИЯ «АМЕТИСТ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.55 К юбилею Карена Шахназарова. Елизавета Боярская, Максим Матвеев, Виталий Кищенко, Кирилл Гребенщиков, Виктория Исакова, Татьяна Лютаева, Дмитрий Миллер, Анастасия Макеева, Любовь Германова, Никита Ефремов, Борис Каморзин, Владимир Ильин. «АННА КАРЕНИНА» 12+
00.55 Ольга Иванова, Никита Тезин, Юрий Батурин, Александра Мареева, Мария Порошина, Сергей Никоненко, Геннадий Смирнов, Алика Смехова. «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ» 12+
02.45 Мария Порошина, Вячеслав Разбегаев, Владимир Епифанцев. «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.30, 18.35 Новости
06.05, 17.40, 22.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.10 Специальный репортаж 12+
09.30 Футбол. Кубок PARI Премьер. ЦСКА – «Зенит» (Санкт-Петербург). Трансляция из Москвы 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35 «Кубок PARI Премьер». Специальный репортаж 12+
12.55 «ПОБЕГ» 16+
14.50 «Матч мировых звёзд хоккея – легендарный овертайм». Прямая трансляция из Красноярска
18.40 Хоккей. OLIMPBET Турнир КХЛ 3х3. Прямая трансляция
20.45 «Karate Combat 2022. Эпизод 4» 16+
23.00 «ЧЕЛОВЕК ПРЕЗИДЕНТА: ЛИНИЯ НА ПЕСКЕ» 16+
00.50 «Есть тема!» 12+
01.10 Футбол. Южноамериканский кубок. 1/8 финала. «Индепендьенте дель Валье» (Эквадор) – «Ланус» (Аргентина). Прямая трансляция
03.15 Новости 0+
03.20 «Матч мировых звёзд хоккея – легендарный овертайм». Трансляция из Красноярска 0+
04.40 Смешанные единоборства. Shlemenko FC. Андрей Корешков против Леонардо Да Сильвы. Трансляция из Омска 16+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) 6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ» (S) 16+
21.45 Премьера. «ПЕРЕСУД» (S) 16+
00.00 «ЧП. Расследование» (S) 16+
00.35 «Поздняков» (S) 16+
00.50 «Мы и наука. Наука и мы» (S) 12+
01.35 «ПЁС» (S) 16+
02.40 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.10 «Давай разведёмся!» 16+
10.10 «Тест на отцовство» 16+
12.25 «Понять. Простить» 16+
13.30 «Порча». «Волосы» 16+
14.00 «Знахарка» 16+
14.35 «Верну любимого» 16+
15.10 «КОМПАНЬОНКА» 16+
19.00 «ТЕНЬ ПРОШЛОГО» 16+
22.35 «Порча» 16+
23.05 «Знахарка» 16+
23.35 «Верну любимого» 16+
00.10 «Понять. Простить» 16+
01.10 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 7-я и 8-я серии 16+
02.50 «Тест на отцовство» 16+
04.30 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «6 кадров» 16+
05.30 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

06.50 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20 «Освобождение». Док. сериал 16+
09.45 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ» 12+
11.20, 18.50 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.25, 14.05 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
20.50 Новости дня 16+
21.50 «Код доступа». «Обратная сторона санкций» 12+
22.40 «ПРАВДА ЛЕЙТЕНАНТА КЛИМОВА» 12+
00.20 «ИНСПЕКТОР УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА» 12+
01.50 «БУДНИ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА» 12+
03.20 «ГОСПОДА ГОЛОВЛЕВЫ» 16+
04.50 «Великая Отечественная. Партизаны Украины». Док. фильм 12+
05.40 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+

1 июль | Җомга

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
10.00, 03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Классный час» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тызрәк! Алга! Житезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Аулак өй» 6+
16.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Юлчы» 6+
22.10 «КВН РТ-2022» 12+
00.00 «КАКАЯ У ВАС УЛЫБКА» 6+
01.25 «Каравай». Национальные куклы 6+
01.50 «БИЧАРАКАЙ» 12+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Ком сәгате» 12+
09.40 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Мәсгудә Шәмсетдинова турында телеочерк 6+
15.30 «Нәсыйхәт» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 00.40 «Калеб» 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Туган җир» 12+
19.35 «Заман көзгесе» 6+
20.05, 21.55, 03.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
01.05 «Сагынырлык булсын...» Марат Кәбировның иҗат кичәсе 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 «Две звезды. Отцы и дети» (S) 12+
23.25 Документальный фильм «The Beatles в Индии» (S) 16+
01.10 «Информационный канал» 16+
05.00 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Данила Козловский, Владимир Машков, Катерина Шпица, Сергей Шакуров, Сергей Газаров, Елена Яковлева, Алёна Бабенко, Вячеслав Разбегаев, Василий Мищенко. «ЭКИПАЖ» 6+
23.50 Премьера. «Немецкая Украина. От гетмана до гауляйтера». Фильм Алексея Денисова 16+
00.50 Константин Хабенский, Ксения Раппопорт, Николай Ефремов, Михаил Пореченков, Алексей Серебряков, Фёдор Бондарчук, Евгений Стычкин, Евгений Дятлов. «БЕЛАЯ ГВАРДИЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.30, 14.50, 16.50, 18.55 Новости
06.05, 15.50, 19.00, 22.15, 00.20 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 Специальный репортаж 12+
09.20 Футбол. Лига чемпионов. «Рома» (Италия) – «Ливерпуль» (Англия) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35 «Лица страны. Денис Гнездилов» 12+
12.55, 14.55 «ПОБЕГ» 16+
16.55 Смешанные единоборства. URAL FC. Кирилл Сидельников против Фабио Мальдонадо. Прямая трансляция из Перми
19.30 Футбол. Кубок PARI Премьер. ФК «ПАРИ НН» (Нижний Новгород) – «Сочи». Прямая трансляция из Москвы
22.25 Бокс. Матч ТВ Кубок Победы. Прямая трансляция из Казани.
01.10 Футбол. Чемпионат Европы среди юношей (U-19). Финал. Трансляция из Словакии 0+
03.15 Новости 0+
03.20 Пляжный футбол. Чемпионат России. «Строгино» (Москва) – «Спартак» (Москва) 0+
04.40 Пляжный футбол. Чемпионат России. Сборная Санкт-Петербурга – «Кристалл» (Санкт-Петербург) 0+

НТВ

05.00 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25, 10.35 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) 6+
11.05 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «Новые русские сенсации» (S) 16+
21.50 Премьера. «Концерт памяти Михаила Круга. 60» (S) 12+
23.50 Денис Рожков. «ОТПУСК» (S) 16+
01.25 «Квартирный вопрос» (S) 0+
02.20 «Их нравы» 0+
02.35 «ДИКИЙ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». «Смертельный след» 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «ВОСПИТАНИЕ ЧУВСТВ» 16+
19.00 «ХРУСТАЛЬНАЯ МЕЧТА» 16+
23.05 «ЛЮБЛЮ ОТЦА И СЫНА» 16+
02.40 «Порча» 16+
03.05 «Знахарка» 16+
03.30 «Верну любимого» 16+
03.55 «Понять. Простить» 16+
04.45 «6 кадров» 16+
04.50 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

06.00 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
06.15, 09.20 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
10.20 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ» 12+
13.25, 14.05, 03.00 «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.40 «Время героев». Премьера! 16+
18.55 «ЗАБЫТЫЙ» 16+
22.55 «УЗНИК ЗАМКА ИФ» 12+
02.40 «Москва фронту». Док. сериал 16+

2 июль | Шимбә

ТАТАРСТАН
08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Разилә Муллина 12+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Татар халык җырлары» 0+
11.30 «Казаннан – казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 «Күңелем минем...» Җавит Шакировның юбилей кичәсе 6+
17.00 Т. Миңнуллин. «АЛТЫ КЫЗГА БЕР КИЯҮ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Ватандашлар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «Кунак БиТ шоу». Винарис Ильегет 12+
23.00 «ТУР ДЕ ШАНС» 12+
00.40 «Вехи истории». Культурная революция 12+
01.05 «Каравай». Соприкасаясь к миру прошлого. Фольклор и дети 6+
01.30 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Мәхәббәтем – җыр минем». Татарстанның халык артисты Эмиль Җәләлетдинов турында телеочерк 6+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Дания Нуруллинаның юбилей кичәсе 6+
17.10 «Казаннан – казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
20.00 Татарстанның халык артисты Зөфәр Хәйретдиновның юбилей концерты 6+
22.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
01.00 «Галиҗәнап шагыйрь» циклыннан. Илдар Юзеев 6+
02.00 «Мәхәббәтем – җыр минем». Татарстанның халык артисты Эмиль Җәләлетдинов турында телеочерк 6+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

1 КАНАЛ
06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
08.35 «Умницы и умники». Финал 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 К 65-летию Александры Яковлевой. «Жизнь с чистого листа» 12+
11.00 «Видели видео?» 0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
14.00 «ЭКИПАЖ» 12+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 «ЭКИПАЖ» 12+
17.10 Специальный репортаж. «Украина. Когда открываются глаза» 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «На самом деле» 16+
19.25 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.15 Премьера. Билли Кристал. «СТЕНДАПЕР ПО ЖИЗНИ» (S) 16+
01.00 «Наедине со всеми» 16+
03.15 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.40 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
12.40 Анастасия Заворотнюк, Алексей Кравченко, Андрей Соколов, Вера Сотникова, Раиса Рязанова. «Я БОЛЬШЕ НЕ БОЮСЬ» 12+
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
21.00 Премьера. Анна Васильева, Татьяна Казючиц, Сергей Мухин, Роман Полянский. «НЕРОДНАЯ» 12+
00.30 Константин Хабенский, Ксения Раппопорт, Николай Ефремов, Михаил Пореченков, Алексей Серебряков, Фёдор Бондарчук, Евгений Стычкин, Евгений Дятлов. «БЕЛАЯ ГВАРДИЯ» 16+
03.55 Алина Сергеева, Юрий Батурин, Юлия Галкина, Сергей Романюк. «ПЯТЬ ЛЕТ И ОДИН ДЕНЬ» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 Профессиональный бокс. Сауль Альварес против Калеба Планта. Бой за титулы чемпиона мира по версиям WBC, WBA, IBF и WBO. Трансляция из США 16+
07.00, 08.55, 12.05, 18.50 Новости
07.05, 15.00, 16.40, 18.10, 20.50, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 «Кубок PARI Премьер». Специальный репортаж 12+
09.20, 12.10, 23.45 «ЗАГОВОРЁННЫЙ» 16+
13.05 «В ПОИСКАХ ПРИКЛЮЧЕНИЙ» 16+
15.25 Пляжный футбол. Чемпионат России. Сборная Санкт-Петербурга – «Локомотив» (Москва). Прямая трансляция
16.55 Пляжный футбол. Чемпионат России. «Кристалл» (Санкт-Петербург) – ЦСКА. Прямая трансляция
18.55 Бокс. Матч ТВ Кубок Победы. Прямая трансляция из Казани
21.00 Профессиональный бокс. Сергей Воробьёв против Адриана Переса. Прямая трансляция из Москвы
03.15 Новости 0+
03.20 Пляжный футбол. Чемпионат России. «Крылья Советов» (Самара) – «Спартак» (Москва) 0+
04.40 Матч! Парад 16+
05.00 Смешанные единоборства. UFC. Исраэль Адесанья против Джареда Каннонира. Прямая трансляция из США

НТВ
05.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
07.25 «Простые секреты» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» (S) 0+
09.20 «Едим дома» (S) 0+
10.20 «Главная дорога» (S) 16+
11.00 «Живая еда» с Сергеем Малозёмовым (S) 12+
12.00 «Квартирный вопрос» (S) 0+
13.05 «Однажды...» (S) 16+
14.00 «Своя игра» (S) 0+
15.00, 16.20 «Следствие вели...» (S) 16+
19.35 Александр Устюгов, Ирина Пегова. «БЛИЗНЕЦ» (S) 12+
23.20 «Международная пилорама» (S) 16+
00.00 Дмитрий Нагиев. «НЕПРОЩЕННЫЙ» (S) 16+
02.00 «Дачный ответ» (S) 0+
02.50 «ДИКИЙ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «ЧУЖАЯ ЖИЗНЬ» 16+
10.25 «ИДЕАЛЬНЫЙ БРАК». 1-я – 8-я серии 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК». 101-я и 102-я серии 16+
22.45 «ВСПОМИНАЯ ТЕБЯ» 16+
02.25 «ИДЕАЛЬНЫЙ БРАК». 1-я – 4-я серии 16+
05.45 «Лаборатория любви» 16+

ЗВЕЗДА
06.30 «СОЛЕНЫЙ ПЕС» 12+
07.40, 08.15 «САДКО» 6+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.35 «Легенды кино». Рина Зелёная 12+
10.15 «Главный день». Вольф Мессинг 16+
11.00 «Война миров». Док. сериал. «Сталин против Гитлера» 16+
11.45 «Не факт!» 12+
12.15 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным». «Страна Советов – жизнь по советскому стандарту» 12+
13.15 «Легенды музыки». «Комбинация» 12+
13.40 «Круиз-контроль». Премьера! 12+
14.15 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
14.25 «ДАУРИЯ» 12+
18.25 «ВЫСОТА 89» 16+
20.20 «ЧАСОВЩИК» 16+
22.00 «МАФИЯ БЕССМЕРТНА» 16+
23.35 «ВХОД В ЛАБИРИНТ» 12+
05.15 «Легендарные полководцы. Михаил Кутузов». Док. фильм 16+

3 июль | Якшәмбе

ТАТАРСТАН
08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Йолдызлар сәламе» 6+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык». Рөстәм Абязов 12+
11.00 «Наша Республика – Наше дело» 12+
12.00, 19.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество» 12+
13.00 А. Цагарели. «ХАНУМА». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Соотечественники» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.30 «Әдәби хәзинә» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Илфат Фәйзрахманов 12+
22.00 «ПРИТВОРИСЬ МОИМ ПАРНЕМ» 16+
23.35 «ВЕСЁЛЫЕ РЕБЯТА» 0+
01.10 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
05.50 Татарстан хәбәрләре 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Ватандашлар» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00 «Галиҗәнап шагыйрь». Гамил Афзалның тууына 100 ел тулуга багышланган кичә 6+
09.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Булат Гыйльванов турында телеочерк 6+
10.00 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Нәсыйхәт» 6+
13.30 «Татар сүзе» II Халыкара нәфис сүз бәйгесенең гала-концерты 6+
16.00 Нәҗип Җиһанов исемендәге «Мирас» VII татар музыкасы фестивале 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 Илсея Бәдретдинова концерты 12+
22.00 М.Кәрим. «АЙ ТОТЫЛГАН ТӨНДӘ». Чаллы татар дәүләт драма театры спектакле 12+
23.45 «Ком сәгате» 12+
00.40 «Яшьләр тукталышы» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
02.50 «Җырлыйм туган якта». Илгиз Закировның иҗат кичәсе 12+
04.40 «Күңелемдә яз». Георгий Ибушев концерты 6+

1 КАНАЛ
05.15, 06.10 «ТОТ, КТО ЧИТАЕТ МЫСЛИ» («МЕНТАЛИСТ»). Многосерийный фильм (S) 16+
06.00 Новости
07.05 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.45 «Часовой» (S) 12+
08.15 «Здоровье» 16+
09.15 «Непутевые заметки» с Дм. Крыловым 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «Голос из прошлого. Холодная война Никиты Хрущева» 16+
11.20 «Видели видео?» (0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» (0+
13.20 Юрий Колокольников, Антон Хабаров. «ВОСКРЕСЕНСКИЙ» (S) 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 «Воскресенский» (S) 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.25 «ДЖЕНТЛЬМЕНЫ УДАЧИ». ВСЕ ОТТЕНКИ СЕРОГО» 12+
19.20 Комедия «ДЖЕНТЛЬМЕНЫ УДАЧИ» 12+
21.00 «Время»
22.35 Донатас Банионис, Жанна Болотова, Владимир Высоцкий, Алла Демидова. «БЕГСТВО МИСТЕРА МАК-КИНЛИ» 12+
01.25 «Наедине со всеми» 16+
02.55 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1
05.35 Ольга Котельникова, Анатолий Руденко, Анатолий Котенёв, Любовь Руденко. «БУКЕТ» 12+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.40 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
12.40 Анастасия Заворотнюк, Алексей Кравченко, Андрей Соколов, Вера Сотникова, Раиса Рязанова. «Я БОЛЬШЕ НЕ БОЮСЬ» 12+
17.00 Вести
18.00 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 Премьера. «Кресты» 12+
03.10 Ольга Котельникова, Анатолий Руденко, Анатолий Котенёв, Любовь Руденко. «БУКЕТ» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 Смешанные единоборства. UFC. Исраэль Адесанья против Джареда Каннонира. Прямая трансляция из США
08.00, 08.55, 12.05, 18.50 Новости
08.05, 13.05, 15.10, 16.40, 18.55, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 «БАБА ЯГА ПРОТИВ». Мультфильм 0+
09.20, 12.10, 23.45 «ЗАГОВОРЁННЫЙ» 16+
13.55 Пляжный футбол. Чемпионат России. «Дельта» (Саратов) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
15.25 Пляжный футбол. Чемпионат России. «Кристалл» (Санкт-Петербург) – «Локомотив» (Москва). Прямая трансляция
16.55 Бокс. Матч ТВ Кубок Победы. Прямая трансляция из Казани
19.30 Футбол. Товарищеский матч. «Зенит» (Россия) – «Црвена Звезда» (Сербия). Прямая трансляция из Сочи
22.45 Смешанные единоборства. UFC. Исраэль Адесанья против Джареда Каннонира. Трансляция из США 16+
03.15 Новости 0+
03.20 Пляжный футбол. Чемпионат России. Сборная Санкт-Петербурга – ЦСКА 0+
04.40 Пляжный футбол. Чемпионат России. «Крылья Советов» (Самара) – «Строгино» (Москва) 0+

НТВ
05.10 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
07.25 «Простые секреты» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу (S) 12+
10.20 «Первая передача» (S) 16+
11.00 «Чудо техники» (S) 12+
12.00 «Дачный ответ» (S) 0+
13.00 «НашПотребНадзор» (S) 16+
14.00 «Своя игра» (S) 0+
15.00, 16.20 «Следствие вели...» (S) 16+
19.40 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
22.30 «Маска» (S) 12+
01.50 «Таинственная Россия» 16+
02.30 «ДИКИЙ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
07.00 «ЛЮБЛЮ ОТЦА И СЫНА» 16+
10.55 «ТЕНЬ ПРОШЛОГО» 16+
14.45 «ХРУСТАЛЬНАЯ МЕЧТА» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК». 103-я и 104-я серии 16+
22.45 «СЛЕПОЙ ПОВОРОТ» 16+
02.20 «ИДЕАЛЬНЫЙ БРАК». 5-я – 8-я серии 16+
05.45 «Лаборатория любви» 16+

ЗВЕЗДА
05.55 «ЖАЖДА» 12+
07.10 «ВЫСОТА 89» 16+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
10.30 «Военная приемка» 12+
11.15 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №44» 16+
12.05 «Код доступа». «Русское золото для английской королевы» 12+
12.50 «Легенды армии» с Александром Маршаломи. Василий Брюхов 12+
13.35 «Специальный репортаж» 16+
14.15 «УЧАСТОК ЛЕЙТЕНАНТА КАЧУРЫ» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
20.00 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
22.55 «ДАУРИЯ» 12+
02.05 «МАФИЯ БЕССМЕРТНА» 16+
03.35 «СОЛЕНЫЙ ПЕС» 12+
04.45 «Перелом. Хроника Победы». Док. сериал 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?
Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 27 июнь
6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Гаяз Исхакый. «Татар кызы». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 28 июнь
6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.20 «Вместе за безопасность»
18.30 Лирик концерт

Чәршәмбе, 29 июнь
6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 «Вместе за безопасность»
7.20 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Вокаль һәм инструменталь дуэтлар. Концерт

Пәнҗешәмбе, 30 июнь
6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Юрий Виноградов әсәрләре

Җомга, 1 июль
6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 «Җәйге кичләр». Концерт

Шимбә, 2 июль
8.10 Фәннур Сафин әсәрләреннән әдәби-музыкаль композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтием өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре». Рөстәм Кутуй шигырьләре, Туфан Миңнуллинның «Әни хикәясе»

Якшәмбе, 3 июль
8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Кәмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 Аяз Гыйләҗев. «Шикәрем син, балым син». К. Тинчурин ис. ТДДҺКТ спектакленең радиоварианты

ЕРЫК АВЫЗ

Юләрләр йортына тикшерү белән килгән инспекторга аңлаталар: «Кешенең юләрме, акыллымы икәнен белү өчен без болай эшлибез: ваннага су тутырабыз, анда авыруны кертеп утыртабыз, аның кулына кашык белән кружка тоттырабыз һәм ваннаның суын түгәргә кушабыз». «Ә-ә, аңладым! – ди инспектор. – Акыллы булса, суны кружка белән түгә, юләр булса...» «Юк, – дип бүлдерә аны врач. – Акыллы булса, ванна төбендәге бөкене тартып чыгара...»

***

– Бик яхшы кер юу машинасы сатып алдым. Үзе юа, үзе сыга. Ә иң мөһиме – берниндә тавышы юк!
– Ә минеке үзе суын, порошогын сала, юа, сыга, әмма тавышына чыдарлык түгел.
– Чит илнекедер әле?
– Нинди чит илнеке булсын, күрше авыл кызы!

***

Төнлә ир кеше нииндидер тавыштан уянып китә. Күзен ачса, берәү шкаф тартмаларын актарып маташа.
– Әй, син нәрсә эзлисең анда?
– Акча!
Ир кеше артына борылып ята.
– Тапсаң, уят.

Сәрия МИФТАХОВА

САЯДА ГОМЕР ҮТМИ ЗАЯ

«160тан артык хуҗалыклы авылыбызда 4–5 көтү чыга. Казанга 4–5 машина белән сөт ризыклары сатарга йөрибез». Биектау районының Сая авылына килү өчен безгә шул сүз дә җитте. Район буенча иң күп терлек асраучылар да монда икән. Көтүчеләре арасында Алтайдан кайтучылар да бар. Авылның мал-туардан бизмәвенең хикмәте нидә?

Илдар Мөхәммәтҗанов



Мал яраталар

Әлдермеш авыл җирлеге башлыгы Нияз Усманов әйтүенчә, җирлектә 457 баш терлек асрала. 236сы – сыерлар. Саяда сөтлебикәләр саны – 125. Уртача алганда, 3–4 сыер тоталар. 15не, 10арны асраучылар да бар. Ә менә Әлдермеш авылы ике тапкыр зуррак булса да, анда терлек асраучылар бик аз. Авылда сөтнең литрын 29 сумнан җыялар.

– Халык телендәге «Биш өйле» урамына барсагыз, теләсә кайсы йортта күпләп терлек асраучыларны табарсыз. Сыерларның баш саны кимеми, киресенчә, арта бара. Сая халкының хайван яратуына бәйле бу. Казан да якын бит. Үз продукцияләрен шәһәргә илтеп сатучылар да бар. Менә шулай акча эшләп көн күрәләр. Хөкүмәт биргән субсидиянең дә файдасы тия. Әйтик, хуҗалыкта сыерың өчтән артса, баш санына карап, 4 мең 300 сум акча бирелә, – ди Нияз Усманов.

Шәһәр кызы Лилия

Авыл башлыгының сүзен истә тотып, «Биш өйле» урамына юл алдык. Чынбарлыкта 13 йортлы Дан урамы икән бу. Үзе бер утрау кебек. Анда яшәүчеләр: «Бездә балалар да, сыерлар да күп», – дип шаярттны. Үрдәге, казы, сарыгы, кәҗәсе дә бар монда. Хәйруллиннар гаиләсе 15 сыер, 340 баш сарык асрый дигәч, иң беренче булып аларга кердек. Өстәвенә хуҗабикә Лилия шәһәр кызы икән. Эшкә батыр булып чыкты ул. 23 ел элек Казаннан кайткан килен авыл тормышына күптән ияләшкән. Без килгәндә, сөт бидоннарын юып бетергән иде инде. Аннан тиз генә чебешләр йолкып алды.

– Минем әти-әни – бу авылныкы. Казанда туып-үссәм дә, каникулларым әби янында узды. 18 яшьтә кияүгә чыктым, хәзер миңа – 41, – дип башлады Лилия сүзен. – Авылга кайтканга бер дә үкенмим. Беренче көнне үк сыер сава башладым. Берне түгел, өчне! Каенанам кушмады, абзарга үзем чыктым. Хәзер бар да автоматлаштырылган. Шулай да кайвакыт кул белән саугалыйм әле.

Хәйруллиннар беркайчан да сыерсыз тормаган. Тик баш саны бергә калган чаклары булган. Лилия берара Биектауга барып, пешекче булып эшләп алган. Шуңа күрә терлек санын киметергә туры килгән. Читкә йөреп эшләү туйдыргач, 2012 елдан малларын арттырып, шәхси хуҗалык булдырганнар. Мәшәкате күп булса да, Лилия зарланмый.

– Иртәнге сәгать дүртенче яртыда торам. Кичке 11гә кадәр эш бетми. Йокының беркайчан да туясы юк. Йокласаң, эш бармый. Бу яшьтә хәзер каядыр чыгып китеп эшлисе килми. Шуның өчен иртүк торып, 15 сыер савудан курыкмыйм. Кайбер көнне артыграк арып китсәм, ачу да чыгып куя. Икенче көнгә барысы да онытыла, – ди хуҗабикә.

Сыер сөтеннән каймак аертып, катык, эремчек, корт ясап саталар. Казанга атнага биш көн йөриләр. Бигрәк тә декрет ялындагы әниләр, әбиләр ишегалдында көтеп тора икән. Сөтнең литрын 50 сумнан саталар. Лилия әйтүенчә, авыл ризыгын талымлап тормыйлар, кайсын да яраталар.

Азыгы да, печәне дә кирәк

Хәйруллиннар сыер гына түгел, сарык та асрый. Шуңа күрә азыгын да күп итеп әзерләргә кирәк. Печәнне гадәттә үзләре әзерли. Пай җирләре бар. Тик быел печән җитмәгән. Ике ай ашатыр өчен 70 мең сумлык печән сатып алганнар. Бер рулоны – 2500 сум. Солярка да кыйммәт. Терлек асрау арзан түгел. Дәүләткә өметләнмиләр. Шулай да лизингка трактор алганда, 300 мең сум ярдәм тигән. Монысына да рәхмәтле авыл кешесе.

– Терлек асрасаң, көтүгә чыгарырга кирәк. Әмма берәү дә көтүче булырга атлыгып тормый. Әллә оялалар шунда. Без үскәндә, 13–14 яшьлек малайлар чыга иде. Хәзер әти-әниләре дә каршы. Алар балаларын үзләре ашатаэчертә хәзер. Бер айга 30 мең сум хезмәт хакы чыкса да, көтү алырга ризалашучы юк. Аптырагач, ерактан эзләп кайтырга туры килде. Викторга үз йортыбыздан аерым бүлмә бирдек. Ашатабыз, киендерәбез, көтү көткән өчен акча бирәбез. Аңа ышанабыз, әйбәт кеше, – ди Илшат.

Алтай Саяга җитми

Хәйруллиннарда ике ел көтү көткән Виктор Олейникны да күрмичә китәсе килмәде. Аны монда нинди җилләр ташлаган? Авылдан 5–6 чакрым ераклыктагы урман буеннан эзләп таптык аны. Сарыклар тыныч кына үлән чемченә. Арада ике кәҗә дә күренә. Көтүче абыйлары янәшәләреннән атлый. Кулында – таяк.

– Алар бит сабыйлар кебек. Синең ятуыңны тоялар. Тавышыма ияләшсеннәр дип, үз-үзем белән дә сөйләшеп йөрим. Тыңламасалар, кычкырып та алам. Шундук туктыйлар. Көтүдә һәрвакыт әйдаманнар була. Безнекендә – ике тәкә. Берсе сөзә торган. Чит кешене күрсә, еракка кадәр куып бара. Холкын белгәч, миңа тими. Ипи ашатып тәрбияләдем бит аны, – ди Виктор.

Казахстанда туып-үскән егетнең тормышы җиңел булмаган. Соңгы елларда Алтай якларында яшәгән. Әти-әнисе мәрхүм, туганнары белән дә аралары өзелгән. Быел апрель аенда туган якларына киткән булган, тик Саяга кабат әйләнеп кайткан. Викторның көтүче булып китүе очраклы килеп чыккан. Казанга эшкә дип килгән ир җиде юл чатында калган. Эшләгәненә акча түләмәгәч, танышлары аңа авылга кайтырга тәкъдим иткән. Аның бәхетенә яхшы, гадел кешеләр очраган.

– Иртәнге сәгать 7дән чыгып китеп, кичкә кадәр болында мин. Әлбәттә, җиңел түгел. Хуҗаларым төшке ашны үзләре китерә. Татарча белмим, тик кайбер сүзләрне аңлый башладым инде, – ди Виктор, елмаеп. – Көтүче булыр өчен сабырлык кирәк. Миндә бар ул. Эссегә дә, салкынга да түзәм. Кар төшкәнче сахрада йөрим. Авылның табигате матур. Саф һава. Матурлыкны күрә беләм. Көн тизрәк үтсен дип, җәен җиләк җыям. Эштән кайткач, балыкка да баргалыйбыз. Менә шулай гомер үтә. Кире китәргә исәбем юк.

Көнгә 1 мең сум түлиләр

Кайтканда юлыбызда сыер көтүчеләр очрады. Малларны туплаган вакытлары иде. Сыерлар елгадан су эчә. Көтүчеләр төшке аш ашый. Шәһәрдән кайткан 4 яшьлек Азамат та көтүгә ияреп килгән. Ул сөтнең елгадан акмаганын, аны сыерлар биргәнен аңлый. Чыбыркы шартлатып караган, тыңламаган сыерларны үзенчә ачуланган була.

– Кеше чираты өчен чыктым. Кем чакыра, шуңа барам. Көнгә 1 мең сум түлиләр. Быел гына чыккаладым әле. Моңа кадәр шабашкада йөргән идем, эш юк бит, – диде Фәнис Гайнетдинов.

Ә менә аның адашы көтүгә 3 нче сыйныфтан ук көтә икән. «Чакырганда, көн саен чыккалыйм. Кая барасын, киреләнеп торып булмый. Ашыйсы килә, яшәргә кирәк бит. Мең сум бирәләр, авыл җирендә ярый инде», – ди икенче Фәнис.

Сая сыерлары бәхетле. Алар киртә арасында ятмый, электр чыбыгы ирекләрен чикләми. Иң мөһиме, авылда көтү чыкмый дип күңел сыкрарлык түгел. Элек урам тутырып кайткан сыерларга исебез китмәсә, хәзер китә шул. Күп җирдә тансыкка әйләнеп баралар. Сая халкы: «Сыерлар безгә кадерле, электән килгән шөгыль», – ди. Киленнәр дә озак йокларга күнекмәгән. Авылда сыерлар мөгрәве тынмауның хикмәте шунда гына.

СЕЗДӘ КӨТҮ ЧЫГАМЫ?

Рәфкать ФӘТТАХОВ,
Чирмешән районының Лашман авыл җирлеге башлыгы:
– Безнең авылда – электр көтүче. Быел алтынчы ел шулай. Болай рәхәт бит. Көтүче табу проблемага әйләнгәч, халыктан акча җыеп, интернет аша җиһазлар кайтарттык. Бүген бер кеше шуңа күз-колак булып тора. Аңа сыер башына айга һәр хуҗалык 200 сум түли. Лашман авылында 80гә якын сыер йөри. Соңгы вакытта бу сан торгыклы, бик азга калган чаклар да бар иде. Электр көтүче булгач, мини-ферма программасы эшләгәч, бар да үз урынына кайтты.

Нәсимә ФӘЙЗУЛЛИНА,
Баулы районының Исергәп авылы хат ташучысы:
– 380нән артык йорт бардыр авылда, меңләп кеше яши дип беләм. Пенсионерлар күп. Авылда көтү чыкмый. Көтүче юк. Кешеләргә кыен инде. Шуңа күрә сыерларын бетерүчеләр дә булды. Безнең урамда берничә хуҗалык электр көтүче куйды.

Хәмит ГӘРӘЕВ,
Әтнә районының Күлле Киме авыл җирлеге башлыгы:
– Күлле Кимедә көтүне үз авылыбыз егетләре көтә. Көтүчегә мал башына бирелгән 1800 сум акчаның 300ен колхоз түли. Бу – аларны ашату өчен. Өстәвенә ашлык бирә. Фермер хисабына көтүгә йөрүче сыерлар арткан иде. Тик быел ул аерым көтә башлады. Авылда барлыгы 90нан артык сыер бар. Хуҗалыктагы 60 сыерның 40ы гына көтүгә чыга. Калганнарын болында аркалыйбыз, үләнне чабып ашатабыз. Ары авылында исә көтү бөтенләй чыкмый. Кигәвен күп булгач, халык малларын кызгана.

rbth.com

КАРА ТАМГА

Башлангыч сыйныфларда ук түгелме икән, авыл клубында караган фильмнан (исемен хәтерләмим) бер күренеш күңелгә онытылмаслык булып уелып калган.

...Бөек Ватан сугышы тәмамланган көннәр. Авыл яуда исән калган батырларны каршылый. Ире сугышта һәлак булган бер ананың өлкән кызы да, орден-медальләр тагып, фронттан кайтып төшә. Әмма әнисе аны бусагадан да кертми. «Кеше күзенә күренеп йөрмә. Өйдә ике сеңлең бар. Аларны ничек кияүгә бирермен?» – дип, кирәк-яраклар белән алдан ук әзерләп куелган биштәрне чыгарып бирә дә ишекне борын төбендә шарт итеп ябып куя. «Нишләп куып чыгарды ул аны?» – дип сорап йөргәнем генә хәтердә.

Яу кырында батырларча сугышкан хатын-кызлар ни сәбәпле мондый гаделсезлеккә тап булалар? Әлеге сорауга беренче тапкыр Нобель премиясе лауреаты, белорус язучысы Светлана Алексиевич 1983 елда дөнья күргән «У войны не женское лицо» китабында ачыктан-ачык җавап бирә. Аңа кадәр бу тема тыелган булып санала. Җыентыкта исә сугышта катнашкан хатын-кызларның истәлекләре урын алган.

Мөнәсәбәт

Бөек Ватан сугышына кагылышлы фәнни язмалардан күренгәнчә, яу кырында хатын-кызларга мөнәсәбәт төрлечә була, хәтта фаҗигале төс тә ала. Тәҗрибә җитмәгәнлектән, көчсез булганлыктан, күбесенең һәлак булуы, дошман кулына эләгә, мәсхәрәгә дучар ителүе – бер хәл, моннан тыш фронтта рәсми булмаган «сөяркәләр институты» да яшәп килә. Дөрес, монда мәхәббәткә дә урын булган дип уйларга кирәк. Ни әйтсәң дә, тормыш – тормыш инде ул, сөю хисләренә өстән яуган ут та комачаулый алмый. Әмма, тарихчыларның тикшерүләреннән күренгәнчә, күбесе командирлар тарафыннан бергә яшәргә мәҗбүр ителә. Әнә шушы хәлләр кызларның сугыштан соңгы тормышларына кара тамга сала да инде. Халык өчен, бигрәк тә офицер хатыннары өчен алар «сугыш кырында солдатлар белән тәртипсез тормыш алып барган бозык кызлар»га әйләнә. Ахыр чиктә хатын-кызларның күбесе, нинди генә батырлыклар кылса да, үзләренең сугышта булганнарын яшерергә мәҗбүр булалар, орден-медальләрен тагып йөрмиләр, туган җирләренә кайтырга оялалар, танышлары белән очрашудан качалар.

Тарихчылар аңлатуынча, яу кырында сөяркәләрнең пәйда булуы фронт шартларына яраклашырга тырышудан да килеп чыга. Бу адымга барган хатын-кызлар яклау таба, яхшырак туклана, башка ир-атларның бәйләнүеннән котыла. Әмма мондый хәл тотрыклы булмый, командирлар хатын-кызларны бик еш алыштырып тора, ташланганнары, аңлашыла ки, бик авыр хәлдә калып, кыерсытуларга дучар була.

Бу хәлләргә кагылышлы документлар да сакланып калган. Мәсәлән, 1942 елның 6 маенда Хәрби Диңгез флоты наркоматының 1365 нче боерыгы нигезендә 1942 елда фронтка чакырылган 21292 хатын-кызның 1878е «бозыклыгы һәм балага узуы сәбәпле» армия сафыннан куыла.

Әйтергә кирәк, соңрак хатын-кызларга булган мондый мөнәсәбәт үзгәрә төшә. Моңа бигрәк тә Андрей Смирновның «Белорусский вокзал» фильмы һәм Светлана Алексиевичның югарыда телгә алынган китабы ярдәмгә килә.

Тормыш... ормыш

Сугышта катнашкан кызлар арасында нинди генә һөнәр ияләре юк: шәфкать туташлары, табиблар, очучылар, зенитчылар, снайперлар, кер юучылар, пешекчеләр... Әмма ничек кенә булса да, сугыш кыры хатын-кызлар өчен түгел, алар психологик яктан да, физик яктан да зур авырлык кичерә, сәламәтлекләре нык какшый. Нәтиҗә буларак, яудан исән-сау кайтканнарның да күбесе, гаилә корып, бала таба алмый торганга әйләнә.

Бу аңлашыла да: яу кырындагы көнкүреш хатын-кызлар өчен яраклаштырылмый бит. Сугыш мондый юнәлеш алыр, гүзәл затлар ут эчендә калыр дип беркем дә көтми. Гадәттә 5–6 солдат урнашкан бер землянкада, пәрдә артында хатын-кызлар да яшәргә мәҗбүр ителә. Әле сугыш башланганда хәрби киемнәр ир-атлар өчен генә тегелә, иң кечкенә аяк киеме 42 нче размер була. Хатын-кызлар ирләр киемен үзгәртеп, үзләре тегәләр.

✓ Бөек Ватан сугышында **93** совет хатын-кызы Советлар Союзы Герое исеменә лаек була.
✓ Татарстаннан Бөек Ватан сугышында **10000** хатын-кыз катнаша. Татар кызлары арасында бердәнбер Советлар Союзы Герое бар. Ул – очучы Мәгубә Сыртланова. Батыр кыз сугыш кырында хәтта яраланмый да. Исән-сау кайтып, Казанда яши, «Радиоприбор» заводында контролер булып эшли, **1971** елда бакыйлыкка күчә. Башкалабызның Идел буе районында бер урам аның исемен йөртә. Җиңү проспекты һәм Сыртланова урамы чатына бюсты куелган.

Итәк кигән килеш алгы сызыкта сугышып йөреп булмый бит. Шинель урынына аларга телогрейка бирелә. Ул юешләнсә, бик озак кипми йөдәтә.

Белгечләр әйтүенчә, корал тотып сугышмаган кызларның да хәле искиткеч авыр була. Мәсәлән, кер юу иң авыр хезмәт булып санала. Кышмы-җәйме, кармы-яңгырмы – бөтен кер урамда, кулдан юыла. Сабын урынына кулланылган селтедән бармакларның тиреләре суелып каный.

Гигиена мәсьәләләре дә шәптән булмый. Хатын-кызга хас булганнары турында әйтеп торасы да юк. Беттән интегәләр. Кызларның чәч толымнарын кисеп атып, башларын кыралар. Яндыра торган препаратлар белән эшкәртәләр.

Күпме сез, гүзәл затлар?

Кызыл Армиядә, гомумән, хатын-кызларга мөнәсәбәт бик үзенчәлекле булып санала. Әйтергә кирәк, ул чорда сугышка кергән башка илләр дә хатын-кызларны чакырырга мәҗбүр булалар. Әмма бездәге кебек кулга корал тотып сугышырга түгел, башка эшләргә. Бездә исә, документлардан күренгәнчә, хатын-кызлар сугышның беренче көненнән үк хәрби комиссариатларга агыла. 1941 елның җәй айларында хәрби хезмәткә яраклы медицина хезмәткәрләренә генә игътибар була әле. Көз көне хатын-кызлардан гына торган өч авиация полкы оештырыла. 1942 елның язында исә үзләре теләп китәргә теләүчеләрне дә армиягә ала башлыйлар. Бу вакытка инде яңа частьлар төзү өчен ир-атларның гына җитмәве ачыклана. Башта хатын-кызлар кер юучы, пешекче кебек хәрби вазыйфаларда булмаган ирләрне алыштырыр дип уйланыла, әмма хәлләр инде мөшкел була: сугышка гүзәл затлар ихтыяри-мәҗбүри рәвештә барып керәләр.

Бөек Ватан сугышында ничә хатын-кыз катнашкан? Күп кенә фәнни язмаларда бу сан 800000 дип күрсәтелә. Дөресрәге, бу сан беренче тапкыр Вера Мурманцеваның «Бөек Ватан сугышында совет хатын-кызлары» дигән китабында 1974 елда пәйда була. Аңа кадәр мондый мәгълүмат сер булып саклана. Оборона министрлыгының рәсми документларында бу сан – 490235. Шуларның 430 меңе фронтка 1942–1943 нче елларда чакырылган. Димәк, монда 1941 елда һәм 1942 елның башында әсирлеккә төшкән, яу кырында башын салган хатын-кызлар бөтенләй исәпкә керми. Бу чорда юкка чыгарылган, әсирлеккә төшерелгән хәрби частьлар турында архивларда гомумән мәгълүмат сакланмый. Димәк, бу кешеләрнең язмышы да билгеле түгел дигән сүз.

Партизаннар

Сугыш елларында хатын-кызлар батырлыгын өйрәнүче галимнәр әйтүенчә, партизан отрядларында да аларның роле зур була. Кызганыч, бу очракта да төгәл санны билгеләү мөмкин түгел. Чөнки отрядлар төзелә дә бераздан юкка чыга. Алар турында бернинди мәгълүмат та калмый. Дөрес, фашистлардан арындырылган территорияләрдә Бөек Ватан сугышы тарихы буенча комиссия вәкилләре хәрбиләр, партизаннар, җирле халык белән сөйләшүләр алып баралар. Әмма төгәл санны билгеләү өчен бу гына җитми. Немецлар басып алган җирләрдә партизан отрядларына төрле яшьтәге хатын-кызлар әләгә. Алар я үзләре урманга качалар, я яшерен комсомол оешмалары юнәлеш бирә. Кайчакларда элемтәче яки агент булып хезмәт итү өчен махсус өйрәтелгән кешеләрне самолеттан десантчы итеп тә төшерәләр. Алар кирәкле мәгълүматларны җиткерәләр, халыкны отрядларга китәргә өндиләр, яшерен оешмадагыларны партизаннар белән очраштыралар. Отрядлардагы хатын-кызлар ашарга әзерлиләр, яралыларны дәвалыйлар, разведкага йөриләр, эшелоннарны шартлаталар, сугышларда катнашалар.

Ничек кенә булса да, хатын-кызларның җиңүгә керткән өлешләре искиткеч зур булган – бу бәхәссез. Саннар да шуны күрсәтә. Нинди генә тыюлар булса да, без – барыбер ил данын яклаган хатын-кызларны белеп үскән буын.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сорап тормадылар...

Заманында сугышта катнашкан районда хатын-кызлар турында күп язылган. Геройларымның берсе – Бөрбаш кызы Нурҗиһан апа Хөснетдинова 15 июньдә генә бакыйлыкка күчте.

– Кыш буе Кайбыч районында ачлы-туклы окоп казып, хәлдән тайгач, 1942 елның июнендә хәрби комиссариатка чакырттылар. Үземне генә түгел. Яз буе авыл мәктәбендә «хәрби әзерлек» үткән – мылтык сүтеп җыярга, атарга, противогаз кияргә өйрәнгән яшьтәш кызлар белән бергә. Әмма Нәгыймә белән икебезне генә «яраклы» дип таптылар, – дип сөйләгән иде ул.

1942 елның июнендә сугышка чыгып киткән Сосна кызы Җиһан апа Хәбибуллина исә: «Барасың киләме, дип сорап тормадылар шул, – дигән иде. – Тел белмибез, русча сөйләшә алмыйбыз, зинһар, кайтарыгыз дип елаганга да исләре китмәде. «Монда болытлар да бездәге төсле түгел», – дип елый идек... Бармак бәйли белмәгән килеш күпме авыр яралыларга ярдәм күрсәттек...»

Түбән Кенә кызы Тәскирә апа Галимуллинаны (районда исән-сау булган өч сугыш ветеранының берсе) сугышка 17 яшендә алалар. «Әтиебез колхоз председателе иде, сугышка кадәр кулга алдылар. Аннан «халык дошманы» ясаганнарын да белмәдек.1943 елның июнендә сугышка алдылар, элемтәче булып хезмәт иттем. Җиңүне Польшада каршы алдым. Бик матур яклар. Сугыш беткәч, киноны да иң беренче тапкыр Брест шәһәрендә карадым. Без бит – бик тә хәерче тормыштан килгән авыл балалары. Нәрсә күргән инде без? Беренче кигән рәтле киемебез дә шинель, гимнастерка булды. Брестта калыгыз, дип бик кыстадылар. Калмадым. Кайтсак, андагы хәерчелек... Әти өчен каһәрләүләр... Ник кайттым, дип үкендем. Әнием бик акыллы, сабыр кеше иде. «Тормышлар көйләнер. Монда да яшәү рәхәт булыр. Кунакка кайтырсың, нигә чит җирләрдә калдым икән, дип йөрәгең әрнер», – дип үгетләде. Ялгышмаган, менә бүген тормышыбыз ничек матур».

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Каймак» тәме

Биектау районының Ямаширмә авылында урнашкан тәвә кошы фермасы хуҗасы Габделәхмәт Котдусовны республикада агротуризмда азау ярган кеше буларак беләләр. Ферма өч ел рәттән 20 мең туристны кабул иткән. Узган ел хәтта көненә 1 меңнән артык кеше килгән чаклар булган. Араларында унар тапкыр килүчеләр дә бар икән.

– Агротуризмның киләчәге зур. Мин аны алдан күреп, «каймагы»н ашадым инде, – ди рәсми төстә 2010 елдан бирле эшләп килүче фермер үзе дә. – Шуңа күрә башкалар эш башлаганда, мин тыныч күңел белән яба да алам. Быел безнең белән бик күп турфирмалар эшли. Туристлар фермага килгәч, кошларны карый, йомырка сатып ала, күлдә балык тота, атларда һәм катамараннарда йөри. Шунысы яхшы: республикада агротуризм белән кышын да шөгыльләнеп була, – ди ул.

Габделәхмәт Котдусов – 30 елдан артык яшелчәчелек, игенчелек белән шөгыльләнүче фермер да әле. Тик аның сүзләренчә, соңгы өч-дүрт елда ул төп табышны туризмнан ала.

– Узган ел игенчелек өчен авыр ел булды. Ә туризм, киресенчә, чәчәк атты. Язын башка тармакларда чыгымнар арта, туризмда, киресенчә, апрель – май айларында керем арта. Күзен, әлбәттә, игенче табышын саный, безнең исә туристлар кими. Аның каравы җәй буе яхшы гына эшләргә була, – ди ул.

Баулыда яшәүче ирле-хатынлы Гөлнара һәм Шамил Гафуровлар кунакларны мичтә пешерелгән ризыклар белән җәлеп итә. Аларның үзләренең рестораны, музее, кунак йортлары бар. Әлеге объекттан ерак түгел генә тагын берничә йорттан һәм мичләрдән торган утар җиткереп киләләр. Шунда атта йөрергә һәм башка төр хайваннарны да күрергә мөмкин булачак.

– Үзебез икенче катта яшибез, эшебез – беренче катта, – диде Гөлнара Гафурова. – Кунарга да калалар. Ипидән башлап бәлешләргә кадәр мичтә пешерәбез. Казылык, сырны да үзебез ясыйбыз.

Аның әйтүенчә, республикада агротуризм белән шөгыльләнү отышлы.

– Урыныбыз да бик яхшы. Уфа, Октябрьский, Оренбург якын булгач, бу шәһәрләрдән бик күп кеше килә. Пандемиягә кадәр эшләребез гөрләп барды, хәзер дә зарланырлык түгел. Халык күп килә, хәтта өлгереп булмый. Чөнки биредә һава да чиста. Гөмбә, җиләк үсә торган урыннар да күп. Алга таба да планнар зурдан, – диде хуҗабикә.

«Үзебезне күрсәтә белмибез»

Авыл туризмының асылы нидән гыйбарәт? Әлеге сорауны без Төбәк авыл туризмы ассоциациясе рәисе Руфия Мөхәммәдиевага бирдек. Аның сүзләренчә, чынлыкта туризмны, кайда урнашуына карап, авылныкына һәм шәһәрнекенә бүләргә мөмкин.

– Бездә күпчелек шәһәр туризмы үсеш алган. Ә авыл туризмы дигәндә, аның төп шарты – авылга бәйле булуы. Ә инде әчтәлеге төрлечә булырга мөмкин: экология, төбәкне өйрәнү, танып белү, экстремаль, аграр яки этник, – дип аңлатты ул.

Кызганыч, Татарстанда авыл туризмының ни дәрәҗәдә киң җәелгәнен чамаларга мөмкинлек бирүче саннарны белә алмадык. Руфия Мөхәммәдиева әйтүенчә, бу юнәлеш буенча статистика алып барылмый. Югыйсә туристлар саны шактый булыр иде, ди ул.

– Кунак йортлары шулай ук авыл туризмына карый. Хәтта коронавирус вакытында бөтен төр туризм туктаган чорда да аларда халык кимемәде. Тик, кызганыч, исәп кенә алып барылмады, – ди ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЕРАК БАРАСЫ ДА ЮК

Дөрес, 2016 елда ассоциация бернича кадәр мәгълүмат туплаган булган. Ул елда Татарстан авыллары 7 мең тирәсе туристны кабул иткән.

– Гомумән алганда, авырлыклар, эшлисе эшләр бик күп булса да, Татарстан агротуризм буенча алга киткән төбәк булып санала, – ди Руфия Мөхәммәдиева. – Әйе, бездә, чыннан да, 15–20 ел дәвамында бу юнәлештә эшләүчеләр бар. Тәҗрибәләре белән генә түгел, зурлыклары, эшләү тәртипләре буенча да аерылып торучылар шактый. Кыскасы, республикада бүгенгә якынча 60 объект булырга тиеш. Ләкин монда барысы да – авыллардагы музей-тыюлыклар да, йорттагы зоопарклар да, кунак йортлары да кергән. Теләүчеләр күп, тик эшләүчеләр аз. Ягъни әлеге 60 объектның барысы да бүгеннән кунаклар кабул итәргә әзер түгел.

Язма әзерләгәндә, интернетта шактый эзләнергә туры килде. Тик авыл туризмы объектларын бергә туплаган платформа да, бар кеше белә торган һәм уңайлы сервис та күзгә чалынмады. Дөрес, кайберләренең аерым сайтлары бар. Тик аларның да күпчелегендә мәгълүмат я искергән, я бик аз. Турист каян мәгълүмат алырга тиеш соң?

– Әйе, сез хаклы, бездә андый проблема бар. Без үзебезне күрсәтә белмибез, – диде безнең соравыбызга каршы Руфия Мөхәммәдиева. – Күпчелек очракта туристлар Островок.ру, 2ГИС мәйданчыкларыннан файдалана. Районнардагы маршрутларны исә район сайтларыннан карарга мөмкин. Кайбер шәһәр һәм районнардагы объектлар «VizitTatarstan» туристик сайтының «1000 и одно удовольствие» бүлегендә бар. «Россельхозбанк»ның яңа платформасына да җиде объект кертелде. Шулай да әлегә иң нәтиҗәле юл – сарафан радиосы.

Мөмкинлек бар, теләк юк

Авыл туризмы буенча Татарстанның мөмкинлеге бик зур, – ди Руфия Мөхәммәдиева. – Коньяк-көнчыгыш районнар белән рәхәтләнеп эшләргә булыр иде. Шулай ук Баулы, Балык Бистәсе, Сабаларның да мөмкинлекләре зур. Гомумән, мин туристларны кабул итә алмаслык бер генә районны да белмим. Тик, кызганыч, аны беркем дә үстерми, дәүләт ярдәме юк дәрәҗәсендә, эшмәкәрләр авыл туризмын аңламый. Кыскасы, системалы эшләү җитми.

Ассоциация әлеге юнәлештә районнар белән дә күп эшли югыйсә. Урыннарда стратегик сессияләр оештыралар, сөйләшәләр, аңлаталар. Тик әлеге дә баягы планлаштыру, белем һәм тәвәккәллек җитми. Җитмәсә, Руфия Мөхәммәдиева әйтүенчә, урындагы җитәкчеләр дә эшмәкәрләргә аяк чала.

– Районнарда, туристлар бай булырга тиеш, дигән фикер бар. Тик чынлыкта аларның 80 проценты – урта хәлле, балалы 35–55 яшьлек гаиләләр. Күпчелеге – үзебезнең татарстанлылар һәм шәһәрдә яшәүчеләр, – диде ул.

Габделәхмәт Котдусов әйтүенчә, авыл туризмы ел дәвамында эшләргә һәм ул авыл белән бәйле булырга тиеш. Аның фикеренчә, агротуризм уңышлы булсын өчен, берничә шартның үтәлүе кирәк. Беренчесе – туризм объектының зур шәһәргә якын булуы, ягъни 30–50 километрдан ерак булмавы. Икенчесе – инфраструктура, ягъни объектның матур, төзек, зур авыл территориясендә урнашуы.

– Безнең Ямаширмә авылында – 365 хуҗалык. Анда 1200дән артык кеше яши. Барлык инфраструктуралары бар. Турист буларак чит төбәкләрдән килүчеләр, гадәттә, авылны да карарга теләк белдерә. Аларга горурланып күрсәтәм. Әтәч тә кычкырмаган авылга турист алып килүнең бер мәгънәсе дә юк, – ди ул.

Дүртенче шарт – шушы эш белән янып-көеп йөрүче кешенең булуы. Монысы – иң мөһиме.

– Авыл туризмы берлән шөгыльләнгән кеше беренче чиратта фермер булырга тиеш, – дигән фикерен җиткерде ул. – Аның үзенең хуҗалыгы, утары, базасы булса яхшы.

Ярдәм дигәннән, быел беренче тапкыр агротуризм юнәлешен үстерергә теләгән фермерлар дәүләттән яңа төрле ярдәм ала башлый. Татарстан Авыл хуҗалыгы министрлыгы хәбәр иткәнчә, алар 16 майдан грантларга гаризалар кабул итә башлады. Әлеге грантлар авыл хуҗалыгын үстерү дәүләт программасының «Авыл туризмын үстерү» федераль проекты кысасында тәкъдим ителә. Аның максималь күләме – 10 миллион сум. Проект үзен биш ел эчендә акларга тиеш. Аны аклар өчен, фермер үз акчасын да кертә: 3 миллион сумлык грант алу өчен проектның – 10, 5 миллион сумга кадәр – 15, 8 миллион сумга кадәр – 20, һәм 10 миллионга кимендә – 25 процент. Быел агротуризм өчен грантлар федераль бюджеттан 300 млн сум күләмендә бирелә.

Әлегә биредә дә хәл итәсе мәсьәләләр, киртәләр шактый икән. Мәсәлән, кунакханәләрне авыл хуҗалыгы җирләрендә төзергә ярамый. Агротуризмны үстерүдәге иң зур кыенлыкны шул тудыра, ди бу юнәлеш буенча эшләүчеләр.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАТАРСТАНДА АВЫЛ ТУРИЗМЫ ОБЪЕКТЛАРЫ

Тәвә кошы фермасы
Биектау районы, Ямаширмә авылы
Үзенчәлеге: Африка һәм Австралия тәвә кошларыннан тыш, монда башка төрле экзотик хайваннар һәм кошлар белән дә танышырга мөмкин.
Бәясе: зурларга керү билеты – 280 сум, 16 яшькә кадәрге балаларга һәм пенсионерларга – 200 сум, 3 яшькә кадәрге балаларга – бушлай. Биредә шулай ук суда беседкалар да арендаларга мөмкин. Анисының бер сәгате – 1200 сум.

«Кыргый ферма»
Балык Бистәсе районы, Степановка авылы
Үзенчәлеге: Биредә Алтайдан кайтарылган мараллар һәм тимгелле боланнарның матурлыгы белән хозурланырга мөмкин.
Билет бәясе: 250–500 сум.

«Алмакай» ат утары
Лениногорск районы, Югары Каран авылы
Үзенчәлеге: атларда йөрергә, тәмле кымыздан авыз итәргә мөмкин.
Билет бәясе: 800–1100 сум.

«Татар авылы» ачык һавада этнографик музее
Яшел Үзән районы, Исаково авылы
Үзенчәлеге: борынгы татар авылының яшәү мохите булдырылган уникаль комплекс.
Бәясе: зурлар өчен керү билеты – 200 сум, балаларга – 100 сум. Төп экскурсия – 1000 сум.

«Каенсар» экофермасы
Арча районы, Каенсар авылы
Үзенчәлеге: агротуризм (ферма буенча экскурсия, күл, балык тоту), экологик чиста ризыклар, татар халкының мәдәни һәм социаль мирасын саклау. Биредә шулай ук 3 кунак йорты бар.
Бәясе: бер тәүлеклек ял – 5000 сум.

ГАЗИНУР ФАРУКШИН:

«СӘХНӘ АГРОНОМСЫЗ КАЛГАН БАСУ КЕБЕК»

Татарстанның атказанган артисты Газинур ФАРУКШИНны Питрәч районының Әлбәдән авылында эзләп таптык. Хатыны Аннаның туган авылында йорт тергезәләр икән. Сәхнәдән кая югалдыгыз, дигәч, чакырган җиргә барабыз, куган җирдән китәбез, дип җавап бирде. Без аның белән үткәннәргә кайтып килдек, хәзерге сәхнә хәлләре турында сөйләштек.



Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Газинур абый, сәхнә сагындырамы?
– Олыгайгач, сәхнә дип ашкыну кими икән ул. Алай да чакырган җиргә барабыз, куган җирдән китәбез. Әле менә Сабантуйларда чыгыш ясадык. Актаныш, Саба якларында җырлап кайттым. Әмма үземнең концертлар оештырган юк инде.

:: Сәхнә кешесе, дигәч, күз алдына нәзберек, балта-чүкечтән ерак йөргән кеше килеп баса. Сез шуның нәкъ киресе.
– Сәхнәгә менү ир заты башкара торган эшләрдән ваз кичү дигән сүз түгел бит әле ул. Тормышны җырлап кына алып барып булмый. Хәер, андыйлар да бар инде, мин алай булдыра алмадым. Эшләмәгән эшем калмады. Консерваториягә чаклы эретеп ябыштыручы да булдым, аннары ун ел юлда йөрдем. Мин корал белән кыйммәтле йөкләрне озатып баручы идем. Мәсәлән, музей экспонатларын. Аның өчен дә укырга кирәк булды. Бу вакыт үз матурлыгы белән истә калды. Россиядә мин күрмәгән музей калмады, нинди экспонатлар, нинди кешеләр белән генә танышмадым. Бервакыт Поленов утарыннан картиналарны башка җиргә алып китәргә дип машинага төядек. Музей директоры янибызда елап басып тора. Нишләп борчыласың, исән-сау алып барып җиткерербез, дим. Сез җиткерерсез, Поленов кына кире кайтмас, ди. Менә бит үз эшенә бирелгән нинди ихлас кеше!

:: Югары белемле җырчының сәхнәдән китүе барыбер аңлашылмый.
– Булды инде хәлләр. Син бик кирәк түгел икән, нәрсәгә анда йөрергә? Хәзер болай да сәхнәне агрономсыз калган колхоз басуы белән чагыштыралар. Ничек кенә булмасын, җыр ул минем барыбер төп эшем инде. Алты ел укыган мин аңа. Бер ел училище, биш ел консерватория белемен алганмын. Ә кирәген калмаган җирдән китәргә кирәк. Хәер, ул чакта бик күп җырчыларның кирәге калмады. Чоры шундый иде аның.

:: Җырлап тормыш алып барып буламы?
– Була инде, нишләп булмасын?! Төп эше булганнар да туйларда, юбилейларда чыгыш ясый. Элек халтура диләр иде аны, хәзер эшкә чутлана. Мин төп эш итеп Бәйрәмнәргә йөри алмадым. Түбәнлек дип санадым микән инде… Күбрәк үзем төркем оештырып, гастрольләргә чыгып китә идем. Булмаган җир калмады инде. Урта Азия, Себер якларын аркылыга-буйга гиздек.

:: «Бәйрәм» ансамбле белән йөрдегезме?
– Юк, бу аларга чаклы булган хәлләр. «Бәйрәм» ансамбле белән дүрт ел гына бергә эшләдек. Хәниянең (Фәрхи. – **Ред.**) кешеләре азайган, минем дә төркемдә кешеләр кимегән бер вакыт булды. Шунда бергә кушылып эшләп алдык. Хәзер «Бәйрәм»не яңадан торгызыр идегезме?» – дип тә сорыйлар. Кирәк түгелдер дип уйлыйм. Берзаман Уфадан администраторлары шалтыратып, бөтен нәрсә белән булышабыз, әйдә оештырыйк, дип әйткән иде. Мин баш тарттым. «Бәйрәм» дигәч, күз алдына Хәния килә. Ә ул инде арабызда юк. Ансамбльне яңадан торгызу аның милкенә кул сузган кебек ул. Күңелемә ятмады.

:: Хәзерге сәхнә хәлләрен күзәтеп барасызмы?
– Җае килгәндә. Рәшит Ваһапов фонды белән Мәскәү, Уфа шәһәрләрендә концерт куеп кайттык. Филармония «Илһамият» концертларына чакыра. Шуннан чыгып әйтүем, безнең чор кешеләренә менә без – Зөһрәләр, Фердинантлар, Хәйдәрләр кирәк. Чөнки алар безне тыңлап картайган. Хәзергеләр үз яшендәгеләрне тыңлый. Бу – табигый инде. Синең «агрономсыз басу»га төрттерәсең килә. Сер түгел, эстрада чуар, анда талантлар да бик күп. Бигрәк тә музыкантлар арасында. Җырчылардан иң яшьләрен белеп тә бетермим. Урта буыннан Филүс Каһиров, Артур Исламов – күренеп торган малайлар. Күренү өчен үз җырыңның булуы кирәк. Минем барысы да – үземнең җырлар. Үзешчән сәнгатьтә йөргәндә кеше җырлары да җырлангандыр. Илһам Шакиров җырларын ярата идем. Профессиональ сәнгатьтә кешенекенә үрелмәдем. Фонограммага җырлаганым булмады. Миңа бер баянчы булса, шул җитә. Өчәү булса да ярый. Хәер, хәзер үзешчән сәнгать дигән бүленеш тә калмады, бөтенесе – профессионаллар.

:: Сез кечкенәдән җырчы булам дип үскән баламы?
– Мин кечкенәдән шофер булам дип үскән бала *(көлә)*. Хезмәт юлымны шофер булып башладым, шофер булып бетердем дә. Актаныштa бер концерттан соң булды ул хәлләр. Җиде ел шофер булып эшләгән 24 яшьлек егетне, моны кертәсе юк, бу үзе дә укырга керә ала дип, Казанга куып диярлек җибәрделәр. Бәхеткә, әнкәй кебек кеше кулына – Зөләйха апа Хисмәтуллина классына эләктем. Училищеда да укытучылардан бик уңдым. Укыган чорда ук Опера һәм балет театрына штатка алдылар. РСФСР-ның халык артисты Хәдичә Гыйниятова, Татарстанның халык артисты Рафаэль Ильясов белән гастрольләргә чыга идек. Менә ул мактаулы исемнәр шул чагында кирәк булган ул, гомер узгач түгел. Әйтик, атказанган артист дигән исем хәзер бөтен кешедә дә бар. Элек бик сирәк бирелә һәм саллы исемнәрдән санала иде.

:: Яныгызда тальян тора. Кулыгызга еш аласызмы?
– Соңгы вакытта бик еш алына. Бу баянны абый (композитор Мирзанур Фарукшин. – **Ред.**) бүләк итте. Элек тә тартылу бар иде, ләкин янымда көчле баянчылар булганда тартына, хәтта алардан ояла идем. Күңел кушканны тыеп торып булмый. Пенсиягә чыккач кинәнәм менә. Иртән торсам да, кич ятканда да кулга баян алып моңлану гадәткә керде. Үземнең җырларны да, Фәтхерахман Әхмәдиев, Сара Садыйкова көйләрен дә уйныйм. Баянга ятып тора бит алар. Хәзер дә матур көйләр язалар, әмма элеккеләре йөрәккә үтеп керә торган. Хәзер дә уйныйлар элеккеге көйләрне. Әмма нәрсәседер килеп җитми, йөрәккә үтми… Мин дә булдыра алам моны, дип уйный алар, шунлыктан салкын килеп чыга. Ә аны йөрәктән үткәрергә кирәк. Чын музыкант җырчыны да тоя, көйнең дә хәлен белә. Менә мин шундый кешеләр белән эшләдем. Рамил Баһаветдинов, Максат Гомәров, абыем Мирзанур Фарукшин… Минем белән абый бик күп эшләде. Үземә йогынты ясаган тагын бер кеше – Максат. Ул эшкәрткән көйләр – алар шедевр инде. Сагындыра ул чаклар…

:: Сезне таныткан җыр «Керкәле таулары» дисәк, дөрес булырмы?
– Мирзанур абый белән үзешчән сәнгатьтә йөргәндә «Яшьлегемә кире кайтыр идем», «Рәзинәкәй», «Әй, гармун, гармун», «Оренбур – Чиләбе» җырлары белән таныйлар иде инде. Соңрак Илгиз Закировның «Сиңа кайттым, газиз туган җирем», «Саубуллашу», «Керкәле таулары» җырларын халык сорап ала иде. Илгиз көенә язылган җырларны бик күп җырладым. Ганс Сәйфуллинның «Акбүз ат»ы да яраткан җырга әйләнде. Менә шулар барысы да мине күтәрде, танытты дип әйтергә кирәк.

:: Бөтен репертуарыгызны туплап чыгарасыгыз килмиме?
– Элегрәк кирәк булгандыр ул. Хәзер инде яраткан җырыңны табу проблема түгел. Техника бит көннән-көн алга бара. Элек пластинкага язылганнар, безнең чорда аңа алмашка «катушка»лар килде, аннары кассетага әйләнде. Хәзер инде дисклар да әйләнештән чыгып бара, бармак буе флешкага икешәр мең җыр сыйдырып була. Кем уйлаган аны шулай булыр дип?.. Моннан берничә дистә ел элек кенә дә телефоннан бер-береңә карап сөйләшү кеше ышанмаслык хәл иде.

:: Сәхнә гаиләгә комачаулыймы?
– Кемгәдер комачаулыйдыр, минем гаиләм акыллы булды. Аннушкам кемгә чыкканын белеп чыкты. Кызларым да барысын да күреп, аңлап үстеләр. Олы кызым бәләкәйрәк чакта мине телевизордан күргән дә елый икән. Нишләп елыйсың, дигәч, әти кызганыч, дип әйткән. Сагынган булган инде. Анна исә, Мәскәүдәме син, басудамы – ул синең эш, дип әйтә иде. Кызларымның икесе дә талантлы. Кечесе музыка мәктәбендә дә укыды, музыка юлын сайларга исәбе бар иде, мин рөхсәт итмәдем. Шуннан икесе дә КАИны тәмамлады. Менә шул кечкенәсе аеруча талантлы иде. Телевизордан кайбер җырчыларны бөтенләй тыңлый алмый, фальш җибәрә, дип сүндереп куя. Үзем күпне күргәнгә, аларның да шул ук язмышны кабатлауларын теләмәдем шул.

Артистның исеме генә матур аның. Матурлык артында күпме көч, күпме көрәш ятканын берәү дә белми. Хәер, беленергә тиеш тә түгел инде ул.

:: Казаннан авылга күченүнең сәбәбе җиргә тартылумы?
– Ул бик табигый килеп чыкты. Әлбәдән – Аннаның туган авылы. Казанга терәлеп торгач, без еш кайтып йөри идек. Бабай ялгызы гына калгач, монда төпләнергә булдык. Әйбәт авыл ул. Халкы белән туганнар кебек яшибез. Якында гына Мишә ага, табигате дә, кешеләре дә матур. Әлбәдән – керәшен авылы, татар кияүләре, татар киленнәре дә шактый.

Әткәй, әнкәй исән булганда, Актаныш юлларына да тузан төшерми идек. Хәзер бабайны ташлап китә алмыйбыз. Мин кайтып килдем менә. Узган атнада туганнарым үзләре җыелып килделәр. Туган нигездә абый яши, шөкер, нигезебез исән. Аннан ерак та түгел сеңелкәш тора. Дүрт туган идек без, бер абыебыз вафат булды. Әткәй-әнкәй дә озын гомерле булмады, алтмышны тутырып, җитмешне ваклый башлагач, гүр иясе булдылар. Нәсел белән җырлы-моңлы без. Туганнардан абый Алабуга училищесын тәмамлады, мин югары белем алдым. Абыйнык оста баянчы ул. Мин «до» нотасының кайда урнашканын белгәнче, ул урамда туктап торган арада да көй язып бирә ала иде инде. Мин Казанга нота белмәгән килеш бардым, бик тырышып укырга туры килде. Җырлау өчен белем бик кирәк. Шуңа күрә ит чабучы оста җырчы булып киткән дигән сүзләргә мин бик ышанып җитмим.

:: Яңа җырлар өйрәнәсезме?
– Өйрәнәм әле. Алмаз Хәмзин «Татар җыры яңгырый дисеннәр» дигән җыр бирде. Сүзләре кемнеке диген син аның, Нияз Акмалныкы! Озын гомерле булсын иде инде. Җырларга егәр бар әле. Композитор Сафьян абый Ибраһимовтан, ничек соң хәлләр, дип сорагач, әйбәт, Газинур, тотып торсалар, басып тора алам әле, дип әйткән иде. Яше 85ләр тирәсендә булгандыр. Мине әле ике яктан тотып тормыйлар, көч бар, җырлар көннәр алда әле.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

РӘШИТ ФӘТХРАХМАНОВ

ӘКЪЛИМӘ

(хикәя)

Бүген иртән компьютерын кабызганчы ук, Әкълимәнең йөрәге нидер сизенде. Була бит шулай кайчак: нидән икәнен белмисең, күңел каядыр талпына. Хатынның бүгенге халәте шундый иде. «ВКонтакте»дагы битенә керүгә, үзенә кемнеңдер дуслык тәкъдим итүен күреп алды. Бу гадәти хәл инде үзе: бер белмәгән кешеләр дә дуслыкка керергә омтылалар. Әкълимә интернетка фотосын куймый. Бары тик йөрәгендә туган хисләрен шигырь итеп төшерә дә социаль челтәргә элә. Аның шигырьләрен яраталар. Йөзләгән лайк җыя. Үз битендә уртаклашучылар да җитәрлек. Дуслык тәкъдим итүчеләр дә күп була. Бүгенге тәкъдимнең иясен күрүгә, хатын дерт итеп китте. Компьютердан аңа элекке ире Зөлфәт карап тора. Әйе, әйе, шушы Зөлфәт хакына йокысыз төннәр үткәргән чаклары бар иде Әкълимәнең. Шомырт күзле, чем кара чәчле, түгәрәк йөзле, каратут тәнле Зөлфәт чибәрләрдән бер чибәр иде. Әнә фотосында да ул шундый: беркатлы күзләрен тутырып, томырылып карап тора. Бер дә картаймаган. Әллә яшьлек фотосын куйганмы?

Әкълимә үзе дә гүзәлләрнең берсе иде. Урамда күрсәләр, егетләрне абындырырлык сылу иде. Шуңадырмы җиңел гаилә кордылар алар: Зөлфәт тәкъдимен озак көттермәде, Әкълимә ялындырмады. Сиксәненче еллар ахыры иде. Юклык чор. Тулай торакта бер бүлмәгә чак тиенделәр. Ул елларда сатып алырга фатир да юк, йорт төзергә дә җай бирмиләр, акчасы да бәрәкәтсез һәм такы-токы гына иде бит. Тик яшьләр зарланмадылар. Шәһәргә килеп төпләнгән күпчелек шулай яши. Узышу юк, көнләшү юк. Тигезлек. Бер-бер артлы бер ул, бер кыз туды. Ул арада совет кешеләренең дөньясын астын өскә китергән 1992 ел килеп җитте. Зөлфәт эшсез калды. Төшенкелеккә бирелде. Бөтенләй көтмәгәндә чирләп тә китте. Онкологик диспансерга йөри башлады. Табибләр диагнозы өметсез иде. Балалар карап өйдә утырган Әкълимә кая барып бәрелергә белмәде. Эшләгән кешенең дә акчасы ашарга җитми. Хезмәт хакларын яртышар ел түләмиләр. Бәяләрнең янына якын барырлык түгел. Әле ярый ул чакта әнисе исән иде. Балаларны шуңа кайтарып куйды. Авылдан күтәрә алган кадәр бәрәңге, кишер, чөгендер төяп килде. Һәм... ирен дәваларга тотынды.

– Сеңлем, күңелеңә авыр алма, ирең бездә дәва юк. Без синең кулыңа, үлгәч мәшәкатьләнеп йөрмәслек итеп, диагнозы язылган белешмә генә тоттыра алабыз. Җирләгәндә бер борчуың ким булыр, – диде аңа өлкән яшьтәге табиб. Аннан бераз карап торды да өстәде. – Өметсез шайтан гына, дип әйтәләр бит. Киләчәккә өмет уята алсаң, ирең, бәлки, уңайланып та китмәсме... Салынган канатлар авыруы дип йөртәләр моны. Төшенкелеккә бирелүчеләрне ярата. Үз-үзләрен ашап, иммунитетларын бетерәләр дә чирлиләр. Могҗизалар да булгалый, депрессиядән чыгып, инде бетте дигән кешеләр дә терелә кайчак.

Әкълимәнең үзенең дә җилкәсе салынган, йөрәктә утлар кайный иде. Табибның соңгы сүзләренә суга батучы саламга тотынган кебек тотынды ул. Яман шештән дәвалау ысуллары турында халык медицинасы китапларын җыйды. Ярдәм итсә, бары тик Аллаһы Тәгалә генә ярдәм итәчәген белә иде: Коръән укырга өйрәнде, намазга басты. Өзелеп-өзелеп догада Раббысына ялвара башлады. Ашарга болай да юк иде. Ач торып, соклар эчеп дәвалану ысулын сайладылар. Сайладылар дип, Әкълимә сайлады инде. Зөлфәт бар нәрсәдән өметен өзеп урын өстендә ятарга керешә. Әкълимәгә аны сабый баланы караган кебек карарга, астын да җыештырырга туры килә башлады. Ирнең аңы бар иде. Шул аңга өмет очкыны салырга тырышты хатын. Уртак киләчәк турында сөйләде гел. Балаларның киләчәген матурга юрап, бергә картаю турында татлы хыяллар өстәп сөйләште. Яман чирдән терелүчеләр турында язылган газета материалларын табып кычкырып укыды. Сәхәр вакытында тәһәҗҗуд намазын укып, догалар кылып таңны каршылады. Ире янына утырып, озаклап Коръән сүрәләре укыды. Көннәр санаулы иде. Я алга китәсең, я кабер йота. Җиләк-җимеш сокларын табарлык мөмкинлек юк иде. Авылдан алып килгән кишерне, чөгендерне угычтан уып, сок сыкты хатын. Куллары суелып бетә иде. Үзе ураза тотты.

Таңнарның берсендә иртәнге намазының сөннәте белән фарызы арасында хатын җаны-тәне белән бирелеп Аллаһтан ирен терелтүен сорап дога кыла иде. Бераз гына тын алыйм дип, туктап уйланып утырганда, тавыш ишетте:

– Әкълимә, тагын кыл әле доганы, син дога кылганда, бөтен бүлмә нурга күмелә.

Зөлфәт торып утырган икән. Шул сәгатьтән башлап, иргә җан керде. Йөри башлады, тормышка дәрте уянды. Тулай торак шәһәр читендә генә иде. Зөлфәт урын өстендә ятканда, Әкълимә таң чыгы җыеп кайтып, аның тәннәренә сөртә иде. Йөри башлагач, ир хатын кушуы буенча берничә тапкыр барып, чыклы үләндә ялантәпи йөрде, ятып аунады да. Көннән-көн алга китеп, ир савыкты. Могҗиза, чынлап та, була икән. Тик Әкълимә күпме генә өндәмәсен, намазга басмады ул, башын Галәмнәр Хуҗасы алдында имәде.

Шатлыклы көннәрнең берсендә тулай торак коменданты килеп ишек шакыды. Бүлмәдән чыгарга кушты. Зөлфәт савыга башлагач, Әкълимә эшкә урнашкан иде инде. Балаларны да үзләре янына алдырырга җыена иде. Бүлмәдә калуның бер генә җае бар: комендантка ришвәт төртеп, яшәгән урынны приватизацияләү. Күпчелек шулай эшли, бу хакта гаилә белә иде. Авылга кайтып, әнисенең пенсиясеннән кысып, сөт-йомырка сатып җыйган акчасын алып килде хатын. Бүлмәне хосусыйлаштырып Зөлфәт исеменә яздылар.

Зөлфәт тә тернәкләнеп эшкә керде. Ярыйсы гына төшемле урыннарда эшли башлады. Искерәк машина алдылар. Буш вакытларында ир таксовать итеп тә маяга акча өстәде. Шәһәр читендә җир юнәтеп, өй салу хәстәренә керештеләр. Тормыш акрын гына үргә күтәрелде. Үз йортлары белән яши башладылар. Тулай тораклагы бүлмәне арендага бирделәр.

Бәла бу юлы бөтенләй көтмәгән яктан килеп сукты. Тормыш бөтәйгәч, Зөлфәт үзгәрде. Башка хатыннарга күз төшерә башлады. Көннәрдән бер көнне аерылышу турында сүз кузгатты. Әкълимәнең күз төпләренә нечкә генә булып җыерчыклар сызыла башлаган иде инде. Тормыш йөген тартам дип талпынып яшәү эзсез үтмәде. Ир йортны да, җирен дә үз әнисе исеменә рәсмиләштергән булып чыкты. Янәсе, пенсионерлар салым түләмиләр. Әкълимәгә, балаларны алып, тулай торак бүлмәсенә күчәргә туры килде. Хезмәт хакы кечкенә иде хатынның. Зөлфәт акчасын конвертта алып эшли, алимент аз тия. Ул көннәрнең авырлыгы әле дә җилкәгә басып тора сыман.

Бирешергә ярамаганын белә иде хатын. Тормышның сынау мәйданы икәнен дә, яшәүнең чын мәгънәсе дә аңа мәгълүм иде. Ике баласын кочаклап, бүлмә уртасында озак уйланып утырды. Ир башка хатын белән яши башлады, Әкълимәне эштән кичә генә кыскарттылар, кесәдә берничә көн яшәрлек акча бар. Утыр да ела, алга таба яшәрлек көч тә, чара да юк сыман. Ләкин авырлыктан соң җиңеллек килә дигән Аллаһы Тәгаләнең вәгъдәсен белә иде ул. Аның Раббысы – вәгъдәсен үтәүче. Башын түбән иеп озак утырмады. Зөлфәтне дәвалаган чакта чыныккан иде. Хәрәкәтсез торырга ярамавын да белә. Булган акчага он китертте, пәрәмәчләр пешерде. Әкълимә пешергән пәрәмәчнең тәмен бер ашап караганнар онытмый. Ач балаларга берәр пәрәмәч тоттырды да, калганын сумкага төяп, Аллаһка тәвәккәл кылып, урамга чыгып китте. Затлы машиналар туктый торган урында теләнеп йөрүчеләрне күргәне бар. Тик ул теләнә алмый бит инде. Юлаучыларга пәрәмәч тәкъдим итә башлады. Затлы иномаркаларның берсеннән чыгып килүче ыспай ир кулына меңлек акча тоттырып ике пәрәмәчен эләктерде дә, сдачаны да көтеп тормыйча, юлын дәвам итте. «Сдачаны алыгыз, акчагыз миндә калды», – дип кычкырырга борылып та карамады хәтта. «Чәйлек» дигән сүзнең ни икәнен белми иде Әкълимә. Кулында «чәйлек» тотып калды. Әмма ике көннән соң очраштылар алар. Әкълимә пәрәмәчләренең тәмен белүчеләр саны арта башлаган иде инде. Шул ук тукталышта шул ук машина килеп туктады. Машинадан шул ук яшь ир килеп чыкты.

– Исәнмесез, минем Сезгә бирәчәгем калды, – диде Әкълимә, уңайсызланып. – Алыгыз сдачагызны.

Тик ир акчага кулын сузарга җыенмый иде.

– Беләсезме, – диде ул, киң елмаеп. – Мин – яңа ресторан хуҗасы. Сездән алган пәрәмәчнең тәме телдән китми. Безнең ресторан өчен пәрәмәчләр пешереп тора алмассызмы икән?

«Тәме телдән китми». Бу сүзне аңа еш әйтәләр. Улы – үзенең ай-ти компаниясен булдырган яшь бизнесмен, республикада танылган шәхес – беренче зур хезмәт хакын алып кайтып әнисенең кулына тоттыргач:

– Әни, теге чакта пешергән пәрәмәчеңнең тәме телдән китми. Сеңлем дә, мин дә бик ач идек ул көнне. Берәрне генә бирдең безгә. Күп итеп тагын пешер әле шундый пәрәмәчне, – диде.

Ул чакта... ул чакта Әкълимәгә акча бик кирәк иде. Нәсим (ресторан хуҗасының исеме шундый иде) ясаган тәкъдимнән соң аның эшләре тауга китте. Бүген ул кулинария цехы һәм кондитер цехы тота. Шәһәр читендә затлы йорт салып чыкты. Бүтән кияүгә чыкмады инде. Үз әтисе каккан балаларны чит ир какмас дисеңме?

Дуслыкка алу төймәсенә басуын сизми дә калды хатын. Йөрәк никтер дулкынланып типте. Әмма бер хәбәр дә салмады Зөлфәткә. Берничә көннән соң ир үзе язды: «Әкълимә, минем янга килеп чык әле. Хәлем авыр минем», – диде. «Хәле авыр, имеш...» Әкълимәнең ярсып кычкырасы, компьютер өстәлен төясе, иргә яман сүзләр язасы килде. Шулай да сабыр итте. Үзенә зарар салучыларны кичергән колларын Аллаһы Тәгаләнең «бөек бәхет ияләре» дип атавын белә иде ул. Шуңа да гомер буе таш атучыларга аш атып җавап бирергә өйрәнде. Ул белә иде: үч сакламаганга күрә аның эшләре һәрвакыт уң була, бәхете арта. Бу юлы да Зөлфәтне тыңларга булды. Җавап язып тормады. Машинасын кабызды да таныш адрес буенча юлга чыкты.

Капка бикле иде. Эчтә буылып эт өрде. Озак вакыт көтәргә туры килде. Ирнең телефонын алмаганга бераз үкенеп куйды. Кире борылып кайтып китәргә дә була иде. Зөлфәткә аның бирәчәге юк. Алачагы бардыр, бәлки. Ни дисә дә, киләчәккә зур өметләр белән бергә торгызганнар иде бу йортны. Ирнең исәбе башка булганын каян белсен инде Әкълимә? Әмма алачагын кичереп өйрәнде ул. Гафу итү аның яшәү принцибы иде.

Көттереп кенә ишек ачылды. Аннан таушалган халатлы, тузган чәчле хатын чыгып этенә кычкырды. Әкълимә «Кем бар анда?» дигән тавышка ни дип җавап бирергә белмәгәч: «Исәнмесез, мин Зөлфәт янына килгән идем», – диюдән башка сүз тапмады. Капка ачылды һәм алар – явызлык белән изгелек, гүзәллек белән ямьсезлек, кичерү белән нәфрәт йөзгә-йөз килеп бастылар. «Йөрисең шунда көттереп, – диде ачулы хатын. – Алып кит иреңне бер көн дә калдырмыйм». Минем ирем юк, дип әйтергә теләде Әкълимә, тик сабыр итеп, телен тешләде. Монда, чынлап та, хәлләр шәп түгел, ахры.

Тынчу һавалы, җыештырылмаган өйгә керделәр. Ирнең урыны бусагадан ерак түгел икән, кайчандыр балалар бүлмәсе дип ниятләнгән кечкенә бүлмәдә тузгыган урын-җир өстендә утыра. Йөзен җыерчык баскан, ап-ак чәчле карт Әкълимәгә карады да катып калды. Авызыннан бары тик: «Әклимә-ә-ә», – дигән гаҗәпләнү катыш сокланулы аваз гына чыкты. Бер мизгелдән ирнең җыерчыклы битеннән эре яшь тамчылары тәгәри иде. Балтаны шөшләгә алыштыруын аңлаганның ачы күз яшьләре иде болар.

Эшләр монда, чынлап та, хөрти икән. Иргә инсульт булган, уң ягы йөрми. Хатын, ирне куркытып, барча мал-мөлкәтне үз исеменә яздырган. Йортка һәм малга хуҗа булгач, хатынга авыру картның кирәге калмаган. Картлар йортына биреп котылмакчы булган. Менә шунда Әкълимәне искә төшереп, ярдәмгә элекке ярын чакырган да инде ир. Кыскасы, Зөлфәт яшьлегендә үзе утырткан агачның ачы җимешләрен татый башлаган.

Машинаның арткы утыргычында уйга баткан иргә эндәшәсе итте, ниһаять, Әкълимә. «Зөлфәт, син мине ачуланма инде, өйгә алып кайта алмыйм. Тулай торакның теге бүлмәсен сатмадым мин. Сата да алмый идем, чөнки ул һаман да синең исемдә. Ул буш тора. Муллыктан бик иркәнәеп, ваемсызлана башласам, үземнең кем икәнемне искә төшерү өчен гел шунда барып чыгам. Тар бүлмәдә бер кич кунам, Аллаһы Тәгаләдән үземнең зәгыйфь кол икәнемне, һәрвакытта да аңа мохтаҗ икәнемне онытмавын сорыйм. Сине шунда илтәм. Карарга кеше билгелим. Үзем дә көн дә килеп китеп йөрермен, билгеле. Калганын, кайткач, балалар хәл итәр. Улың да, киленең дә, киявең белән кызың да, оныкларың да – барысы җыелып Дубайга ял итәргә киттеләр. Бер атнадан кайталар, Аллаһ теләсә», – диде ул тын гына утырган иргә. Балаларының үзе кебек үк шәфкать ияләре икәнен, әтиләрен кичерәчәкләрен белә иде ул, әлбәттә.

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»нан ай саен бер бүләк

1 **ЯЗЫЛ!**
2022 елның
икенче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язып

6 айга язылу бәясе

П2435
җомга саны
488 сум 10 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1099 сум 32 тиен

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘК ОТ!**
30 июньгә кадәр
газетага
язылучылар
арасында
ТАНДЫР
уйнатабыз

Квитанцияләр 5 июльгә кадәр кабул ителә. 7 июль көнне уйнатыла.

Акция 2022 елның 29 апреленнән башлап 7 июленә хәтле дәвам итә. Акциянең оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Тулырак: vatantat.ru 16+

Реклама

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕЛӘРЕ

Тандырда пешкән ризык тәмле һәм тәмлы!
Иң күп сайлау мөмкинлеге – «Тандыр 24» кибетендә.
Сезнең барлык сорауларыгызга җавап бирерләр.

«Тандыр 24», ТР, Казан шәһәре,
Заикев урамы,
4 нче й., сул канат, 2 нче кат
тел.: +7-917-919-80-01

Реклама

«АРЧА ОСТАСЫ»

Капка-коймалар, мангал, атынчыклар, бакча өчен урындык-өстәлләр, беседкалар, чардуганнар.

+7-906-326-82-68 Зөлфәт



Реклама

Сканворд клетка эчендәге сораулар:

- Чүлдә үсә торган куак
- Чиләгенә ... капкачы
- ...-Абеба
- Борынгы грек тарихчысы
- Балхаш күленә коючы елга
- Ялагай, тәлинкә тотучы
- Юпитер иярчене
- Гарәп хәрефе
- Актер ... Костнер
- Актриса Клара ...
- Үле тел
- Кәтлит төре
- ... Турман
- Станислав ... (поляк фантасты)
- Җырчы ... Польна
- ... Дарвин
- Бозда шуу өчен җилкәнле чана
- Популяр салат
- Көпчәк
- Көчле давыл
- Агулы тропик агач
- Виктор ... (француз язучысы)
- Сугылган башак
- Африкадагы ил
- Зодиак билгесе
- ... Гайсин
- Неваның сул кушылдыгы
- Ераклык, дистанция
- Кәрәзле элемтә компаниясе
- Татарстандагы район
- Йөз, чырай
- Хәйлә белән, чынлыкны яшереп

Рәис Габдулла

17 июнь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: катет, елт, Нигер, Бикчәнтаев, Агра, кремнезем, дәү, чор, ким, иртә, Шамил, акан, Таишев, Негро, ору, Рея, Лут. **Вертикаль буенча:** бәке, Ной, кратер, кредит, агул, куныч, Мәмәшир, әрну, шорт, таган, шае, Таз, саквояж, теркәгеч, Ма, Ермолин, Оттава.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч вариантыннан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Берләшкән Милләтләр Оешмасының (БМО) Курыкынычсызлык Советына кергән илләрнең ничәсе бу төркемдә даими катнашучы булып санала?
А) 5;
Б) 6;
В) 7.

2 Бу төбәкләрнең кайсы Татарстан белән чиктәш түгел?
А) Оренбург;
Б) Пермь;
В) Ульян.

3 Танылган совет футболчыларының кайсы Татарстанда дөньяга килгән?
А) Галимҗан Хөсәенов;
Б) Вәгыйз Һидиятуллин;
В) Ренат Дасаев.

4 Никита Хрущев СССР белән ничәнче елларда идарә итә?
А) 1953–1963;
Б) 1953–1964;
В) 1953–1965.

**5 «Йөрәгеңнән үбәр идем,
Күренми шул йөрәк –
Ах шул йөрәк, серле йөрәк,
Яши тирәндәрәк».
Бу шигырь юлларының авторы?**
А) Рафис Корбан;
Б) Мәдәррис Әгъләм;
В) Равил Фәйзуллин.

Җаваплар: 1) А; 2) Б; 3) А; 4) Б; 5) Б.

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 16016 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 288

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+